МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР РАЗВИТИЯ ТРАДИЦИОННОЙ КУЛЬТУРЫ

# ТАТАРСКАЯ ФОЛЬКЛОРИСТИКА. ИССЛЕДОВАНИЯ МОЛОДЫХ

**Выпуск 2**

**Казань 2011**

*Печатается по рекомендации*
*Ученого совета Республиканского центра развития*
*традиционной культуры*

**Составители:**
Ф.Х. Завгарова;
Л.Ш. Давлетшина

**Редколлегия:**
Р.Г. Мухамедова;
М.Х. Бакиров

Татарская фольклористика. Исследования молодых: сборник материалов чтений школы молодых фольклористов. – Казань: Алма-Лит, 2011. – Вып. 2. – 157 с.

В сборнике представлены материалы чтений школы молодых фольклористов  2011 гг. Книга представляет интерес для фольклористов, языковедов-диалектологов, этнографов и всех тех, кто интересуется татарской традиционной культурой.

## От составителей

Республикански центр развития традиционной культуры Министерства культуры Республики Татарстан продолжает исследовательскую работу по разным проблемам татарской традиционной культуры. В целях привлечения молодых к программным научным проектам и обмена опытом известных ученых и молодых исследователей с 2008 года при Центре работает ежегодная школа молодого фольклориста. В рамках школы проводятся чтения, в котором основное слово предоставляется молодым ученым, аспирантам, учителям словесникам, студентам и всем тем, кто делает первые исследовательские шаги. Республиканским центром развития традиционной культуры в год проводится два тематических чтения. Одно из них постоянное и посвящено освещению актуальных проблем полевой фольклористики. На протяжении последних трех лет данные чтения воспитали своих постоянных участников. Отрадно и то, что на эти чтения с удовольствием приезжают учителя общеобразовательных школ, которые руководят фольклорными экспедициями школьников. Тематика других чтений определяется Ученым советом Центра. В 2011 году осенние чтения были посвящены проблемам текста и контекста в фольклористике.

В предложенном сборнике представлены доклады участников чтений 2011 года. Сборник материалов чтений охватывает статьи, в которых рассматриваются вопросы взаимосвязей фольклорных традиций с традициями письменной культуры и искусства, актуальные вопросы полевой фольклористики, в которых рассматриваются локальные традиции и особенности разных фольклорных явлений.

Статьи представлены на татарском и русском языках.

**И.И. Ахатова, С.И. Ахатова**
Казан педагогия көллияте

# ТАТАР ГАИЛӘСЕНДӘГЕ АРАЛАШУ ӘДӘБЕНЕҢ ФОЛЬКЛОР ҮРНӘКЛӘРЕ (Татарстан Республикасы Кайбыч районында булган экспедиция материаллары буенча)

XXI гасырда укыту-тарбия максатлары педагогик система алдына яңа таләпләр куя:

– өйрәнә белү;
– эшли белү;
– яши белү;
– аралаша белү;
– сәламәт булу.

Педагогия көллиятендә укучы студентлар әлеге компетентларны үзләрендә һәм булачак укучыларында формалаштыру юлларын белергә тиеш.

Музыкаль фольклор белән кызыксынучы Казан педагогия көллияте студентлары 2011 елның 29 июнь – 2 июль көннәрендә Татарстан Республикасы Кайбыч районына экспедициягә тәрбияви максатларга ирешү өчен халык педагогикасында нинди җирлек бар икәнен ачыклау теләге белән бардылар. Аерым алганда, аралаша белү компетентлыгын формалаштыру юллары аеруча кызыксындырган өлкә булды.

Күзәтүләрдән чыгып, без хәзерге яшьләрдә һәм балаларда аралаша белү әдәбенең тиешле дәрәҗәдә югары булмавын раслый алабыз. Әйтик, үзара тупас мөгамәләдә булу, сабырсызлык, юл куя белмәү, гаебеңне таный белмәү еш очрый.

Татар халык педагогикасы гасырлар буена әлеге күренешләрне булдырмау юлларын күрсәтеп килә. Иң нәтиҗәле чараның фольклор үрнәкләре булуына без югарыда әйтелгән экспедициядә инандык.

Аралашу әдәбе иң элек гаиләдә формалаша. Экспедиция барышында табылган татар гаиләсендәге аралашу әдәбе үрнәкләрен без 6 төргә булеп карадык :

1) егет – кыз аралашуы әдәбе;
2) кода – кодача аралашуы әдәбе;
3) ир – хатын аралашуы әдәбе;
4) килен – кайната, кайнана аралашуы әдәбе;
5) ана – бала аралашуы әдәбе;
6) балаларның үзара аралашуы әдәбе.

Бу үрнәкләрнең Татарстан Республикасы Кайбыч районында язып алынуын һәм аларның 1950 елларга караганлыгын искәртеп үтәргә кирәк.

Һәр аралашу әдәбен 3 төрле яктан анализлыйк:

1) аралашуның кагыйдәсе;
2) аралашу барышында үз-үзеңне тоту рәвеше;
3) аралашу барышында кулланыла торган тел байлыгы һәм сәнгать чаралары.

**Егет-кыз аралашуы әдәбе**

*Кагыйдә*: егет – кыз аралашу әдәбе үзара хөрмәт, интим тотнаклыкка нигезләнгән.

*Үз-үзеңне тоту*: егеттән йөз яшерү гадәте юк, ләкин кыз егеткә беренче булып сүз кушмый. Егетләргә беркадәр кыюлык күрсәтү гаеп түгел. Гадәттә бу гамәл кызның тотнаклымы-юкмы икәнлеген тикшереп карау максатында була. Әгәт кыз үзенә кагылырга рөхсәт итмәсә генә, егет тарафыннан хөрмәткә лаек була һәм егет өйләнү нияте белән аралашу тәкъдим итә. Никахка кадәр интим якынлыкка керү катгый тыела.

Татарстан Республикасы Кайбыч районы Олы Кайбыч авылыннан Шәмсетдинова Ләбибә апа белән интервьюдан өзек: “Танышып, берничә ел йөргән егетләрә чыга идек, ияреп кенә кайтмый идек. Бик тәртипле йөри идек ул чагында без, шул хәтле тыйнаклык була иде. Утырып торганда (ул заманны әйтәсе дә түгел, совет заманы!) ырынышып та утырмый идек! Товарный

поездда йөреп тә кызларга тимиләр ие, кешегә кеше дошман түгел ие”.

Хәтта гаилә коруда кагыйдәгә кермәгән кыз урлау йоласында да интим сафлыкка таләп зур. Бу йолада кыз үзе һәм аның әтиәнисе кызны кияүгә алып китәчәкләре турында белми. Егет гаиләсе шулай ук белмәскә мөмкин, ләкин ачыктан-ачык булмаса да егетнең берәр туганы бу хакта белеп тора һәм хәстәрлеген күрә: гади генә табын, никах укыячак бабайны белешеп куя. Бары тик егетнең ата-анасы белеп, никах укыганнан соң гына яшь кәләш белән кияүгә уртак түшәк җәелә.

Татарстан Республикасы Кайбыч районы Олы Кайбыч авылы китапханәчесе Хаялиева Эльмира, бертуган Шамсутдинова Рәхилә һәм Фәизова Рәхимә апалар белән әңгәмәдән өзек:

– Беренче тапкыр кияүгә үзегез риза булып чыктыгызмы?

– Юк, ризалыктан башка. Менә фермада эшлидер идем. Япяшь кыз. Әти-әни юк инде, абый өйләнгән ие. Безгә килеп йөри бу кешеләр ат белә. Күрше кызына йөри иде. Хәзер мин фермада дежурга барам, төнге дежурга. Шул вакытта болар чыгып киттеләр. Мин үзем генә киттем, мин китәм дидем. Күрше кызы да бар ые шунда. Тегеләр аны ташлап киткән дә, кай арада ат җигеп алганнар? Мине арткы яктан килеп бәреп салдылар да алып киттеләр. Шуннан бер-ике сәгатьтән соң, (чишенмәгән дә ием, бик каты елап, яшь бит, яшьлек, ие) абый алып кайтты мине. Шул көнне, кайткач ук инде, әйттеләр: ”Ии, тимәдеме, тимәдеме?” Минем йөрәккә бик кадалды инде ул. Мине ризалаштырып, шуннан килеп, ниеп, ничектер бергә булган кешеләр әйбәтләп, фәләннәр дип, мин яңадан киттем шунда үзем теләп.

– Әле, Румияләр ягында, Шыгырданда, кызны урлап китәләр икән, өенә алып кайтмый, икенче бер йортка: белешенәме анда, танышынамы, алып кайта, йоклый. Әгәр дә син честный буласың икән – өенә алып кайта, честный булмасаң, – кире җибәрә. Менә ансы бигрәк начар инде аның.

Хаялиева Эльмира өстәп куя: ”Кире кайтарганда инде авыл җыела. Уже син беркайчан да инде кияүгә чыга алмыйсың. Сине позор дип кайтарып куялар”.

Ябышып чыгу йоласында, кыз урлау йоласыннан аермалы буларак, кыз үзе ризалыгы белән бара, аның әти-әнисе генә бу хакта белми.

Кече Кайбыч авылыннан Миңнуллина Тәскирә апа белән әңгәмәдән өзек:

– Сезнең заманнарда урлап алып кайтулар булган, сезнең ничек иде?

– Безнең заманда урлап алып кайтып түгел, үзең барадыр идең.

– Хәзерге кебек алдан сорап, көнен билгеләп, никах-туй белән тугелдер?

– Юк, юк, үзебез генә иярәбез дә кайтабыз инде. Никахны шул көнне төнлә укыйлар, бабай чакырталар да.

– Никахка кунаклар чакырыла идеме соң?

– Никахка кеше җыелмый. Үз кешеләрең була да, шул бер бабай алып керәләр дә, укыталар, шул гына. Анда свидетельләр юк, хәзерге кебек.

– Табын әзерләнә идеме соң?

– Табын түгел инде, шул, бабай килгәч, чәй хәзерлисең инде. Бер бабай гына сиңа укып китә никахны.

– Ә туй кайчан үткәрелә?

– Ясаган кеше ясый, ясамаганы юк.

– Кызның әти-әнисе белә идеме соң никах турында?

– Юк, икенче көнне минем кайнанам, кызыгыз бездә, дип барып әйткән инде. Кайсы хәллерәк кеше, әзрәк акча да алып барып бирә инде, кызга. Элек бөтен кешегә дә туй ясау юк иде, хәллерәк кешеләр генә туй ясыйлар иде.

Олы Кайбыч авылыннан Шамсутдинова Рәхилә апа сөйли: «Йөрештек тә Сәлах абыең белән, беркөнне килде. Көндез вәгъдә куеп киттек. Бүген кич килеп алам, диде. Әнкәйләр кунакка кит-

те. Әнкәйләр киткәч, мин сеңлем белән бераз гына бөтеремне бөтәрләдем дә, бер очка барып утырдык. Шул арада теге сызгырды да, чыгып чаптык. 54 нче елның 10 нчы январендә иде бу. Бөтен дөньям туңган инде. Өч егет, тулуп кигермәкче булалар, кигерә алмыйлар миңа, теге, курыкканмы инде, ниткәнме... Болар мине алып кайттылар, аннары бабайны алып килделәр. Мине бер почмакка керттеләр, почмакта утырам хәзер. Бабай укыды да: «Риза булып килдеңме?», – дип сорый. Мин почмактан: «Риза», – дип кычкырдым инде (көлә), баштан әллә ниләр уза инде. Аллага шөкер: 50 ел да 5 ай яшәдек. Алты бала үстердек".

*Тел байлыгы һәм сәнгать чаралары.* Егет – кыз аралашуында назлы сүзләр куллану киң таралган күренеш. Бер-беренә «җаным», «канатым» дип дәшү, «сөеклем», «җанкисәккәем», «бәгырькәем» кебек сүзләр кертеп, шигырь, җыр юллары язылган сөю хатларын энекәше, сеңлесе яки берәр дусты аша бер-берсенә җибәрү – матур гадәт. Беренче булып язмаса да, хатка җавап язу кызга гаеп саналмаган, киресенчә, кыюсызрак егетләргә кызның уңай мөнәсәбәтен белдерә торган ишарә булган бу. Кичләрен клубка чыгып, күмәк җырлап утыру һәм җырлы-биюле уеннар оештыру – яшьләрнең көндәлек аралашу чарасы. Уен барышында кулга-кул тотынышу, кочаклап алу кебек хәрәкәтләр дә гаеп саналмый.

Кече Кайбыч авылыннан Сафиуллина Мөнширә апа белән интервьюдан: «Клубта нинди җырлар җырлыйлар иде?» – «Җаным, анда общий җырлыйлар ие. «Урам көе», «Алмагачлары» диләр ие инде. Әллә нинди көйләр юк иде инде. Менә мин үскән чакта чыкты инде «Күбәләгем, түгәрәгем». Мин әле бит бик карт түгел».

Кече кайбыч авылыннан Сафиуллина Мөнширә Лотфулла кызы һәм Сафиуллин Мөдәрис Сафиулла улы кайбер уеннарны искә төшерделәр:

*«Күгәрчен ашату»* уены. Кызлар һәм егетләр тезелешеп утыралар (саны билгеле түгел). Култыклап тотышалар, ярты шырпыны иреннәр арасына кыстырып бер-берсенә бирәләр.

*«Каеш сугыш»* уены. Кызлар һәм егетләр тезелешеп утыралар. Алып баручы егет утырган берәр кызга каеш белән кулына сугып каешын идәнгә ташлый да, әйтә: «Яратасынмы? Яратсан, ал», – ди. Кыз, яратса, каешны алып егет утырганчы җавап итеп сугарга тиеш. Яратмаса, икенче егеткә сугып: «Яратасынмы? Яратсан, ал», – ди. Уен шулай дәвам итә.

## Кода – кодача аралашуы әдәбе

*Кагыйдә:* кода – кодача аралашуы никахта, туйда һәм кода төшерү мәҗлесләрендә башлана. Һәр кода ягы дәрәҗә саклау, сер бирмәү позициясеннән торып аралаша, юмартлыкта ярыша.

*Үз-үзеңне тоту:* ике як та үзе бирә торган кызны яки өйләнүче егетне бары тик яхшы яктан мактап күрсәтергә омтыла, алар туып үскән гаиләләрнең халык арасындагы дәрәҗәсе белән горурлыгын күрсәтә. Ләкин бу артык мактануга китсә, гаеп санала: мактаулар кияү-кәләшнең бер-беренә тиң икәнлеген раслау дәрәҗәсендә генә булырга тиеш. Үз ягыңны мактаганда, каршы якны ялгыш кына да кимсетеп күрсәтү ярамый. Һәр кода ягы үз нәселенең кимчелекле ягын күрсәтмичә яшереп калдыру ягында. Холыксыз, хәмер белән мавыгучы кешеләр кодалар янында үзләрен тиешле кысаларда тоталар. Мәҗлесләрдә һәм гади аралашуда баш кодага аеруча зур хөрмәт күрсәтелә. Туй ясаган очракта, бүләкләренең мулдан булуы шарт, һәр як хәленнән килмәгәндә дә сер бирми. Чөнки юмартлык нәселнең уңганлыгын күрсәтүче критерий булып тора.

Татарстан Республикасы Кайбыч районы Олы Кайбыч авылы китапханәчесе Хаялиева Эльмира, бертуган Шамсутдинова Рәхилә һәм Фәизова Рәхимә апалар белән интервьюдан:

– ...Туганнары, тумачалары килә, күршеләре килгән инде, дус ишләре, нишләп килмәсен. Җаным, берсе керә, савымнарын,

бүләкләрен калдырып чыгып китә, ансы капка төбендә, урамда тора; икенче бере керә. Кыз инде сөлгеләрен аскан, кергән беренә сөлге биреп тора. Ансы чыга, тагын икенчесе керә, тагын күчтәнәчләрен, савымнарын, чәк-чәкләрен калдырып чыгып китә.

– Савым дигәне нәрсә?

– Савым нәрсә, казмы инде анда, күмәчме, бәлешме, чәк-чәкме, менә нәрсә алып киләсең килә инде. Савым инде ул электән нәрсә була? Алтымы күмәч, аннан соң юка, унике бугай, аннан соң каз өстәлгә куярга. Кыз ягы алып килә егет ягына, ие.

Кече Кайбыч авылыннан Миңнуллина Тәскирә апа белән әңгәмәдән: «Элек бөтен кешегә дә туй ясау юк иде, хәллерәк кешеләр генә туй ясыйлар иде. Туйлар хәзерге кебек бик зур булмый иде, чамалы гына. Табын да хәзергечә юк инде, теге, пироглар, бәлешләр пешереп инде ансы. Кабатын ашы буладыр ые. Закускага тозлы кыяр, тозлы кәбестә. Балык та юк, салат та юк инде. Менә холодец буладыр ие инде. Менә шул гына. Эчергә сыра була ие».

*Тел байлыгы һәм сәнгать чаралары:* һәр кода ягының бер берсенә эндәшү өчен махсус исемнәре бар: баш кода – кияү, кәләшнең этиләре. Кодалар – кияү, кәләшнең этиләреннән өлкәнрәк ир туганнары; кодагыйлар – кияү, кәләшнең әниләре, әниләреннән өлкәнрәк кыз туганнары; кодачалар һәм кодалар – кияү, кәләшнең эти-әниләреннән яшьрәк туганнары (гадәттә кода, кодача сүзләренә кешенең исеме кушыла. Мәсәлән: Мәсрүрә кодача, Камил кода). Керәшен туйларында кодалар бер-берсенә җыр белән эндәшәләр. Ул җырларның махсус көе бар һәм «Кодалар көе» дип атала. Мөселманнарда бу юк. Аларның туенда беренче аш, икенче ашлардан соң күмәк җырлау һәм фольклор биюләр бар. Мәҗлес ахырында рәхмәт сүзе җыр белән әйтелә.

Кече Кайбыч авылыннан Миңнуллина Тәскирә апа белән интервьюдан:

– Туйда җырлар җырлана идеме, нинди җырлар популяр иде? Гармун беләндер инде ул?

– Обязательно гармун белән. Элек инде озын, моңлы җырлар җырлыйлар иде. Хәзерге шикелле тырт-пырт түгел инде. Элекке туй җырларын җырлыйлар ие. Мин аның беренче куплетын гына беләм. «Сокланып карап туймаслык», менә шул җырларны җырлыйлар ые элегрәк. Тагын «Урам көе» дә җырлыйлар иде.

– Хатын-кызлар бизәнә идеме?

– Белмим инде ансын, җаным, бизәнгәнен-бизәнмәгәнен. Бизәнергә ярый, сөрмә сөртергә ярый, дигән бит Мөхәммәт пәйгамбәребез хатын-кызларга. Ә ирләргә алтын балдак киярга ярамый, хатын-кызга ярый.

## Ир – хатын аралашуы әдәбе

*Кагыйдә:* ир хакын хаклау кагыйдәсе.

*Үз-үзеңне тоту:* ир белән хатын тигез хокуклы, ләкин хәлиткеч мәсьәләләрдә ир-ат сүзе иң мөһиме. Ир-атлар үзара киңәш иткәндә хатын-кызның катнашмавы гадәткә кергән. Бала тәрбияләүнең малайлар өлеше ата, кызлар өлеше ана карамагында. Кыз баланың гаебе булган очракта ата кеше кызга түгел, иң беренче ана кешегә дәгъва белдерә.

Интим мөнәсәбәтләрне ачык күрсәтү (бигрәк тә гаиләдәге өлкәнрәк кешеләр алдында) гаеп санала. Кеше алдында ир белән хатын кырыс мөгамәләдә.

*Тел байлыгы һәм сәнгать чаралары.* Ир белән хатынның яшь үзенчәлекләренә карап, аларның бер беренә эндәшү сүзләре үзгәргәне күзәтелә: беренче еллардагы “Җаным”, “Бәгърем” кебек ярату сүзләре тора-бара “Атасы”, “Әй-дим”, олайгачрак “Карчыгым”, “Картым” сүзләре белән алмашына.

## Килен – кайната, кайнана аралашуы әдәбе

*Кагыйдә:* кайнатадан тел яшерү, кайнанага берсүзсез буйсыну.

*Үз-үзеңне тоту:* гаиләдәге барлык кешеләр өчен өлкән кеше авторитеты мәҗбүри. Кайната, кайнана сүзен вакытында җиренә җиткереп башкару шарт. Кайнанадан алда аның рөхсәтеннән башка ял итәргә утырырга ярамый.

Татарстан Республикасы Кайбыч районы Олы Кайбыч авылыннан Фәизова Рәхимә апа сөйли:

– Мин үз туемда бальниста бәби бәбиләп яттым. Өйдә туй уйнаталар. Унбер айдан соң туй ясадылар, унбер ай! Карчыкларны туйга өндәп йөрим, никахка инде шул, эч авырта. Белмисең бит инде нәрсә буласын, беренче бала. Керәм дә утырым инде, керәм дә утырам. Әнкәй нәрсәдер эшли инде, кайнанам. Бар, ятып тор, ятып тор, ди инде. Өндәүгә килгән бер кешегә килеп утырам, өндәүгә килгән бер кешегә килеп утырам. Потому что эчем авырта, тулгак, тулгак башланган. Шул көнне кич мине бальниска да озаттылар. Өйдә рәхәтләнеп туй уйныйлар.

Кайнана, кайната хаксыз булган очракта да каршы дәшү зур гаеп. Олы Кайбыч авылыннан Фәизова Рәхимә апа сөйли: ”Әнкәй тукмач кисеп куйган, эре-эре итеп кискән тукмачларын. И-и, мин әйтәм, Алла бирса, мин вак кисәрмен әле дим инде, эчтән”.

Киленнең кайната белән йөзгә-йөз очрашмаска һәм бернинди дә сүз алышмаска тырышуы мәҗбүри булмаса да, киленнең әдәплелеген, кайнанасын хөрмәт итүен күрсәтә торган сыйфат буларак, күп гаиләләрдә сакланган.

Олы Кайбыч авылыннан Фәизова Рәхимә апа сөйли: “Кайнатаның киленгә күзе төшмәсен өчен инде ул, ие, гыйшыкмыйшык булмасынга”.

*Тел байлыгы:* килен кайнанасына “Әнкәй”, кайнатасына “Әткәй” дип, кияү хатынының әнисенә “Әби”, әтисенә – “Бабай” дип дәшә. Кайнан-кайната, әби-бабай үз чиратында “Кияү”, Килен” дип дәшәләр.

## Ата-ана - бала аралашуы әдәбе

*Кагыйдә:* баланың ата-анага берсүзсез буйсынуы, атаның улы өчен, ананың кызы өчен тулы җаваплылыкны йөртүе.

*Үз-үзеңне тоту:* ата-ананың баланың һәр адымына, хәтта интим мөнәсәбәтләренә дә ачыктан-ачык контрольлек итәргә хакы бар. Канәгатьсезлекне балага җиткергәндә кискенсек күрсәтү ата-анага гаеп түгел, бала исә ничә яшьтә булуга карамастан, үз фикерен яклап каршы әйтә алмый. Ата-ана балага һәр даим көче җитәрдәй эш куша, тора-бара баладан эшне үзе белеп эшләвен таләп итә. Гаиләдә әби булганда, әбинең сүзе әнинекеннән өстен санала. Әби кеше оныклалары белән аралашуга күп вакыт сарыф итә. Әни кешенең, гаиләдәге хатын-кыз эшенең авыр өлешен үз өстенә алуына карамастан, балаларга кагылышлы барлык информацияне белеп торуы һәм балалар белән якын мөнәсәбәт урнаштырырга вакыт табуы ата кеше тарафыннан да таләп ителә.

Кайбыч районы Кушкүл авылыннан биш бала анасы Ефремова Ольга Сергеевна балалары белән уйнарга вакыт таба. Без аның балаларына “Сызыкташ” уенын өйрәткән вакытында очраттык.

*Тел байлыгы:* гаиләдәге өлкән кешеләр балаларга исем белән түгел, ә “Улым”, “Кызым”, дип дәшәләр. Балалар, “Әти”, “Әни”, дип дәшәләр.

## Балаларның үзара аралашуы әдәбе

*Кагыйдә:* гаиләдәге өлкән баланың кечесе турында кайгыртуы, аның эш-гамәле әчен җаваплы булуы, кечесенең олысына буйсынуы.

*Үз-үзеңне тоту:* Гаиләдәге өлкән бала кечесен үстерергә булыша. Кече яшьләрдә энесе яки сеңелесенең уенын оештыра, дөрес итеп, ягъни уен кагыйдәләрен бозмыйча, уйнарга өйрәтә. Үсә төшкәч, өлкәнрәк бала кечерәк баланы ашату, киендерү, йоклату кебек вазифаларны үз өстенә ала. Яшьлек чорына кергәч, олырак ир бала сеңлесенең интим сафлыгын саклауга өлеш кертергә, аны якларга тиеш була.

Балаларда уйнау культурасы булу-булмау аларның киләчәктәге яшәү рәвешенең нинди булачагына нигез булып тора. Кече яшьләрдә бала гаиләдә һәм гаилә дусларының балалары белән уйнап аралаша. Анда ул уен тәртибе, кагыйдә кебек төшенчәләр белән таныша; вакыт чамасын тою; нәфесне тыю; җиңелә белү; башкаларның уңышыннын көнләшмичә, максатлы рәвештә җиңүгә ирешү күнекмәләре ала. Шул ук вакытта физик һәм психик яктан чыныга.

*Тел байлыгы:* олырак балалар кечесенә “Энем”, “Сеңелем” дип, кечерәкләр олыракларга “Абый”, “Апай (Апа)” дип дәшәләр. Гаиләдә олыраклар берничә булганда, бу сүзләргә исем өстәлә. Мәсәлән: Илдус абый, Сәхрә апай. Дуслар бер-берсенә исемләп дәшәләр. Уен барышында балалар аз сөйләшәләр, һәр уенның үз терминнары белән аралашалар. Әйтик, уеннан чыгарга тиеш булганда: “Беттең”, кагыйдә бозганда: “Хәрәмләшмә”, кебек репликалар белән уйныйлар.

Билгеле, традицион татар гаиләсендә ярты гасыр чамасы элек яшәгән әлеге язылмаган кагыйдәләрне хәзерге заман гаиләсенә турыдыан-туры күчереп кую мөмкин түгел. Шартлар үзгә. Хәзер яңа төр аралашу чарасы – Интернент барлыкка килде һәм аралашу башка төсмерләр алды. Традицион гаиләдәге кыйммәтләрне саклап калып, яңача тәрбияләүдә куллану – заман педагоглары алдында торган бурыч.

**З.М. Галимуллина**
Кукмара 4 нче урта гомуми
белем бирү мәктәбе

# СУ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЫШАНУЛАР, ЙОЛАЛАР
## (Кукмара районы Зур Кукмара авылы мисалында)

Татар мифологиясендә төрле ияләргә багышланган мифологик хикәятләр җитди урын алып тора. Аларның күпчелеге су асты "патшалыгы" белән бәйләнгән.

Халык йолаларындагы суга карата илаһи ышануларны, олы ихтирамны ислам дине дә саклап калырга булышкан. Хәдистә әйтелгәнчә, иң яхшы сәдака – су белән сугару.

Суның изгелеге ана карынындагы баланың су эчендә ятуы белән аңлатыла. Баланы юган беренче суны (изге, илаһи суны), аның киемен юган суларын чүплеккә, зәхмәтле урынга түгәргә ярамаган. Баланы беренче мунчада аның әбисе юындырырга тиеш булган. Ул, бисмиллаларын әйтеп, балам сау-сәламәт, бәхетле-тәүфиклы булып үссен, кебек теләкләр теләгән. Үлгәннәрне юуны да кешенең беренчел (ана карынында яткандагы) чисталыгына кайтару дип аңлатканнар. Бу юынтык суны, бисмилла әйтеп, агач төбенә түгәргә кушканнар. "Гает алдыннан әрвахлар кайтырлар, бисмилла белән түгелгән суларны эзләрләр", - ди әтием.

Гомумән, юынтык суларны юлга түгәргә һәм түгелгән юынтык сулар өстеннән атлап чыгарга ярамый, су зәхмәте, су җене кагылырга мөмкин. Су белән без үзебездәге тискәре энергияне чыгарабыз. Шуңа күрә мунча кергәннән соң, кул-битләребезне, аякларыбызны юганнан соң без үзебезне яңадан туган кебек хис итәбез.

„Тере су" дигән төшенчә дә юктан бар булмаган. Татарлар беренче язгы яңгырны, чишмә суларын „тере су" рәтенә керткәннәр. Авырулардан котылу өчен чишмә суын, таң алдын-

нан төшкән чык тамчыларын кулланганнар, Болар барысы да Су тәңресе мәрхәмәтеннән тора, дип уйлаганнар.

Халык суларны изгеләштергән. Мөселман халыклары Кадер кичендә кояш баегач, тәхәрәтләнеп, 3 көн „зәм-зәм суы” алырга бара. Суга барганда да, кайтканда да сөйләшергә ярамый, изге теләкләр теләп барырга кушалар. Су алганда, салават әйтеп, ходайдан исәнлек-саулык сорыйлар. Христиан динендәгеләр исә, Раштуа бәйрәмендә бәкедә коеналар. Күп еллар элек безнең якта бер керәшен әбисе, суны изгеләштереп, өстендәге каеры туны белән бәкегә сикерә. Тунын салдырып, икенче кеше тунына төреп алып кайтып дәвалыйлар.

Суны изгеләштерү хәер-сәдакаларда да күренә. Су алиһәсенең мәрхәмәтенә өметләнгән кешеләр, елга-күлләр, чишмәләр янына килеп, суга күлмәк, яулык яисә кеше буе җеп салганнар һәм: „Сиңа яулык, миңа – саулык”, – дип теләгәннәр. Бу күренеш бүген дә сакланган, күп кенә кешеләр чишмә улагына тәңкәләр, акчалар салып, бәхет, саулык сорыйлар. Ә инде ялгыз кызлар язын елга буйларына килеп, чәчәктән үргән тәкыяларын агымсуга салып, үзләренә пар телиләр.

*Су бабасы.* Аның „патшалыгына” билгеле бер төбәктә урнашкан су биләмәләре керә. Ул үзе сулыкларның иң ерак почмакларында яши. Халык ышануларына караганда, ул бервакытта да ярга чыкмый. Ялгызлык яраткан Су бабасы үзен борчыганны, үртәгәнне өнәми. Суның иң ерак, иң тирән урынына кергән кешеләрне, ачуы чыгып, үз янына – су төбенә - тартып алырга да мөмкин. Шуңа күрә элек картлар суга баткан кешеләр турында: „Су бабасы алган”, - дигәннәр. Сулыкларны кимсеткән, суга төкергән, аны пычраткан, нәҗесләгән кешеләргә, ул кеше яши торган авылга да Су бабасы рәхимсезлеген күрсәтә торган булган. Мәсәлән, ул аяз көндә сулыкларда давыл кубарган, буаларны ерып җибәргән, су тегермәннәрен җимергән, кешеләргә хәтәр чир җибәргән. Кешеләрнең тәннәренә сулы шешләр чыккан, аны „су чире” дип йөрткәннәр. Бу чирдән котылу өчен, бер уч ярманы тоз

белән катыштырып, сулыкларга салганнар яки ярманы тозсыз гына чүпрәккә төреп: „Каян килдең, шунда кит, ияңә илтеп бир”, - дип, суга җибәргәннәр.

Беренче мәртәбә таныш булмаган сулыкларга кергәндә яки су алганда хатын-кызлар бер бөртек чәчләрен, ир-атлар бер бөртек сакалларын суга салганнар. Кайбер вакытта киемнәреннән суырып алган бер саплам җеп тә яраган. „Мине ашама, мине эчмә, шушыны аша, шушыны эч”, - дигәннәр.

Әнием, суның матурлыгына, тәменә сокланып карарга ярамый, дип өйрәтте. Андый вакытта суга киемнән бер саплам җеп алып салырга куша, югыйсә су җене кагылырга мөмкин, дия иде.

*Су иясе.* Су иясе сулыклар булган һәр җирдә бар. Ул Су бабасыннан күпкә яшьрәк, шуңа бераз тәҗрибәсезрәк, җиңел акыллырак та. Ул юкка да елга-күлләрдә шау-шу куптарырга мөмкин. Су иясен тынычландырыр өчен Су бабасына кулланган чараны кулланганнар.

Чыннан да, җәйге тыныч көннәрдә елганың кинәт дулаганын, көчле дулкын күтәрелгән очракларны күзәтергә туры килә. Мондый вакытта әтием, суга ипи валчыклары салып, „Су иясе, моны аша да тынычлан”, - дип әйтә. Күп тә үтми, су өсте тынычлангандай була..

*Су анасы.* Ул – хатын-кыз сурәтендәге мифологик образ. Коры җиргә Су бабасы белән Су иясенә караганда ешрак чыга. Су анасы куркыныч затлардан санала. Аның исемен әйтеп балаларны куркытканнар. Кичләрен ялгыз гына су буена төшәргә ярамаган, суны кояш баеганчы алырга кушканнар. Су төбендә ни булмас. Су кечкенәләрне генә түгел, зурларны да алырга мөмкин.

Суның тынычландыру үзлеге барлыгын борынгылар күптән белгәннәр. Чыннан да, суга кул гына тисә дә, кеше тынычлана. Ә балалар җәйге эссе көннәрдә буш вакытларын су янында үткәрергә ярата. Су турындагы ышанулар, легендалар аша өлкәннәр бала күңелендә сулыкарга карата хөрмәт

тәрбияләгәннәр. Халыкта су чыганакларына кагылышлы йолалар яшәп килгән.

Кешеләр элек-электән якын-тирәләренә коелар казыталар. Аны, сәнгать әсәре кебек бизәп, нәкышләп ясыйлар. Балалар кое янында уйнамасыннар өчен, күрше апабыз: „Кое төбендә Кое бабае яши, көндез ул йоклый, аны уятырга ярамый. Кем дә кем аны уята, ул шуны кое төбенә алып төшеп китә. Кое төбенә таш, чүп ташларга, аның янында кычкырырга ярамый. Кое бабае бик усал, чыгып култыксасы белән маңгаегызга суга", - дип сөйли иде. Халыкта, коега төкермә, бервакыт суын эчәргә кирәк булыр, дигән мәкаль дә яши. Шуңа күрә кое авызы һәрвакыт каплаулы булырга тиеш. Ә инде борынгы әбиләребез, кояш баегач, коеларны капкач белән ябып, бәйләп куя торган булганнар.

Әтиебез Кое бабае турында менә нинди әкият сөйләргә ярата: „Кое төбендә Кое бабае үзе генә яши икән. Үзенә генә күңелсез булганга, кое янына килгәннәрне, кое төбенә чүп ташлаганнарны үзе янына ала икән. Аның өе бик зур икән, шуны җыештырып, аңа ашарга пешереп торырга кирәк икән. Ә инде кое төбенә алып төшкән кешеләрне чыгармый, ди".

Су белән бәйле ышанулар матур әдәбиятта да очрый, билгеле. Мәсәлән, С. Хәкимнең „Әнкәй" шигырендә кое образы сагыш, моң белән яктыртылган. Кое яны кешесез тормый. Аннан күршетирә су ала, юлаучылар да аның янында тукталмый узмыйлар. Шунда төрле хәбәрләр ишетәсең. Халыкта, юлчыга тулы чиләк су белән очрасаң, аның юлы уңачак, дигән ышану йөри. Ә суга гадәттә әниләр йөри. Аларның кешеләргә мөлдерәмә сулы чиләкләр белән очравы очраклы түгел. Чөнки ана күңеле гел яхшылыкта. Кол Гали сурәтләгән коллыктан котылып кайтучы Бәшир дә әнисе белән су янында очраша.

Әбием сөйләве буенча, суны савытның авызыннан (чиләккә, кисмәккә башыңны тыгып), китегеннән эчәргә ярамаган. Чөнки савытның китегенә кер җыела, ә савытның сабы – шайтан утыра торган урын. Әгәр эчәргә савыт тапмасаң, кулың белән эч. Суны

чиста савыт белән алырга һәм өстен каплап сакларга кирәк, юкса шайтан төкереп китә. Суны кирәк кадәр генә тотарга кирәк, артыгын тоту – суга карата мәрхәмәтсезлек саналган. Дин буенча да суны гөрәнкәләп (400 гр.) тотканнар. Мунча юынганда, көндәлектә артык су тоту гөнаһ санала.

Халыкта, суның кадере чишмә корыгач беленә, дигән мәкаль бар. Суны кадерләп тотмау Су ияләренә ошамаган. Алар елга-күлләрне, кое һәм чишмәләрне корытканнар, җәй көннәрендә кешеләрне корылык белән тилмерткәннәр. Мондый очракларда халык су буйларына килеп, яңгыр сораган, бер-берсен су белән коендырган. Су буенда бергәләп ботка пешереп ашаганнар, соңыннан ботканы  Су ияләренә ,,корбан” итеп биреп, аны шәфкатьләндергәннәр. Хәзер корылык булганда, иртәнге намаздан соң авыл бабайлары мулла белән басуга чыгып дога укыйлар, ходайдан яңгыр сорыйлар. Ә көндезләрен бала-чага урта яшьтәге апа-абыйлар белән чирмәнчекле уйный. Бу йола мәктәбебездә ел саен үткәрелә. Җәйге каникулда мәктәп лагеренда ял итүче балалар Нептун көнен (Чирмәнчек) үткәрәләр.

Яңгыр, яу, яу,
Майлы ботка бирермен.
Майлы ботка казанда,
Матур кашык базарда.

Яңгыр, яу, яу,
Кара сарык суярмын,
Суйгач, ботын куярмын,
Тәти кашык бирермен.

Йомгаклап, шуны әйтергә кирәк: татар мифологиясе – татар халык иҗатының бик борынгы, бай һәм үзенчәлекле өлкәсе. Аны өйрәнү, шул исәптән су белән бәйле ышанулар, йолы-ырымнарны да, мөһим нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә.

## Әдәбият исемлеге


1. Әдәбият: татар урта гомуми белем мәктәбенең 7 сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия / Ф.М. Хатипов, Ф.Г. Галимуллин. - Казан: Татар. кит. нәшр., 2001.
2. Әйтем – чәчәк, мәкаль – җиләк. Халык афоризмнары. - Казан: Мәгариф, 2002. – 2 китап.
3. Бакиров М.Х. Татар фольклоры / М.Х. Бакиров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008.
4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005.
5. Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, имтомнар, сынамышлар, йолалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996.
6. Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары. - Казан: Татар кит. нәшр., 1980.
7. Урманче Ф.И. Татар халык иҗаты / Ф.И. Урманче. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.
8. Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар.- Казан: Татар. кит. нәшр., 1987.



**Р.Р. Гатауллин**

Г. Ибраһимов исемендәге

Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан


## УРАЛ АРТЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНЕҢ ТАТАРЛАР ТАРАФЫННАН ҮЗЛӘШТЕРЕЛҮЕ

Курган һәм Чиләбе өлкәләрендә борын-борыннан халкыбызның үзенчәлекле берничә төркеме гомер кичерә. Чиләбе, Троицк шәһәрләре татар халкының бай мәдәни һәм икътисади үзәкләреннән саналып килә [3]. Бу яклар бик борынгы заманнардан ук татар халкының үз туфраклары булып исәпләнә. Билгеле булганча, Урал арты, Көньяк Урал төбәкләре, Көнбатыш

Себер иңкүлеге кешелек цивилизациясе бишекләренең берсе булып санала. Тарихчылар, бу җирләрдә б.э.к. 2 000 нче елларда ук инде төрле кабиләләрне берләштергән уртак мәдәни берлек булган, дип саныйлар [2].

Кешелек мәдәнияты тарихында тирән эз калдырган бу халыкларның бер өлеше төрки кабиләләр булганнар дип әйтергә ныклы дәлилләр бар. Көнбатыш Себер һәм Урал арасындагы урманлы, далалы киңлекләр б.э.к. III гасырдан башлап һуннар, IV гасырдан - Бөек Төрки, VIII гасырда - Уйгыр, IX гасырда Кыргыз каганатлары составында була. IX -X гасырларда бу географик төбәкнең көньяк өлеше кимак һәм кыпчаклардан торган Кимак каганатына керә. Ләкин төрки кабиләләрнең шактый зур өлешенең бу җирләрдә безнең эрага кадәрге чорларда ук яшәүләре билгеле.

Алтын Урда чорында себер татарлары составына казан-урал татарлары да күпләп кушыла башлый. Себер татарлары тарихын махсус өйрәнүче Г. Фәйзрахмановның әйтүенә караганда [2], себер һәм казан татарлары арасындагы мөнәсәбәтләр Ибак һәм Күчүм ханнар вакытында аеруча көчле була. Димәк, казан татарларының Урал арты, Көньяк Урал, Көнбатыш Себер туфракларына күчеп утырулары Казан ханлыгы җимерелгәннән соң гына башланган дип сөйләү тарихи чынбарлыкка туры килеп җитми. Бу уңайдан, Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, Казан татарларының күп өлеше үзләренә тел, дин, тормыш-көнкүреш үзенчәлекләре ягыннан бик якын булган себер татарларына килеп кушылуының икенче этабы турында гына әйтергә мөмкин.

Биредә шуны искәртеп китү дә әһәмиятле: Иртыш һәм Тура буенда яшәгән себер татарлары беренчеләрдән булып XI гасырның азагы - XII гасырның башларында бу җирләрдә бик борынгы заманнардан ук яшәп килгән төрки кабиләләр белән бергәләп үзләренең беренче дәүләтләрен корып җибәрәләр. Себер татарлары аны “Себер йорты” дип атап йөртә башлыйлар. Шулай итеп, Көнбатыш Себердә яшәгән себер татарлары һәм Урал

төбәгендәге халыкларның тарихында тирән эз калдырган Себер ханлыгы барлыкка килә. Ханлык территориаль яктан Көнбатыш Себер иңкүлегенең шактый зур өлешен алып тора. Бу дәүләт төньяк-көнбатышка Урал таулары аша Кама елгасына кадәр барып чыга, казан татарлары һәм башкортлар яши торган төбәкләрне үз эченә алып, Казан ханлыгының чикләренә кадәр барып җитә.

XVI гасыр урталарында ханлыкның көнбатыш өлешендәге халыкның бер өлеше утрак тормыш белән яшәгән була. Ханлыкның көнбатыш чикләрендә себер татарлары казан татарлары һәм башкортлар белән аралашып яши. Бу төбәктәге татарларның Казан ханлыгыннан Себергә олы юл булуы, күпчелек татар авылларның шушы юл буйлап урнашулары халык арасында сакланып калган риваятьләрдә дә әйтелә. Курган һәм Чиләбе өлкәләрендә яшәүче татарларны, шушы юллар буйлап яшәүләренә карап, күп кенә тарихи язмаларда һәм архив материалларында "себер юлы татарлары" дип атап йөртү гадәткә кергән була. 1581 елда Себер ханлыгына каршы башланган Ермак походлары да шушы юллар аша үтә. Каты сугышлардан соң, халыкның күп өлеше Көнбатыш Себернең көнчыгыш төбәгенә, урманлы-сазлы өлешенә күчеп утыра. Шулай да халыкның бер өлеше туган туфракларында яшәп кала. Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, бу якларга күчеп килгән казан татарлары беренче чиратта шул авылларга килеп утыралар. Халык санын алу кенәгәләрендә бу авылларда яшәүче татарлар, башка төркемнәр кебек үк, махсус рәвештә аерып, "себер татарлары", "элеккеге себер ханлыгы токымы", "күчем токымы" дип күрсәтелә торган булганнар.

Татарларның мөстәкыйль халык булып формалашкан җире – Идел һәм Урал буйлары. Бу җирләр халкыбызның бик борынгы гасырлардан бирле тарихи ватаны булып санала. Төрле фаҗигале сәбәпләр аркасында дөньяның төрле почмакларына таралырга мәҗбүр булса да, татарларның иң күп өлеше бүгенге көннәрдә дә

Урта Идел, Түбән Кама һәм Урал алды географик төбәгендә яши. 1989 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча, Татарстанда – 1765404, Башкортстанда 120702 татар исәпләнә. Статистика материаллары Башкортстан татарларының аз булса да арта баруын күрсәтә. 1997 елгы мәгълүмат буенча, аларның саны 1 миллион 186,2 меңгә җиткән. Шуның белән бергә, биредә халыкның бер өлеше, башкорт булып язылса да, үзенең туган теле итеп татар телен саный. Моннан тыш татар авыллары Татарстан һәм Башкортстан белән күрше булган милли республикаларда һәм өлкәләрдә тоташ массив булып урнашканнар. Бу бигрәк тә Урал алды, Урта, Көньяк Урал, Урал арты территорияләре өчен хас.

Архив материалларында һәм тарихи әдәбиятта ул заманнарда бу территориядә яшәгән татарларның бер өлеше ясаклы татарлар, казан татарлары, казан кешеләре, казанлылар, Уфа (Өфе) татарлары, типтәрләр, бобыльләр, мишәрләр, мишәкәрләр, йомышлы татарлар, мещаннар, башкортлар, чын башкортлар, яңа башкортлар дигән исемнәр белән аталып йөртеләләр. Этник мишәрләр исә төмәннәр (Темников өязеннән килгәннәр), алатырлар (Алатырь өязеннән килгәннәр) һ.б. исемнәр белән күрсәтеләләр.

Урал төбәкләрендә татарларның яшәүләрен Казан ханлыгының руслар тарафыннан яулап алуы белән генә аңлатырга ярамый. Кызганычка каршы, Урал төбәкләрендә яшәүче татарларны Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, Идел буе өлкәләреннән күчеп килүчеләр итеп кенә аңлату тенденциясе бүгенге көннәрдә дә яшәп килә. Ләкин икенче төркем тарихчылар исә, бу бигрәк тә XVIII гасырда иҗат иткән рус галимнәренә карый, татарларны бу якларда бик борынгы заманнардан ук яшәп килгән җирле халык итеп аңлаталар.

**Әдәбият исемлеге**

1. Рамазанова Д.Б. Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии / Д.Б. Рамазанова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984.

2. Файзрахманов Г.Л. История сибирских татар (с древнейших времен до начала XX века) / Г.Л. Файзрахманов. – Казань: Фэн, 2002.

3. Юсупов Ф.Ю. Сафакүл татарлары: тарих, тел, халык иҗаты / Ф.Ю. Юсупов. – Казан, 2006.

**Л.З. Гаянова**
Кукмара 4 нче урта гомуми
белем бирү мәктәбе

## ЯШЬЛӘРГӘ ТӘРБИЯ БИРҮ ЫСУЛЫ БУЛАРАК КУКМАРА ТӨБӘГЕНДӘ УЙНАЛА ТОРГАН КИЧКЕ УЕННАР

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә уенга “күңел ачу, ял итү шөгыле” дигән билгеләмә бирелә [4, б. 207]. Алай гынамы икән? Уенның бит тәрбияви, иҗтимагый, эстетик вазифалары да бар. Ул – кешелек җәмгыятенең үсеш дәверендә хезмәт формаларын чагылдыру рәвешендә барлыкка килгән, яшь буынны физик һәм әхлакый, эстетик яктан тәрбияләү һәм көнкүрештә берәр эш-шөгыльне, йоланы үтәү вазифасын башкаручы мавыктыргыч чаралар системасы.

Халкыбызның гореф-гадәтләрен саклаган уеннар бик күп: Нәүрүз бәйрәме, Каз өмәсе, Нардуган, Аулак өй уеннары, Кичке уен, Сабантуй һ.б.

Күңел ачу гадәтләренең күбесе авыл җирендә хуҗалык эшләре барышы белән бәйләнгән. Язгы кыр эшләре беткәч үткәрелә торган Сабан туе бәйрәме күп кенә уеннарның барлыкка килүенә җирлек булган. Мондый бәйрәмнәрне бигрәк тә яшьләр сагынып көтеп алган, чөнки авылга кунак кызлары килгән, “бәхет

эзләргә” киткән шахтер егетләр кайткан. Бәйрәм көннәрендә егетләр, кызлар бер-берсе белән танышып аралаша алганнар, күмәк уеннар оештырып ял иткәннәр. Ә очрашу урынын безнең Кукмара ягында “уенлык” дип атыйлар. Аңлатмалы сүзлектә дә: “Уенлык – яшьләрнең бергә җыелып, җырлап, биеп уйный торган урыннары”, - диелә [4, б. 604]. Башка әдәбиятта мондый уеннарның “Кызтау”, “Кыз каласы” дип аталуы турында язылган [5, б. 19].

Уенның характерына, башкару үзенчәлегенә карап, уен-бию җырларын М.Х. Бакиров ике төргә бүлә: 1) кара-каршы сафларга тезелеп башкарыла торган җырлар һәм 2) әйлән-бәйлән яки түгәрәк җырлары [3, б. 329]. Ә “Татар халкының бәйрәмнәре һәм йолалары” китабында Рәүфә Уразманова яшьләр уенын, кайчан һәм ничек үткәрелүенә карап, 6 вариантка бүлә [9, б. 69].

Кичке уеннар кыр эшләреннән азмы-күпме бушаган вакытта – чәчүдән соң, печәнгә төшкәнче - аяз кичләрдә үткәрелгән. Уеннарда һәр авылның үз башлап җырлаучысы, кешесенә карата куплетлар чыгаручы җор телле чичәннәре булган. Берәү дә читтә ялгызы моңланып тормаган. Сабантуй вакытларында Кукмара төбәгендә өлкән буын кешеләре, кичләрен яшьләрне җыеп, бу уеннарны әле дә уйныйлар. Бәйрәм атнасында Сәрдекбаш һәм Уразай авылындагы болынлыкта яше-карты кичке уенга җыйнала. Бирегә мондый көннәрдә, машиналарга төялеп, тирә-як авыллардан да бик күп яшьләр килә. Чөнки бу традиция бүгенге көнгәчә шушы авылларда гына сакланып калган. Җәйге кичке болынлык халкыбызның буыннан-буынга килгән дәртле уеннары шавына күмелә. Өлкән буын кешеләре яшьлекләрен искә алса, яшьләр шушы традицияләрдә тәрбияләнеп, эстафетаны дәвам итәргә өйрәнәләр. Бу уеннар күңел ачуга гына кайтып калмый, ә яшьләр өчен тәрбия чарасы да булып тора.

Кукмара районының Уразай авылында яшәүче Наилә апа Сәгъдиева үзләре яшь чакта уйнаган кичке уеннары, җырлаган җырлары турында шактый мәгълүмат бирде. Аның сөйләвенчә,

кичке уенда һәркемгә атап җыр җырланган. Җырны кешенең кем булуына, авылда аның турында нинди фикер йөрүгә карап сайлаганнар. Һәркем үзе турында яхшы җыр ишетергә теләгән. Ләкин тискәре сыйфатлары булган кешегә шул сыйфатларын яманлаган җырлар җырланган. Мондый җырлар “Татар халык иҗаты” сериясеннән булган “Кыска җырлар” томында чәнечкеле-шаян җырлар рәтенә кергән. Анда дүртьюллыклар бирелгән. Ә Кукмара төбәгендә өчьюллык уен җырлары да булган һәм ул җырларда кешенең исеме дә яңгыраган. Мәсәлән, бик күп кызлар артыннан йөргән егетләргә мондыйрак уен җырлары җырланган:

Исемнәре – Биктимер,
Ярларыңны җепкә тезеп,
Клиндер итеп кимер.

Кибетченең метры,
Менә шушы була инде
Кунак кыз директоры.

Исемнәре – Әхәтме?
Берсен башлап, берсен ташлап
Сөюләре рәхәтме?

Тәлинкә төбе тишек,
Кичә озаткан ярыңның
Фамилиясе ничек?

Яшел шарф муеныңда,
Килгән-киткән кунак кызлар
Бар да синең куеныңда.

Тау башында алачык,
Ярларыңны җепкә тезеп,
Базарга сатарга чык.

Түбән очның зираты,
Бүген кемгә калды инде
Капка төбе чираты?

Исемнәре - Герасим,
Туксан тугыз яр сөясең,
Настоящий дурак син.

Икенче уенда мондый җыр ишетмәс өчен егетләргә, әлбәттә, тәртипләрен үзгәртергә туры килгән. Бу әхлакый тәрбия чарасы да булып торган.

Сөйгәннәре армия сафларында булган кызларның да кайсына юату сүзе, кайсына кисәтү сүзе багышланган:

Армиядә – сафларда.
Син аны көтәргә тиеш,

Армиядә бит әле,
Тагын бер ел, тагын бер ел,

Карамыйча ятларга.

Ике еллап көт әле.

Ботинкаларым тая,
Миннехәйга биреп куйган,
Вәгъдәләрең кайда?

Граница саклый ул,
Сагынсаң да, саргайсаң да,
Ике елсыз кайтмый ул.

Тәртипле кызларга да кирәкле киңәшләрне җырга салып җиткергәннәр:

Чәчең озын, бер метр.
Сөям дигән егетләргә,
Серләреңне бирми тор.

Агыйделдән сал килгән.
Юк авылда, юк шәһәрдә
Синең белән пар килгән.

Бу өчьюллыкларда татар хатын-кызында булырга тиешле күркәм сыйфатлар, эчке һәм тышкы матурлык чагыла. Сөйгән кешеңә тугрылык, вәгъдәдә тору, сер бирмәү һ.б. сыйфатлар уен җырлары аркылы мактала.

Кыюсызлардан да рәнҗетмичә генә көлеп алганнар:

Исемнәре – Барбарый.
Кызлар үтеп киткән чакта,
Капка астыннан карый.

Әбинең сарафаны,
Син дә мондамыни әле,
Мич асты тараканы?

Амбарның борчаклары,
Уйнамагач, ник килдегез,
Магазин курчаклары?

Исеме - матур Вакыйп.
Кесәңә ислемай тыгып,
Кызлар эзләргә вакыт.

Түбәндәге тәрбияви куплетларда юмор гына түгел, сарказм да сизелә. Яшьләр бер-берсеннән ачы итеп көлеп тә җырлаганнnар. Мәсәлән:

Исемнәре – Зөбәйдә,
Сөйгән ярың бер дә күрми,
Рәхәтләнеп йөр әйдә.

Исемнәре – гөлҗимеш,
Кулын кесәсенә тыккан,
Министр булган, имеш.

Исеме – матур Сара,
Ярым монда түгел, димә,
Икенче ярлар кара.

Атар әле чия дә,
Берсе килә, берсе китә,
Берсе комиссиядә.

Очып йөри күбәләк,
Икегез дә монда бугай,
Сезнең дөнья түгәрәк.

Чабатасы, катасы,
Сөйгән ярың монда түгел,
Кайтасы да, ятасы.

Исемнәре – Илсөя,
Матур кызлар шулай була,
Яр өстенә яр сөя.

Төягәннәр әрҗәләр,
Үзең монда, ярың кайда,
Дип кычкыра кәҗәләр.

Ботинкасы лаковый,
Йөрмә капка төпләрендә,
Имән күсәк готовый.

Тәрәзәләр парлана,
Төнге өчтә кайта, диеп,
Синнән анаң зарлана.

Ботинкасы иллеле,
Авторитетлы егетнең
Гәүдәсеннән билгеле.

Машинасы ватыктыр,
Инде сиңа, абзыкаем,
Өйләнергә вакыттыр.

Исемнәре – Люция,
Кирәк безгә уйнаучы,
Кирәкми комиссия.

Исемнәре – Хәдичә,
Ничә сәгать сөйләштегез
Капка төбендә кичә?

Юмор – безнең халыкның табигатендә. Хәсрәтле уйлар, борчулар, тормышта еш кына уен-көлке белән, көр күңелле мәзәкләр, шаян сүзләр, җырлар белән аралаша. Күргәнебезчә, шаян җырларга кешеләрдәге кимчелекләрне тәнкыйть итү хас. Ул мәхәббәткә җиңел караучы “чуар йөрәк”ләрдән, “магазин курчаклары”ннан, “министр кебек” йөрүче тәкәббер, мактанчыклардан үткен көлә. Халык үзенең чәнечкеле, төртмәле җырлары белән мәхәббәтнең сафлыгын, тугрылыкны һәм рухи гүзәллекне расларга омтыла, дустанә ачы тел белән әйтелгән тәнкыйть ярдәмендә әхлакый тәрбия бирә [6, б. 24].

Кичке уенлыкта уйнала торган уен төрләре шактый. “Йола һәм уен җырлары” китабына [5] кертелгән уеннарның күбесе

Кукмара төбәгендә дә уйналган. Мәсәлән, “Йөзек салыш”, “Ша” уены, “Буяу сатышлы”, “Челтәр элдем читәнгә”, “Чума үрдәк, чума каз” кебек уеннарны яшьләр бик яратканнар. Тик кайбер уеннар Кукмара төбәгендә башкача аталган, такмаклары да башкача булган. Мисал өчен, китаптагы “Өлгерсәң өлгер” уены бездә “Гөлбану”, “Җимчәчәк” уены - “Назалы” дип йөртелә.

*“Назалы” уены* түбәндәгечә уйналган. Яшьләр җитәкләшеп, икешәр булып, берсе артыннан берсе басалар. Берәү так кала. Ул тезелгән парларның алдына аларга карап баса. Так калган кешегә “төрттереп” бер куплет җыр җырлыйлар. Бу вакытта җитәкләшкән куллар җыр темпына чайкалалар. Аннан соң кушымта җырлана. Уен дәвамында кушымта бер үк төрле була. Кушымтаны җырлаганда, алда басып торган так кеше, парларның берсен аерып алып, үзе аны җитәкләп, уртадан алып чыгып китә (тотышкан куллар бу вакытта аерылып юл бирәләр), һәм алар, иң соңгы пар булып, артка җитәкләшеп басалар. Ә так калганы тагын парлар алдына чыгып баса. Уен шулай дәвам итә. Кушымталар түбәндәгечә булырга мөмкин:

Ай-ли, машина,
Шоферы кабындыра,
Кемнәрең бар, кемне уйлыйсың,
Кемнәрең сагындыра?

*“Бормалы” уенында* яшьләр, кулга-кул тотышып, каракаршы тезелеп басалар. Берәү так кала. Парлыларның куллары “Бормалы су” җыры көенә кара-каршы чайкала. Җыр барышында так калган кеше, кем каршына басып җырлыйсы килсә, шуның артына басып, биленнән тота һәм үзенә таба бора. Каршы яктагы пары так кеше булып чыгып китә, ә болары, яңа пар булып, каракаршы басалар. Так калганы янә үзенә пар сайлый. Җыр өзлексез дәвам итә. Уйнап туйгач кына туктыйлар.

*“Чупләмле” уенында* да парлар, бераз ара калдырып, каракаршы басалар. Бию көе уйнала. Иң беренче булып басып торган парлар бер-берсе белән тотышып әйләнәләр. Аннан соң һәр икесе биеп барып, үзләренең рәтендәге үзләре янында торган кешене әйләнергә алалар. Аннан соң тагын икесе бергә әйләнәләр. Шул рәвешчә, чират буенча әле кырыйдагы кеше белән әйләнеп, әле икесе бергә әйләнеп, рәт ахырына кадәр барып чыгалар һәм, соңгы пар булып, ике якка басалар. Болар белән әйләнгән һәркем яңадан үз урынына барып баса. Уен арыганчы дәвам итә. Бу уен сәламәтлеккә уңай йогынты ясый: күңел күтәренкелеге белән хәрәкәт активлыгы булдыра; җиңеллек, үз гәүдәңне дөрес тоту, тиз ориентлашу, игътибарлылык тәрбияли.

*“Биш парлы”* уенына җитәкләшкән ун кеше, ягъни биш пар, кирәк. Парлар, бер-берсеннән шактый ара калдырып, уңга, сулга, алга, артка басалар. Алар барысы да уртада калган парга карап торалар. Бию көе уйный башлагач, уртадагы парлар үзләре каршындагы парның җитәкләшеп (капка ясап) күтәрелгән куллары арасыннан биеп чыгалар. Уртада башка пар кала һәм ул пар да үз каршысындагы пар белән шул ук хәрәкәтләрне кабатлый. Өч пар шулай өзлексез бию көенә “йөгерә”. Көй кинәт туктый. Бер пар уртада басып кала. Һәм ул пар уйнамыйча торган ике пар белән уенны дәвам итә. Тагын гармун туктый. Шулай уен дәвам итә. Әгәр бер үк пар уртада өч тапкыр калса, ул җәза үти (җырлый, бии һ.б.).

Гомумән, халыктагы кичке уеннар – күңел ачу һәм ял итү традицияләре белән тыгыз үрелгән поэтик байлык. Алар бүгенге көн өчен эстетик кыйммәткә ия булган кадерле мирас. Шуңа күрә әлеге уеннарны яшь буынга өйрәтеп калдыру – безнең бурыч. Моны мәктәп бусагасындагы балаларга өйрәтүдән үк башларга кирәк. Озын тәнәфесләрдә, физкультминутларда, төрле кичәләрдә файдалану уңай нәтиҗәләр бирер иде. Беренчедән, бала халык көйләре белән таныша; икенчедән, бию хәрәкәтләрен өйрәнеп кенә калмыйча, сәламәтлеген ныгыта; өченчедән, хәтерен дә ях-

шырта; дүртенчедән, әхлакый яктан тәрбияләнә; бишенчедән исә, бу уеннар аның күңеленә гомергә сеңеп кала һәм ул аны киләчәк буынга тапшыра ала.

## Әдәбият исемлеге


1. Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. А.Г. Әхмәдуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 192 б.
2. Әдәбият: татар урта гомуми белем мәктәбенең 6 сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000.
3. Бакиров М.Х. Татар фольклоры / М.Х. Бакиров. – Казан: Мәгариф нәшр., 2008.
4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты нәшрияты, 2005.
5. Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары. - Казан: Татар кит. нәшр., 1980.
6. Татар халык иҗаты. Кыска җырлар. - Казан: Татар. кит. нәшр., 1976.
7. Татар халык иҗаты: хрестоматия. – Казан: Мәгариф нәшр., 2005.
8. Татар халык уеннары. – Казан: Раннур нәшрияты, 2002.
9. Уразманова Р.К. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре / Р.К. Уразманова. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1992.
10. Урманче Ф.И. Татар халык иҗаты / Ф.И. Урманче. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.

**С.М. Гыйльманова**
Чистай шәһәренең 2 нче гимназиясе

# РУХИ ЯДКӘРЛӘР

Һәр халык мәдәни, тарихи, әхлакый һәм башка байлыкларга ия. Әлеге байлыклар һәрберебезнең туган төбәгендә бихисап. Халкыбыз тарихын өйрәнү, аның мәдәни байлыгы турында күзаллау булдыру укучыларга ул яшәгән республика, шәһәр, район, авыл тарихы турында мәгълүмат бирүдән башлана. Халкыбызның язмышы, киләчәге бүгенге яшьләрнең нинди шәхси сыйфатларга ия булуына бәйле. Безнең укучыларыбыз үзләре басып йөргән туфракның, эчкән суларның һәм сулаган һаваның нәрсә икәнлеген белеп, аларны кадерләргә, сафландырырга, халкыбызның рухи кыйммәтләрен барлап, алга таба аларны тагын да баетырга һәм камилләштерергә, милләт язмышын уңай хәл итәргә хәзерлекле булып үсәргә тиешләр. Укучыларда шушы сыйфатларны үстерү һәм милли үзаң тәрбияләүне күздә тотып гимназиядә „Этнографик музей“ эшли. Анда тупланган материаллар – үзе бер тарих. Алар халкыбызның, төбәгебезнең үткәнен тирәнрәк аңларга ярдәм итә.

Музеебыз өч экспозицион өлештән тора. Беренчесе – халкыбызның үткән тормышыннан җыелган экспонатлар. Хронологик яктан ул үз эченә XIX гасырның ахырын – XX гасырның 30нчы елларын ала. Укучылар төрле экспонатлар алып киләләр, алар белән танышалар, тарихын эзлиләр, кадерләп сакларга өйрәнәләр.

Халыкның матурлыкка омтылуы, үзенең рухи байлыгына хәзинә итеп каравы, аны кадерләп саклавы, үстерә һәм буыннан-буынга тапшыра баруы һәркайсыбызда милли горурлык хисе уята.

Матурлык төшенчәсе күпкырлы. Ул телебезнең байлыгында, матурлыгында чагыла. Өлкәннәрнең сөйләме, телгә сакчыл

булуы, сөйләү-сөйләшү рәвеше, әкиятләре, көйләгән җырлары, бәетләре, табышмаклары, мәзәкләре - туган телебезнең күркәм үрнәкләре. Укучылар белән Чистай төбәгеннән тупланган бишек җырларын тәкъдим итәбез.

Әлли-бәлли итәр бу,
Хәзер йоклап китәр бу.
Үсеп галим булгачтын,
Күлмәк бүләк итәр бу.

Әлли-бәлли итсен бу,
Ак бишектә ятсын бу.
Баллар ашап, майлар ашап,
Рәхәт гомер итсен бу.

Әлли-бәлли итәр бу,
Армиягә китәр бу.
Әтисенә, әнисенә
Изге хезмәт итәр бу.

Әлли-бәлли итәр бу,
Үсеп буйга җитәр бу.
Үсеп буйга җиткәчтен,
Ил сакларга китәр бу.

Әлли-бәлли итәр бу,
Кызым йокыга китә.
Әнкәй мәми пешереп,
Әткәйне эштән көтә.

Әлли-бәлли итә ул,
Тар бишектә ята ул.
Мәми ашап туя ул,
Елауларын куя ул.

Кызым, кызым – кыз кеше,
Кызыма килгән йөз кеше.

Йөз кешенең арасыннан
Сайлап алыр бер кеше.

Әллиһу-бәллиһу,
Кәҗәләрне талга ку.
Кәҗә талны кимерсен,
Улым йоклап зур үссен.

Әллиһу-бәллиһу
Кәҗәләрне талга ку.
Тал яфрагы селкенсен,
Кызым йокыга китсен.

Бу җырларны Алинә Егорова җыеп алган: “Бишек җырларын мин Чистай районы Татар Баганалысы авылында яшәүче дәү әнием - Сираева Флюра Талип кызыннан язып алдым. Ул шушы бишек җырларын көйләп 4 бала тәрбияләп үстергән”.

Сафиуллина Алия Чистайда яшәүче әбисеннән язып алган:

Әлли итәргә кирәк,
Бәлли итәргә кирәк.
Әлли иткәч, бәлли иткәч,
Йоклап китәргә кирәк.

Әлли-бәлли бәпкәсе,
Кая киткән әнкәсе.
Каенлыкка җиләккә,
Бәпкәсенә бүләккә.

Әлли-бәлли бәү итә.
Кызым йокыга китә.
Тәмле итеп йоклагач,
Матур булып зур үсә.

Гимназиябездә халык җәүһәрләрен җыю эше дәвам итә.

**Г.М. Демухаметова**
ТР Кукмара поселогының
3 нче урта гомумбелем бирү мәктәбе

# ТУГАН ЯГЫМ АТАМАЛАРЫ ҺӘМ АЛАР БЕЛӘН БӘЙЛЕ ХИКӘЯТЛӘР

Уйлап карасаң тарих чын мәгънәсендә халыкның изге китабы, көнкүреш һәм эшчәнлек көзгесе, ата-бабаларның мирасы һәм киләчәккә сабак. Тарихны язу – ул энә белән кое казу. Авылның үткәне турында язма чыганаклар юк диярлек, чөнки аларны язып баручы булмаган. Бердәнбәр чыганак – өлкән яшьтәгеләрнең истәлекләре, хәтерендә калганнары, буыннан-буынга сөйләнеп килгән хатирәләр, вакыйгалар.

Безнең мәктәптә тарихи төбәкне өйрәнү укыту процессын тормыш белән бәйләүдә иң мөһим чараларның берсе булып тора. Тарихи төбәкне өйрәнгәндә авылның микротопономиясенә зур игътибар бирелде. Исемнәрне өйрәнү, теге яки бу географик атаманың килеп чыгуы белән кызыксыну бик мавыктыргыч.

Тел белеменең ономастика дип йөртелә торган бер тармагы бар. Бу фәннең тикшерү өлкәсе ифрат бай һәм кызыклы. Ул кеше исемнәрен, фамилияләрне һәм кушаматларны, күп җисемнәрнең һәм географик урыннарның, шул исәптән елга-суларның, мифологик затларның риваятьләрдәге исем-атларын өйрәнә. Ономастика шундый күпсанлы һәм төрле-төрле исемнәрне җыю-туплау, тәртипкә салу, аларның килеп чыгышын, тарихи җирлеген аңлату кебек мөһим бурычларны гамәлгә ашыра. Ономастика фәнендәге табышлар һәм казанышлар тел тарихын өйрәнүдә генә түгел, бәлки халыкның этник тарихын яктыртуда да зур әһәмияткә ия.

Бу фәннең географик бердәмлекләрне өйрәнә торган өлкәсе топонимика дип атала. Ә топонимиканың бер тармагы гидронимика дип йөртелә. Барлык төр су чыганакларының – елга, күл, инеш, чишмә, сазлык, күпер һ.б. атамаларын гидронимнар диләр.

Алар жир йөзендә иң күп таралган атамалар, гидронимнарга бәйле бик күп кенә авыл, шәһәр һ.б. географик объектларны очратырга була [1].

Тарихка күз салсак, иң борынгы заманнардан ук кешеләр су буйларына урнашкан, шунда тормыш корган, хуҗалыгын алып барган. Кукмара районы Кәркәвеч авылы да нәкъ менә шундый гүзәл урынга урнашкан. Тау итәгендәге авыл урман-суларга да бай.

Тарихи чыганакларда Кәркәвеч авылы 1710 – 1711 еллардан билгеле.1860 елларга кадәр аның халкы крестьяннар катламына караган. Алар җир эшкәрткәннәр, терлек үрчеткәннәр. XX гасыр башында мәчет, тегермән, ярма яру җайланмасы, 5 кечкенә сату почмагы булган. Авылның Кләвеш өязенә, Мамадыш кантонына, Кукмара, Саба, Тәкәнеш районнарына керүе билгеле. 1965 елдан бүгенге көнгә кадәр Кукмара районына керә. Авылда 1782 елда 39 кеше, бүгенге көндә 375 кеше яшәве билгеле.

Иң беренче булып Чуллыдан Морадулла дигән кеше тау өстенә килеп урнашкан. Аның янәшәсенә акрынлап башка кешеләр дә килеп төпләнгән. Алар тау башында торганнар, чөнки аста сазлыклар булган. Ләкин әлеге урында яшәү авыр, анда мөмкинлекләр булмый. Сазлыклар кипкәч, әкренләп үзәнгә елга буена беренчеләрдән булып  Потапов дигән рус кешесе килеп урнашкан. Авылның Кәркәвеч дигән атама алуы да шушы кеше белән бәйле һәм бу хакта түбәндәге хикәят тә яши:

Потапов Шөн елгасын будырып тегермән салдыра һәм анда керкә балыклары күч-күч булып йөрүен күрә. Үзе дә сизмәстән: “Керкәкүч, керкәкүч,” - дип кабатлый икән. Шуннан чыгып авыл башта Керкәкүч, ә соңрак Кәркәвеч дип үзгәртелә. Соңрак Потапов берничә вак чишмәчекләрне берләштереп чишмә ача. Бу чишмә аның исеме белән “Путап чишмәсе” дип йөртелә.

Тагын бер атама - Шәпи юлы. Әлеге юл авылны тау кырыена урнашкан урман белән тоташтыра. Бу юл белән бәйле хикәят тә бүгенге көндә өлкәннәрдә яшәп килә:

Имеш Шәфигулла исемле кеше, урманда озак тоткарланып, караңгы төшкәч кенә авылга кайтырга чыга. Юлны таба алмый изалана. Суыкта, буранда шушы сукмакта үлеп кала. Ул үлгәннән соң бу юлны Шәпи юлы дип атап йөртә башлыйлар.

Сапый урамы - бу урамга беренче Сафа исемле кеше килеп урнашкан. Сафа абзый анда кирпеч суккан. Бүгенге көндә анда әлеге нәселнең бер буыны гомер сөрә. Бер урамны кутыр дип атыйлар. Ул "Хутор" дигән сүздән алынган, чөнки бу урам башкаларыннан Шөн елгасы белән аерылып тора.

Авылның көньягы кечкенә яссытаулыклардан тора. Аның урманга якын биегрәк урынын "Куян атавы" дип атыйлар. Бу атама әлеге урында куяннарның күп булуыннан барлыкка килгән.

Тагын бер истәлекле урын – бакыр базы. Ул урыннан бакыр тапканнар һәм хасил булган чокырга әлеге атаманы биргәннәр.

Олы юл белән генә аерылып торган авыл - Бурсык елга. 1720 - 1730 елларда бер төркем мөселманнар урман аланлыгына килеп йорт-җир салганнар. Калкулыкта урнашкан хуҗалык сазлыклар кипкән саен түбәнрәк урыннарга күченгәннәр. Халык аучылык, җир эшкәртү, терлек үрчетү белән шөгыльләнгән. Сазлыкларда бурсыкларның күп булуыннан авылга әлеге атама тагылган.

Әлеге авыл белән бәйле кызыклы мәгълүматларны өлкәннәрдән ишетергә мөмкин. Шуларның берсе: бу авылга мөселманнар килеп төпләнгән. Ләкин Явыз Иван отряды бу авылга да килеп җиткән һәм андагы халыкны чукындырып өлгергән. Шуның нәтиҗәсендә авылда ике зират – мөселман һәм керәшен зираты. Мөселман зираты астыннан бер чишмә ага. "Изгеләр чишмәсе" дип атала ул. Аның суын кешеләр шифалы, бигрәк тә таң алдыннан алып кулланганы сихәтле диләр. Бу чишмәнең килеп чыгышы белән бәйле хикәят тә яшәп килә. Габдрахман Шәех дигән бик укымышлы авыл карты, үлгәч, төнлә булса да татар зиратына җирләүләрен үтенә, чөнки ул ничектер чукындырылудан котылып калган була. Картның сүзен тыңлыйлар. Таң алдыннан

аны шушы зиратка җирлиләр һәм гаҗәп хәлгә юлыгалар. Зиратта эшләрен тәмамлап, акрын гына зират кырыендагы таудан төшеп килгәндә челтерәп аккан су тавышы ишетеп алалар. Тавыш килгән якка барып карасалар, чишмә агып ята. Аны шушы изге карт хөрмәтенә “Изгеләр чишмәсе” дип атыйлар.

Тагын бер үзенчәлекле урын - “Ирекле чокыры”. Бу урында Сабантуй бәйрәмнәре, кичке уеннар уздырылган. Байлар җитештергән әйберләрен сатканнар. Кешеләр анда үзләрен ничектер ирекле һәм иркен тотканнар. Аның атамасы да шушы вакыйгалар белән бәйле ди картлар. Бу урында бүгенге көндә дә Сабантуй үткәрелә.

Татар халкы үткән тарихи юлны, көрәшләр, исемнәр, кушаматлар, нәсел агачларын (шәҗәрәләрне) өйрәнү киләчәк буыннарга зур мирас булачагын күренекле галим һәм фикер иясе Шиһабеддин Мәрҗани үзенең күпсанлы хезмәтләрендә әйтә килгән. Чын тарихыбызны белер өчен, мәгърифәтле бабаларыбызның акыллы фикерләрен сакларга тырышырга кирәк. Ә менә язылмаган тарихны, авылларыбыз тарихын барлап теркәп калу безнең үзебездән тора.

## Әдәбият исемлеге

1. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. - Казан, Татар. кит. нәшр., 1979.

**Ф. Х. Завгарова**
Республиканский центр развития
традиционной культуры, Казань

# ВОПРОСЫ ТЕКСТА И КОНТЕКСТА В СОВРЕМЕННОЙ ФОЛЬКЛОРИСТИКЕ

Проблема текста и контекста для современной фольклористики не нова. Еще в семидесятые годы XX века ряд ученых, как Б.Н. Путилов[8], Ю. М. Лотман [5] обратили внимание на многокомпонентность фольклорного текста. Продолжая суждений предшественников все чаще об этом стали говорить и такие ученые фольклористы современности как: С.Ю.Неклюдов [6], Т.Б. Дианова [2], В. Е.Добровольская [3], А.А. Иванова [4].

На протяжении долгого времени исследования в области фольклористики были сосредоточены, в основном, на изучении конкретных фольклорных текстов и на их совокупности как на единственно надежном материале, рассмотрение которого допускает достаточно убедительные процедуры получения выводов. Крупнейшие исследователи фольклорных явлений, как А. Веселовский [1], В. Пропп [7] и многие другие их последователи, изучавшие структурных составляющих текстов, в том числе и национальных фольклористических школ, работая над своими ставшими классическими трудами использовали для своих анализов корпус текстов устных традиций из собраний предшественников, причем никакие другие данные ими в данном случае не привлекались. Эти анализы, проведенные согласно поставленным целям разными методами, выглядят вполне самодостаточными, точнее, самодостаточным оказываются сами тексы, которые сами по себе уже содержат информацию, удовлетворительную для выявления структурных особенностей. Вообще, здесь необходимо отметить и такой факт, чем выше структурированность текста, тем более он «самодостаточен», в то время как слабо структури-

рованные тексты больше зависимы от прагматического и семантического контекста соответствующей культурной традиции. Например, в текстах сказки уже имеется достаточно сведений для ее понимания, и нет никакой необходимости выходить за их пределы. Конечно, внешние по отношению к ним данные (контекстные, социальные, психологические и пр.), в принципе, присутствуют и здесь, однако они неспособны существенно откорректировать те значения, которые «прочитываются» при восприятии текста.

Разумеется, когда речь идет об «избыточности» внетекстовой информации для морфологического (отчасти и семантического) анализа сказки, надо иметь в виду следующее обстоятельство. Сама возможность понимания текста обусловлена языковой и культурной подготовленностью слушающего, его «кодовыми» знаниями, которые предполагают извлечение из родовой памяти необходимых «ментальных репрезентаций» (мифокенетики, констант или концептов, мотивов и др), как и набора представлений, соотнесенных тем «возможным миром», в рамках которого производится расшифровка текста. При этом применительно к фольклорной сказке формирование соответствующего «возможного мира» будет происходить на основании комплекса все тех же сказочных текстов.

Ситуация меняется при обращении к прагматике текста. Так, определение жанра устного произведения только по его сюжетной структуре может привести к неточностям и даже к грубым ошибкам – именно потому, что не берется в расчет его функция, его культурный контекст. Впрочем, функция текста не может каким-то образом не отражаться на его морфологии, и более пристальный анализ позволяет обнаружить эти функционально обусловленные признаки текста. Особенно это касается обрядовых вербальных текстов, где морфологию текста, прежде всего, определяет его функциональное поле, четко регламентированное культурной традицией. Для примера обратимся к тексту обраще-

ния димче карчык (свахи) родителям девушки при ее обрядовом визите в дом девушки.

Ефәк баулы былбыл кош
Бардыр синең өеңдә.
Каеш баулы лачын кош
Бардыр минем илемдә.
Бохарадан ияр алган мин,
Юлым сиңа ярган мин.
Каеш баулы лачыным бар,
Былбылыңа килгән мин.
Тмер булсаң, мин – күмер,
Эретергә килгән мин. [9, с. 57]

(Соловей с шелковой тесьмой есть, наверное, в твоем доме. Сокол с кожаной тесьмой есть, наверное, в моем доме. Купив седло в Бухаре, я к тебе держу путь. Есть у меня сокол с кожаной тесьмой. За соловьем пришла я. Если ты железо, то я пришла расплавить тебя.)

Как видим, текст полностью подчинен функциональному полю ритуального обращения. Стилистическая, лексическая и морфологическая структура определена самим обрядовым контекстом. Без обрядового контекста данная вербальная структура теряет свой смысл и перестает восприниматься как текст. В то же самое время только культурная традиция обеспечивает данному вербальному образцу существовать как текст. Так как в данном контексте (имеется в виду сама вербальная формула и его обрядовая составляющая) присутствие участников ритуального диалога: свахи и родителей девушки предопределена самой культурной традицией и морфология текста поддерживается только их присутствием.

В свою очередь структурированность текстов связана с тем, что мы называем жанровой моделью, т.е. с ограниченной системой правил текстопорождения, свойственной именно для данной

группы текстов, а также с определенной «моделью мира» с соответствующим ему функциональным полем, опять-таки жанрово-обусловленной. Можно предполагать, что чем обильнее и жестче набор этих «правил», тем менее продуктивен жанр. Например, возьмем произведения жанров сказки или эпоса по строгим жанровым правилам, которых новые тексты уже не составляются. А такие произведения жанров баит или мифологические былички, где четких структурных правил меньше и они постоянно, согласно прагматических функций, «подвергаются изменениям» продолжают продуцировать. Например, в современных татарских баитах мы очень часто замечаем характерные черты схожие с мунаджатами. Это обуславливается тем, что мунаджаты в течение XX в. в силу объективных причин потеряли свое, предопределенное мусульманской традицией, функциональное поле, а баит продолжая функционировать в народном быту, в какой то степени стал синтезировать черты мунаджата в рамках собственной жанровой парадигмы.

Однако, обойтись без термина *текст* в фольклористике не представляется возможным. Только в отличии от текста книжного, текст в фольклоре не существует вне контекста. Поэтому понятие контекст в фольклоре является одним из ключевых. В современной фольклористике некоторые ученые, не удовлетворяясь рамками контекста, рассматривая фольклорные явления как культурологический объект стали употреблять понятие культурный ландшафт [4, с. 18.]. В рамках данного понятия текст воспринимается как явление присущее конкретной, определенной географическими рамками, культурной традиции. В данном случае структуру текста обуславливает присущее данному локусу культурная традиция. При таком подходе к вопросу фольклорный текст начинает наполняться смыслами, которые становятся понятными и несут полную, заложенную в них культурной традицией, информацию: вербальную, темпоральную, персональную, локативную, акциональную, музыкальную, танцевальную и тд.

## Литература

1. Веселовский А.Н. Историческая поэтика. - М.: Высшая школа, 1989 –С.408.

2. Дианова Т.Б. Текст и контекст в фольклоре. //Славянская традиционная культура и современный мир. М., 2005. Вып. 8. С. 12-21.

3. Добровольская В.Е. Роль контекста в бытовании и реконструкции фольклорного текста. // Традиционная культура. 2004. № 3 . – С. 46 -55.

4. Иванова А.И Кладбища и могильники в культурной традиции Пинежья //Актуальные проблемы полевой фольклористики. Сборник научных трудов. – вып. 4. – Сыктывкар, 2008. – С. 18 – 35.

5. Лотман Ю.М. Текс и функция // Статьи по семиотике культуры и искусства. – СПб, 2002, - С. 24 – 37.

6. Неклюдов С.Ю. Семантика фольклорного текста и «знание текста» // Славянская традиционная культура и современный мир. – М., 2005. Вып. 8. – С. 22 – 41.

7. Пропп В.Я. Фольклор и действительность. Избр. ст. – М., 1976. – С. 123.

8. Путилов Б. Н. Фольклор и народная культура. – СПб., 1994. – С. 155.

9. Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары. // Төз. Надиров И.Н. – Казан: Тат. Кит. Нәшр., 1980. – С. 231.Рольконтекста в бытовани и реконструкции фольклорного текста. // Традиционная культура. 2004. № 3 . – С. 46 -55.

**Ф.Х.Завгарова**
Республиканский центр развития
Традиционной культуры, Казань

# МИФОЛОГИЧЕСКИЙ ПЕРСОНАЖ БИЧУРА В ТРАДИЦИОННОЙ КУЛЬТУРЕ ТАТАР ЗАКАЗАНЬЯ[1]

В современном общенародном мифологическом мировоззрении татар до сих пор активно бытует мифологический персонаж Бичура, относящийся к котрегории низших духов. Этимологию названия Бичура ученый Р. Г. Ахметьянов связывает со словом ***бич*** *– обезьяна* с монгольского языка [1, с. 45]. Схожие персонажи с близким и по звучанию встречаются в традиционной культуре Поволжских народов. Например, в башкирском языке *писура,* в удмуртском языке *пичура* [3, с. 227 -229.].

В мифологическом мировоззрении татар Заказанья Бичура представляется существом женского пола, живущей в домах неопрятных хозяев [2, с. 122.]. Ипостаси персонажа подчеркивается и в эпиитах, которые употребляются в современных речевых коммуникациях исследуемой локальной традиции по отношению неопрятных, неряшливых женщин, например, *Бичура кебек киенеп йөри* (Одевается как Бичура), *Бичурадан бичура тумый кем тусын!* (От бичуры кто кроме бичуры может родиться!). В тоже самое время Бичура может обитать и в заброшенных домах. Например, по словам информантов деревни Кирби (Хәерби) Лаишевского района у них в деревне есть место, где обитает Бичура. Это заброшенный дом, которого после смерти хозяина Бичура не покинула. Жители деревни это место, вне зависимости от времени суток стараются обходить. Так как, по их мнению, Бичура может навредить. Так же Бичура может обитать в захламленных, не убранных местах. Но Бичура деревню никогда не покидает. По сродству с домовыми духами (йорт иясе), Бичура обычно живет за печкой, под полом, на чердаке. Может также обитать в забро-

[1] Работа выполнена при финансовой поддержке РГНФ (грант № 11-14-16002 а/В (РГНФ) «Мифологические персонажи в культурной традиции татар Заказанья»).

шенных строениях, во дворе, в бане. Днём от людей прячется, активна ночью, порой надоедает хозяевам шумом и возней. В тихие ночи бывает слышно, как она подпрыгивает, шуршит, кидается вещами. Может допрясть оставленную пряжу, вот только не слева направо, а наоборот, но чаще обрывает и мусолит нити, запутывает шерсть, которая была брошена без бисмиллы. В основном портит то, что оставили не доделав. Поэтому нити, пряжу в традиционных татарских семьях положено убрать в закрывающиеся коробки, в ночное время вообще иметь дело с пряжей не рекомендуется. Появляясь в доме, бичура часто является источником неприятностей, творит мелкие пакости: мешает спать шуршанием, писком, разбивает посуду, кидает луковицы, чеснок, которые как правило, хранятся за печкой в повешенном на гвоздь виде, сбрасывает одежду. Чтоб оберечь себя от пакостей бичуры надо стараться ее раздобрить. Бичура любит когда ее кормят, особенно приготовленной специально для нее, пресными лепешками (төче күмәч). *«Чормада, чоланда, я мич артында шыштыртаулар ишетелә башладымы, тизрәк төче күмәч пешереп атабыз. Бичура тынгызызлый башлый алайса»* (Как только начинаем слышать шуршание на чердаке, на чулане, за печкой, так сразу печем пресные лепешки и кидаем. Иначе бичура покоя не дасть.) (Записано от Галлямовой Н.Р. жительницы дер Кирби, 1953г.р.в 2006г.). В данной локальной традиции у современных татар функциональное поле бичуры немного расширено. Она, тем хозяевам которые ее кормят, привыкает и начинает услужливать: помогает найти затерявшиеся вещи, деньги, украшения, кошельки. Только ее об этом надо вслух попросит. “*Бичура шул әйберем югалды, табыш әле, дип сорасаң үзең дә сизми каласың, бер бик билгеле, син бөтенләй уйламаган җирдән теге әйбер килеп чыга. Шаклар катарсың* ” (Бичура пропало то – то, то – то. Помоги найти. Как только эти слова скажешь, та пропавшая вещь тут же находится в таком видном месте о котором совсем не думала. Диву даешся. ).

(Записано от Ганеевой Д.Х. жительницы п. Кукмор, 1968г.р.в 2011г.)

В населенных пунктах Мамадышского района нами зафиксированы функциональные сходства бичуры с албасты. По рассказам информантов дер. Шемякова бичура может ночью наваливаться на хозяев и душит их. Может дергать за волосы. При таких случаях положено двигать кончиками пальцев на ноге, особенно мезенцем. Если человек смог двигать пальцами на ноге, то он смог уйти от проказней бичуры, а если не получилось, то бичура может мучить человека до утра. Бичуре нельзя давать слишком шалить. Иначе она может начать вредить. Если узнали, что в доме поселилась бичура ее надо раздобрить: не ругаться, не гремить посудой, не кидать дрова, ее подкармливать: на чулане или где нибудь в углу дома оставлять еду. Можно какую небудь пресную кашу. Посоленную еду бичура не есть. Если вы увидите, что на утро оставленная вами на ночь еда съедена, значит бичура к вам начала привыкать. Шумных домов бичура тоже не любит, поэтому семья должна жить в мире и в согласии. Иначе такому дому не видать покоя. Бичура своими шалостьями хозяив может довести. Бывают и такие случаи, когда семья вынуждена покидать свое жилище. Как правило в такие дома больше никто не поселяется, их начинают обходит. *“Ташландык өйләргә кеше кереп урнашмаска тырыша инде. Анда бичура булырга мөмкин. Бичуралы өйдә бәхет бик булмый ул. Кешедән калган бичура булса, бигрәк тә. Теләсә кемне килештерми бит ул. Шау – шулы гаилә булса көт тә тор. Берәр бәлә-казаны да китереп чыгарырга мөмкин диләр. Хәтерлим әле бер биш алты еллар үтте бугай. Апам тора торган авылда, бездән сигез чакрымдыр ул авыл, булды бу хәл. Бик озак сөйләделәр инде. Бер йорта, су буенда диделәр аны, беркем тормаган. Ташландык өйләр күп бит хәдер авылларда. Яшьләр китә бит. Менә бу өйдә дә бер карчык үзе генә яшәгән булган, аннары аны кызы апкиткән. Өйе бер үзе генә калган. Бичурасы да калган, авылдан китмәгән инде. Китми бит ул. Шунда*

*калган инде. Менә шул йорт күп кенә еллар буш торган. Аннары бер ара тарлар теләсә каяан кайта башладылар бит. Бездә качаклар диләр аларны. Эш рәте белгән кешеләр түгел инде алар. Рәтле кеше гел урын алыштырып йөрми бит. Менә шундый дүрт бабалы хатын авылның эчәргә яратарак булган бер ире белән теге йортны әзрәк сипләп шунда яши башлаганнар. Эчә торган кешеле гаилә шау – шулы була бит. Аннары теге хатын үзе дә бик сүгенә булган. Менә шулар кычкырышып беткәннәр, әйберләре гел югала торган булган. Ахыры шулай булган теге хатынның балалары бу иргә пычаклар белән ташланып, берсе чәнчелеп үлгән. Менә балам, шундый хәтәрләр булган. Тыныч кына яшәгән бичура боларның котыруын килештермәгән инде. Тегеләргә кычкырышырга сәбәп чыгарып кына торган.*"(В заброшенные дома люди стараются не поселяться. Там может обитать бичура. В доме с бичурой не всегда счастье ждет, особенно если там осталась чужая бичура. Кого попало бичура не воспринимает. А если семья сама шабутная так и  жди, какая небудь беда да случиться. Я помню в деревне сестры, в 8-ми километрах от нас, рассказывали такой случай. Долго об этом событии слухи ходили. Был заброшенный дом. У речки кажется. Сейчас в деревнях заброшенных домов много. Молодежь уезжает. Там жила одинокая старушка. Когда она совсем состарилась дочь ее  забрала к себе. А ее бичура осталась Они же деревню не покидают. Этот дом долго пуставал. В деревню приехала беженка татарка с четырьмя детьми, которая не к чему не годная. Вот она поселилась там со своими детьми и с мужчиной, любящим выпивать. Дети и она сама были шабутные, шумные, тут еще и пьяница. Бичуре это не понравилось, она стала им вредить. Стали теряться вещи, ну и началась ругань. Один из сыновей кинулся на мужика ножом и порезался сам на смерть. Вот ведь как бывает. Бичура все время им находила причину ругаться.) (Записано от Агзямовой С. Х. жительницы дер. Шемякова Мамадышского района, 1933г.р. в 2011г.). Анализируя приведенную быличку можно заметить следующее: персо-

наж бичура низшей мифологии  в мировоззрении современных татар существует в традиционном представлении и наделена фукциями как потранажными так и вредоносными. Но бичура как постоянно бытующая в конкретном локусе константа идет на определенные уступки с человеком. При выполнении поведенческих этических норм, закрепленных культурной традицией конкретного локуса может стать помощником, другом человека. Тем самым выполняя функции сохранения  приемственности народной этики и поведенческих норм, менталитета.

## Литература


1. Ахметьянов Р.Г. Краткий историко-этимологический словарь татарского языка (Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге). – Казан: Тат. кит. нәшр. , 2002. - 272б.
2. Риваятьләр һәм легендалар. / Төз. С. Гыйләҗетдинов. – Казан: Тат. кит. Нәшер, 1987. – 278б.
3. Урманчеев Ф. И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. Өч томда. Том 1. – Казан: Мәгариф, 2008. – 307б.

**Л. Зиганшина**
Казанская государственная консерватория
им. Н.Г. Жиганова

# О НЕКОТОРЫХ ОСОБЕННОСТЯХ КАЛЕНДАРНО-ОБРЯДОВОГО ЦИКЛА ТАТАР-МИШАРЕЙ ДРОЖЖАНОВСКОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Мишарская песенная культура представляет собой конгломерат локально-территориальных традиций, каждая из которых характеризуется комплексом специфических особенностей. Вместе с тем изучение этнографических субкультур татар-мишарей практически вплоть до настоящего времени находится на периферийных позициях. Не является исключением песенная культура буинских мишарей – этнографической подгруппы, расселенной в Буинском, Дрожжановском районах Республики Татарстан, а также Батыревском и Комсомольском районах Чувашии. Отметим, в частности, что песенная традиция буинской группы в существующих музыкально-этнографических сборниках представлена не более чем десятком образцов, не дающих сколько-либо целостного представления о специфике местной культуры. С целью сбора песенного и этнографического материала летом 2011 г. Фольклорным кабинетом Казанской консерватории была предпринята экспедиционная поездка в Дрожжановский район. Всего на обследуемой территории находится около 20 мишарских поселений, в том числе районный центр - село Старое Дрожжаное. В ходе экспедиционных изысканий нами было обследовано 10 населенных пунктов, опрошено 70 информантов (1925 - 1977 гг. рождения), зафиксировано более 300 образцов мишарской песенной и инструментальной культуры и более 100 единиц записей интервью с этнофорами.

Объектом рассмотрения в настоящей работе является календарно-обрядовый цикл, бытующий в среде татар-мишарей, проживающих на территории обследованного ареала. Этнографический комплекс, в рамках которого существует традиционная песенная культура местных мишарей, представляет собой весьма значимый предмет для изучения, так как обладает целым рядом самобытных черт, определяющим ее этнокультурную специфику в ряду других этнографических традиций татар. Работа основана на свидетельствах народных исполнителей, зафиксированных нами во время экспедиционных изысканий.

Обрядово-праздничная культура татар-мишарей представляет собой разветвленную систему, сочетающую в себе как собственно календарно-земледельческий цикл, так и комплекс праздников, связанных с исламской традицией. Календарно-земледельческие праздники являются частью обрядов, которые исполнялись в определенное время года и были призваны благоприятно влиять на плодородие земли, ход сельскохозяйственных работ, семейное благополучие и т.д. Среди обрядов весенне-летнего цикла нам удалось зафиксировать особенности проведения таких праздников, как *ташу* (букв.: «ледоход»), *йомырка бәйрәме* (Пасха), *ызба юу* (букв.: «мытье дома»), *каталау көне (букв.: «день кувыркания»*), *Сабантуй*, *яңгыр теләү* (обряд вызывания дождя), *карга буткасы* (букв.: «грачиная каша»). Осенне-зимний цикл отмечен проведением таких обрядовых действ, как *көзге бәйрәм (*«осенний праздник»*), каз өмәсе* («ощипывание гусей»), *йон эрләү* («прядение шерсти»), *Раштва* (Рождество), молодежные посиделки *(мәзәк, аулак, кич утыру*) и т.д. Отметим, что как структура всего календарного цикла, так и собенности проведения отдельных праздников и обрядов имеют ряд сходных черт с другими этническими традициями региона, иными словами, имеют общерегиональное распространение.

Наряду с земледельческим календарем в среде татар-мишарей активно практикуются исламские обрядовые традиции.

Как известно, мусульманские праздники исчисляются согласно лунному календарю и имеют передвижной характер. Среди множества мусульманских праздничных дат у мишарей Дрожжановского района традиционно почитаются: *Ураза бәйрәм* (праздник разговенья), *Корбан бәйрәм* (праздник жертвоприношения), *Мәүлид ае* (празднование дня рождения пророка Мухаммада). Отметим, что ислам в народной среде мишарей занимает устойчивые позиции, его влияние ощутимо на всех уровнях организации духовной жизни и культуры местных жителей. Таким образом, специфический облик обрядовой культуры татар-мишарей (в нашем случае - буинских) формируется в результате тесного взаимодействия общерегионального и исламского компонентов. При этом роль каждого из них в конкретном обряде может быть различной: так, *Раштва* и *Йомырка бәйрәме* в большей степени транслируют общерегиональный субстрат, связанный с языческими традициями. Следующее ниже рассмотрение коснется обрядов - *каталау көне* и *янгыр теләү*, в которых оба компонента находятся в паритетных отношениях.

*Каталау көне* (букв.: «день кувыркания») имел закрепленную дату проведения: его справляли 15 мая (по старому стилю 28 мая); отсюда второе название праздника - *унбишенче май көне*. Народные исполнители традиционно характеризуют этот обряд как всеобщий, в котором принимали участие все население, без ограничения по возрастному признаку - старики, взрослые и дети. Для его проведения все жители уходили за пределы деревни, чаще всего в лес или поле, в зависимости от особенностей местного природного ландшафта. Продолжительность праздника составляла практически целый день: уходили с утра, возвращались после обеда или ближе к вечеру.

«Урман буена авыл халкы бөтенесе чыга иде. Анда ерлыйлар, бииләр, култыклашып урманга керәләр» («В этот день все население деревни ходило в лес. Там пели, плясали, взявшись за руки, входили в лес») (Дрожжановский район, дер. Татарские

Тюки, Шарафутдинов Нурулла Шагабутдинович, 1943 г.р.; Шарафутдинова Ламига Халимовна, 1945 г.р. Запись: июнь 2011 г.).

Основной целью обрядов, приуроченных к этому дню, было ритуальное обеспечение здоровья себе и своим близким на предстоящий год, заключавшееся в проведении определенных ритуальных действ: дети кувыркались через голову, взрослые ложились на землю в полный рост и в горизонтальном положении скатывались с горы.

«Оланнар каталап йөри иде чирәмнән, саулык сорап» («Дети кувыркались на траве через голову, просили себе здоровье») (Дрожжановский район, дер. Мочалей, Закирова Мушфика Нуртдиновна, 1925 г.р.; Идиятуллина Таскира Амирзяновна, 1969 г.р. Запись: июнь 2011 г.).

Существовал также обычай обнимать деревья – дуб или березу – с просьбой дать здоровье.

«Каен кочаклыйбыз, агачтан саулык сорыйбыз» («Обнимали березу, у дерева просили себе здоровье») (Дрожжановский район, дер. Татарские Тюки, Шарафутдинов Нурулла Шагабутдинович, 1943 г.р.; Шарафутдинова Ламига Халимовна, 1945 г.р. Запись: июнь 2011 г.).

Кроме того, к этому дню был приурочен сбор трав, по поверью наделенных чудодейственной силой. Из этих трав и цветов делали веники для бани, варили отвары.

«Урманнан үләннәр, минек җыеп катясын, май үләннәре. Балаң касталаса майның 15дә җыеп кайткан үләмгә баланы салып коендыра идек. Файдасы бар иде» («В лесу собирали майские травы, делали веники. Если заболеет ребенок – купали отваром собранных 15 мая трав. Польза была») (Дрожжановский район, дер. Мочалей, Закирова Мушфика Нуртдиновна, 1925 г.р.; Идиятуллина Таскира Амирзяновна, 1969 г.р. Запись: июнь 2011 г.).

Отметим, что в данных ритуалах совершенно определенно прослеживается связь с культом растений, имевшим место в общинно-родовых представлениях народностей Поволжско-

Приуральского региона. Определенные региональные аналогии видятся, в частности, в троицко-семицком обрядовом комплексе, бытующем у православных этносов региона, но вместе с тем связанном с языческими представлениями - характерным для этого периода выходом молодежи в лес, ритуалом завивания берез и т.д.

Наряду с собственно общинно-родовыми, земледельческими представляниями в обрядовом комплексе *Каталау көне* достаточно четко обозначен и исламский компонент. Так, женщины и мужчины старшего поколения, прося у Аллаха здоровья, читали суры из Корана, исполняли мунаджаты.

«Аенда карчыклар бара, барсы да мөнәҗәт укыйлар» («Ходили старушки, каждая читала мунаджаты») (Дрожжановский район, дер. Мочалей, Валиуллова Факима Фатыховна, 1936 г.р.; Идиятуллина Таскира Амирзяновна, 1969 г.р. Запись: июнь 2011 г.).

*Яңгыр теләү* (букв.: «пожелание дождя») - обряд окказионального характера, проводился только в периоды засухи с целью «вызывания дождя». В проведении обряда участвовало все население. Все ритуальные действия, приуроченные к этому дню, можным сгруппировать в два комплекса:

1) обливание водой;

2) моление.

В обрядовом обливании водой принимали участие только дети и молодежь. Выйдя на улицу с ковшами и ведрами, участники ритуала обливали прохожих водой, произнося при этом заклички:

| | |
|---|---|
| Яңгыр яу, яу, яу! | Дождик лей, лей, лей! |
| Тәти кашык бирермен. | Получишь красивую ложку. |
| Сарык суярмын, | Я принесу в жертву барашка |
| Ботын сиңа бирермен. | И дам тебе ляжку. |

(Дрожжановский район, дер. Старые Какерли, Алиева Рузалин Латыповна, 1939 г.р.; Алеева Фанзия Равилева, 1975 г.р. Запись: июнь 2011 г.).

«Урамга чыга идек, су сибешә идек. Килеп явып та китә иде»

Яңгыр яу, яу, яу!
Майлы бутка казанда,
Тәти кашык базарда,
Тәти кашык мең алтын.

(«Выходили на улицу и обливали друг друга водой»).

Дождик лей, лей, лей!
Масляная каша - в котле,
Красивая ложка - на базаре.
Красивая ложка - тысяча золотых.

Когда произносили заклички, и дождь проливал») (Дрожжановский район, дер. Мочалей, Закирова Мушфика Нуртдиновна, 1925 г.р.; Идиятуллина Таскира Амирзяновна, 1969 г.р. Запись: июнь 2011 г.).

«Урам буенда су сибешәләр. Узган кешегә башыннан су сала идек, яхшы киемнәнме, начарданмы узып барасың, су сибәләр иде. Су сипкәндә: “Ачуланма, яңгыр килә хазер”. Бер кеше ачуланмый иде» («На улице обливались водой. Каждому проходящему голову обливали водой. Неважно, во что он был одет. Когда поливали водой, говорили: “Сейчас будет дождик, не ругайся”. И никто не ругался») (Дрожжановский район, дер. Старые Чукалы, Юсупова Рокыя Аделзяновна, 1938 г.р.; Халиуллова Гульсира Фатыховна, 1953 г.р. Запись: июнь 2011 г.).

Старшее поколение принимало участие в молениях, репрезентирующих исламскую традицию и существовавших на исследуемой территории в различных вариантах. Так, в д. Малая

Цильна женщины старшего возраста спускались к реке, возле которой читали намаз. В д. Старые Какерли моления проходили в поле. В д. Татарские Тюки обряд включал жертвоприношение:

«Яңгыр теләү булган. Кырга чыгып дога укыганнар, корбан чалганнар» («Обряд вызывания дождя был. Выходили в поле, читали молитвы и приносили в жертву животного») (Дрожжановский район, дер. Татарские Тюки, Шарафутдинов Нурулла Шагабутдинович, 1943 г.р.; Шарафутдинова Ламига Халимовна, 1945 г.р. Запись: июнь 2011 г.).

В некоторых деревнях (например, в д. Старые Чукалы) для молений ходили на кладбище, к местам захоронений святых.

«Картлар зиратка бара иде. Теләк телиләр, намаз укыла, тәхлил тартыла, яңгыр сорыйбыз. Безнең Татлыкай бабай дигән изге зирәтебез бар. Алар өч кеше булганннар: берсе Болгарда күмелгән, икенчесе - бездә, өченчесе - Цилнада. Өч бырат. Бу теләү элек-электән килгән» («Старики ходили на кладбище. Молились, читали намаз, произносили тәхлил, и просили у Бога дождь. У нас есть кладбище, где захоронен святой человек - Татлыкай бабай. Их было три брата: первый захоронен в Булгарах, второй - в Старых Чукалах, третий - в Цильне. Прошение дождя было с давних времен») (Дрожжановский район, дер. Старые Чукалы, Юсупова Рокыя Аделзяновна, 1938 г.р.; Халиуллова Гульсира Фатыховна, 1953 г.р. Запись: июнь 2011 г.).

Завершая предпринятый в настоящей работе краткий обзор, отметим, что он, безусловно, не претендует на целостное рассмотрение поставленной проблемы выявления специфики этнографического комплекса обрядовой традиции буинских мишарей, однако вместе с тем намечает определенные подходы к ее решению.

**С.С. Исмәгыйлева**
Казан педагогия көллияте

# СТУДЕНТЛАРНЫҢ ФОЛЬКЛОР ТҮГӘРӘКЛӘРЕ БЕЛӘН ЗАМАНЧА ЭШЛӘҮ АЛЫМНАРЫ

Педагогия көллиятләрендә укучы студентларны милли шәхес итеп тәрбияләү иң әһәмиятле бурычларның берсе булып тора. Милли шәхес ул, беренчедән, үз халкының телен, тарихын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен һәм башка күптөрле рухи байлыгын белүче, яратучы, хөрмәт итүче, яшәү рәвеше һәм шәхси сыйфатларында үз милләтенең иң яхшы якларын саклаган кеше.

Икенчедән, милли шәхес үзенең әйләнә-тирәсендә яшәүче башка халыкларның мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, динен һәм башка рухи байлыкларын белүче һәм хөрмәт итүче кеше.

Өченчедән, милли шәхес – үз милләтенең һәм башка милләтләрнең рухи дөньясының өстенлеген белеп хөрмәт иткән, кимчелеген белеп, сабыр иткән хәлдә үз милләтенең исемен горур йөртә алырдай көчле, заман белән бергә атлаучы кеше.

Кешенең рухи дөньясы үзен чолгап алган мохиттә формалаша. Этник культураның компонентлары булган тел, материаль сфера, йола, гореф-гадәт, профессиональ сәнгать, этнопсихология арасында фольклор үзенчәлекле урын алып тора. Музыкаль фольклор – югарыда күрсәтелгән компонентларда булган рухи продуктның сәнгатьчә гәүдәләнеше. Ул һәр кешенең хисләрендә, хәтерендә саклана. Музыкаль фольклор кешенең иң нечкә хисләре белән эш итәргә сәләтле көчле тәрбия чарасы булып тора. Шуңа күрә фольклорның музыкага кагылышлы өлешен тәрбиячеләргә һәм аеруча укытучыларга җентекләп өйрәнү, аны мәктәп балаларын тәрбияләүдә нәтиҗәле файдалана белү кирәк.

Укучыларны милли шәхес итеп формалаштыру – катлаулы һәм күләмле хезмәт. Бу эш кайбер каршылыклар белән башкарыла.

Беренчедән, балаларның яшәү рәвеше традицион фольклордан ераклашкан. Җитештерү сферасындагы модернизация про-

цесслары кешенең шәхси тормышына да үтеп кереп, традицион фольклорда үзәктә торган рухи кыйммәтләр икенче планга күчкән. Икенчедән, педагогия көллиятләрендә музыкаль фольклор дисциплина буларак бөтенләй укытылмый, ә бәлки музыка дәресенең кайбер темалары буларак кына яки башка темаларны ачу өчен өстәмә, дидактик материал ролендә генә өйрәнелә. Югарыда санап кителгән проблемаларны хәл итү максаты белән музыкаль фольклорны педагогия коллиятенең уку планнарына милли региональ компонент буларак факультатаив предмет яки түгәрәк итеп кертү тәкъдим ителә.

Музыкаль фольклор түгәрәгенең бурычлары:

1. Татар музыкаль фольклорын рус, Идел буе, Европа, Азия халыклары музыкаль фольклоры һәм дөнья сәнгатенең тарихи үсеш баскычлары контекстында комплекслы рәвештә фәнни яктан өйрәнү.

2. Милли бәйрәмнәр һәм йолаларны, халык җырларын һәм биюләрен башкарырга өйрәнү, һәрберсенең тарихын, әһәмиятен ачу.

3. Фольклор экспедицияләр, информацион технологияләр белән эшләү барышында балаларда иҗади сәләтләр һәм фәнни эзләнү ихтыяҗы уяту.

Музыкаль фольклор түгәрәге эшенең нәтиҗәлелеге өчен гомуми педагогика тәкъдим иткән укыту тәрбия методларын белү һәм урынлы файдалану кирәк. Методларны кулланганда, заман таләпләренә туры килгән яңа алымнар кертү әһәмиятле.

Педагогия фәннәре докторы, югары уку йортлары өчен педагогика дәреслекләре авторы Ю.К. Бабанский укыту-тәрбия методларын тирәнтен өйрәнеп, мәктәптә куллану өчен тәкъдим итә [1]. Аның әлеге фәнни хезмәте фольклор түгәрәкләре эше өчен дә кулланма материал булып тора.

Укыту-тәрбия методлары ул зиһенгә, тойгыларга, ихтыяр көченә, тәртипкә, мөнәсәбәтләр системасына тәэсир итү, укучының акыл көчен үстерү, белемнәрне үзләштерү һәм

күнекмәләрне булдыру юллары. Алым исә – методның аерым ягы яки состав өлеше, укыту шартларына яки укучы һәм укытучының иҗади мөмкинлекләренә туры килүче аерым операцияләр. Ю.К. Бабанскийның классификациясе буенча методлар укыту-тәрбия процессына бердәм якын килү нигезендә 3 төркемгә бүленә. Әлеге классификацияне нигез итеп алып, XXI гасыр башында безнең илдәге тәрбия системасы таләпләренә туры килгән алымнарны карап китик.

I. Танып белү эшчәнлеген оештыру һәм булдыру методлары.

1. Сөйләм, күрсәтмәле, практик методлар. Бүгенге этапта XXI гасыр башында актив рәвештә укытуны компьютерлаштыру нәтиҗәсендә арткы планга күчкән сөйләм методын кире кайтару зарур. Хәзерге яшьләрнең сөйләм культурасы түбән булуы, ягъни сүз байлыгының аз булуы, телнең чисталыгы булмау, образлы сөйләм белән үзара аралашуның гомумән юкка чыгуы күзәтелә. Бу хәл балаларның гомуми үсешенә зур зыян сала. Әлеге проблеманы хәл итү максатында түгәрәк музыкаль булуына карамастан, тел үстерүгә бәйле алымнар куллану кирәк. Әйтик, халык җырларын башкарган сәхнә чыгышларын риваятьләр, әкиятләр нигезендә язылган әдәби-музыкаль композиция рәвешендә әзерләү, студентларның татар телендә фәнни эшләр язуы һәм яклавы музыкаль фольклор түгәрәкләре өчен беркадәр катлаулы, ләкин яңа һәм мавыктыргыч алым.

Күрсәтмәле методларга килгәндә, һичшиксез, укытучының әсәрне башкаруы, сәнгать осталарының сәхнә чыгышларын турыдын-туры карау иң нәтиҗәлеләре. Шулай да информация алу чыганагы буларак бүгенге көндә иң популяр булган компьютер, аерым алгында *Интернет челтәрен файдалану алымы* яшьләрнең табигый ихтыяҗына туры килә. Бу очракта укытучы үзе укучыларның информация алу тәртибе белән идарә итә белергә тиеш. Ул Интернетка яки компьютер дискларына ниндидер юллар белән килеп кергән зәвыксыз әсәрләрне белеп торырга

һәм укучыларны да критик караш белән сайлап алырга өйрәтергә тиеш.

Музыкаль фольклор түгәрәге эшендә практик метод төп метод булып тора. Бу студентның фольклор әсәрен башкаруы дигән сүз. Башкару рәвеше 2 төрле булырга мөмкин: сәхнә башкаруы һәм табигый тормыш шартларында фольклор мөхитендә булу. Сәхнә башкаруында, әлбәттә, фольклор әсәрен сәнгатьчә эшкәртелгән вариантта күрсәтү кирәк. Моның өчен җитәкче сәхнә культурасы, тавыш кую кебек эшләрне башкарырга тиеш. Бигрәк тә фольклор фестивальләрендә фольклор күренешне сәхнә куюда табигыйлек, уникальлекне примитивлык һәм псевдофольклор белән бутамау чикләрен тоемларга кирәк. Соңгы вакытта барлыкка килгән *фольклорны стилизацияләнгән рәвештә кую* практик методны куллануның яңа алымы. Бу алым фольклорны аеруча нык сиземләүне, шул ук вакытта заманча башкару алымнарын белүне таләп итә. Бер яктан, ул заманчалыгы белән студентны җәлеп итә һәм яшьләр арасында фольклорны популярлаштыруга уңай йогынты ясый. Икенче яктан, примитив кулланганда, фольклор әсәренең уникальлеген юарга мөмкин. Мәсәлән, салмак көй, хәтта озын көй жанрындагы җырларны ритмик аккомпанемент кысаларына буйсындыруның әлеге җырларның асылын югалту икәнен аңлау кирәк. Кызганычка каршы, бу күренеш яшь артистлар иҗатында еш очрый һәм тиражлана. Бу очракларны укучылар белән тәнкыйть күзлегеннән чыгып анализлау кирәк. Димәк, бу алымны кулланганда бик сак булырга кирәк. Заманчалыкны керткәндә, фольклор әсәренең асылын үзгәртми торган алтын урталыкны таба алырдай сәләтле укучыларың булганда һәм, җитәкче буларак, үзең дә шул таләпләргә җавап бирерлек булсаң гына бу эшкә алыну хәерле.

Студентның әсәрне башкару рәвеше табигый тормыш шартларындагы фольклор мөхитендә булганда аны ясалмалылыктан сакларга кирәк. Музыкаль фольклорны фольклорның башка төрләреннән аерып карарга ярамый. Әйтик, студент Каз өмәсе

йоласын үткәргән җиргә бара икән, бу йоланың һәрбер шартын башкалардан аерылмыйча үтәргә әзер булырга тиеш. Хәтта җырчы буларак кунакка чакырылса да. Бу уңайдан шуны да искәртеп үтәргә кирәк: яшьләрнең көнкүреш шартларында үткәрелгән милли йолаларда катнашуы үткән гасыр өчен табигый булса да, бүгенге яшьләр өчен яңалык. Алар йоланы сәхнәдә күрергә күнеккән. Шуңа күрә, *милли йола, бәйрәмнәрне яшьләр арасында оештыру – фольклор түгәрәгенә йөрүче студентлар белән эшләүнең яңа алымы.* Бик матур үрнүк итеп Бөтендөнья татар конгрессының яшьләр форумында Арча педагогия көллияте студентлары тарафыннан уздырылган Каз өмәсе йоласын китерергә була.

2. Индуктив, дедуктив методлар. Индуктив метод: материалны өйрәнү өлештән бөтенгә таба бара. Күп очракта индуктив фикер йөртү барышында гына төшенчәләрнең мәгънәсе ачыла. Мәсәлән, 32 ле озынлыктагы ноталардан торган көй һәм мелизм тәшенчәләренең аермасын өйрәнгәндә бу метод уңайлы. Дедуктив метод: материалны өйрәнү бөтеннән өлешкә таба бара. Материалны тизрәк үтәргә мөмкинлек бирә.

3. Репродуктив, проблемалы эзләнү методы репертуар сайлауда, укучыларның фәнни эшләренә материал эзләүдә кулланыла. Татар музыкаль фольклорын рус, Идел буе, Европа, Азия халыклары музыкаль фольклоры һәм дөнья сәнгатенең тарихи үсеш баскычлары контекстында комплексны рәвештә фәнни яктан өйрәнүгә багышланган теоретик курс тулаем шушы метод белән эшләүгә нигезләнгән. Бу әзер дәреслекләр булмавы белән аңлатыла.

4. Мөстәкыйль эш, укытучы җитәкчелегендәге эш (фикер эзлеклелеге, акыл һәм практик операцияләр укучының үзе белән билгеләнә). Бу методны кулланганда укучының мөстәкыйль эшкә куелган бурычны төшенүе, эшне ничек башкарыга кирәклекне аңлавы мөһим.

II. Мотивация һәм стимуллаштыру методлары.

*1.* Кызыксыну формалаштыру методлары. Уңыш ситуация-се тудыру. Түгәрәк эше укучының шәхси вакытын сарыф итүгә исәпләнгән. Укучы канәгатьләнү алмый икән, шөгыльләнүдән баш тарта. Бу хәл тискәре эмоцияләр булганда бигрәк тә четерекле. Укучы түгәрәккә үзенең сәләтен, иҗади мәмкинлекләрен бәяләп тормыйча килә. Аның беренче мотивы – аралашу, үзеңне сәләтле кешеләр җыелган коллектив өлеше итеп тою. Шушы иң мөһим мотивны саклап калу кирәк. Бу мотив кайсыдыр сәләтле укучының конкурсларда урын алган уңышыннан да бәялерәк. Чөнки фольклор ул башлыча иҗтимагый күренеш. Фольклор түгәрәкнең башка түгәрәкләрдән өстенлеге дә шунда: һәр студент сәләтенә күрә үзенең урынын таба һәм шул юнәлештә үсешкә ирешә ала. Алдагы еллардан аермалы буларак, соңгы вакытта студентларда күмәк җырлау күнекмәләре юк, аларда күңелдәге җыр запасы юк дәрәҗәсендә, фольклор биюләр төшенчәсе аларга гомумән таныш түгел. Шуны исәпкә алып, *мәҗлес җырларын, XIX гасырның 50 – 80 нче еллары һәм хәзерге чорның популяр җырларын күмәкләп җырлап ятлау яшьләрне җәлеп итүдә уңышлы алым.*

2. Җаваплылык формалаштыру методлары. Фольклор түгәрәктә шөгыльләнүнең иҗтимагый әһәмиятен аңлату, шәхси үсеш мөмкинлекләрен күрсәтү, билгеле бер таләпләр кую, дәртләндерү, бүләкләү, җәза бирү методларын дөрес куллану – хәзерге чорда да актуаль методлар.

III. Контроль һәм үзконтроль методлары. Әлеге методлар бигрәк тә җырны, биюне, фольклор күренешне ансамбль белән башкару өстендә эшләү барышында алыштыргысыз. Ансамбльнең уңышы студентның күмәк күренештә үзенең образын, тавышын таныган хәлдә коллективның бөтенлеген тоеп башкаруыннан тора. Ансамбль җитәкчесе исә үз вакытында һәр катнашучының үсешен сизеп, хаталарны төзәтеп өлгерергә тиеш. Хәзерге заман укытучысы *үзенең коллективын тирәнрәк өйрәнү өчен укучыларның үсеш дәрәҗәсен ачыклаучы диагностика*

*алымнарын куллана.* Бу алымнар фольклор түгәрәге җитәкчесе өчен дә заман таләбе.

Әлеге язма минем 2004 елдан Түбән Кама педагогия көллиятендә, 2011 елдан Казан педагогия көллиятендә “Халык җәүһәрләре” фольклор коллективы белән эшләвем тәҗрибәсен уртаклашу максатында бирелде.

**Әдәбият исемлеге**

1. Понятие о методах обучения и их классификация // Педагогика / под ред. Ю.К. Бабанского. – М.: Просвещение, 1983.

**Р.Ә. Минһаҗева, О.Н. Иванова**
Алабуга дәүләт педагогия университеты

## Г. ИРАҺИМОВНЫҢ «ЯЗ БАШЫ» ХИКӘЯСЕНДӘ ФОЛЬКЛОР МОТИВЛАРЫ

Г. Ибраһимовның «Яз башы» хикәясе – романтик хикәя, әдипнең Казан чоры иҗатын ачып җибәрүче тәүге әсәре. Яшь автор Г. Ибраһимов бу әсәрендә кешенең рухи дөньясын ачып бирүче оста психолог, фольклор белгече һәм табигать матурлыгына мәдхия җырлаучы пейзаж остасы буларак ачыла.

Әсәр тугыз ай мәдрәсәдә укып, яңа гына җәйге ялга туган авылына, туган нигезенә кайтып төшкән 11 яшьлек Салих тарафыннан хикәяләнә.

Яз – хикәя герое Салихның иң көтеп алган ел фасылы. Авыр мәдрәсә хәяте белән тәмам туйдырырга өлгергән кыштан соң язга чыккач, героебыз кыш буена җыелып килгән табигый балалык теләген – уен дәртен – уйнап басарга керешә: дуслары белән күлгә балыкка китә. Әмма кичкә таба кинәт табигатьнең тынлыгы бозыла. Моңарчы кояш елмаюы астында көннәрен бәйрәм кебек

үткәрүче балаларның күңеленә шом төшә башлау, дулкынлану, җил чыгу белән тагы да көчәя. Табигатьнең бу рәвешле кинәт бозылуы образ-персонажлар күңелендә билгеле үзгәрешләр тууга сәбәпче була, серле камышлыкка якынаю белән күңелләрен дулкынлану хисе били башлый. Җитмәсә, нәкъ менә шул рәвешле җил-давыл, кара болыт ярдәме белән, имеш, камышлыктан аждаһа күтәрелә икән. «Янәсе, кемнеңдер бабасы күргән... » [2, б. 63].

Гомумән алганда, гареб һәм шәрекъ романтик әдәбиятында караңгылык, кояш югалган чак, җил-давыл, кара болыт герой күңелендә төрле шомлы уйлар, үлеләр дөньясы, төрле галәмнәр белән элемтә тудыручы халәтләргә якынайтучы символик образлардан саналалар.

Мәсәлән, рус әдибе И.С. Тургеневның «Аучы язмалары» хикәяләре циклына кергән «Бежин луг» әсәрендә ат көтүче балалар төнлә учак янында төрле халык ышануларын, албастылар, Су аналары, Су ияләре хакында бар белгәннәрен, ишеткәннәрен искә төшерә торган булалар [4, с. 92 – 111]. Сүз узган ел авылда кемнәрнең ничек вафат булуы, исән булганда, алар белән бәйле төрле юрауларның ничек рас килүләре турында фикер алышуга килеп җиткәндә, малайларның берсе – Павлуша − су алырга елгага төшә һәм үткән ел суга батып үлгән дуслары Васяның үз янына дәшкән тавышын ишеткән кебек була. Озак та үтми, бу шомлы төнге аһәң Павлушаның да язмышын билгели: нәкъ бер елдан, ул да, аттан егылып, һәлак була.

Романтикларның халык авыз иҗатына битараф булмаулары, фольклор мотивларын, образларын иҗатларында бик теләп идеаллаштырулары хакында галим В.В. Ванслов болай дигән: «Пытаясь искать полноту жизни среди сельских жителей, романтики с огромной любовью относились к народному творчеству, собирали, изучали и обрабатывали его» [1, с. 128].

Г. Ибраһимов та герое Салих белән бу камышлы күлгә кагылган, анда яшәүче әкияти-мифологик зат Аждаһа турында

ишеткән бар риваять-легендаларны, имеш-мимешләрне әсәр тукымасында җанландыра.

Хикәянең кульминацион ноктасында Салих, күзаллавындагы хыялый-мифологик аждаһага тәмам ышанып, һушын югалта. Әмма фарсы мифологиясеннән кергән бу явыз зат, кешенең куркыныч дошманнарының берсе, бар нәрсәне җимерүче куркыныч символ – аждаһа (утлы елан) халык авыз иҗатында, белүебезчә, һәрвакыт җиңелеп килгән.

Хикәянең чишелешендә Салихның да явызлык, караңгылык дөньясын җиңеп, күзен ачып, реаль җир тормышына кайтуы татар халык әкиятләренә хас оптимистик бетемне хәтерләтә: «Дөнья әүвәлгечә матур. Таулар, кырлар, урманнар элеккечә яшел, сандугачлар һаман өзлексез сайрамакталар иде» [2, б. 64]. Шулай итеп, әкияти күзаллаулар белән көчәйтелгән, куркыныч табигать стихиясеннән аңын югалткан романтик герой янә реаль җир тормышына, табигатьнең яңарыш алган иң матур чорына – яз башына кайтып төшә.

Әдип эстетикасында халык авыз иҗаты мотивларын өйрәнгән галимә Айслу Садыйкова: «Фольклоризмы в этом рассказе молодого писателя используются осознанно, в целях восполнения идейно-национального комплекса литературной повествовательной системы. И рыбалка, и сказки, и мальчик могли появиться в рассказе писателя любой национальности. Но образы аждахи, юхи, сражение Гали батыра с аждахой были знакомы Востоку, тюркским народам, в том числе татарскому народу, принадлежали эстетической системе татарского фольклора. Причудливое переплетение реального и фантастического, солнечного, ясного и темного, страшного начал придает рассказу занимательность» [3, с. 61], – дип искәртә.

Шулай итеп, татар халык иҗаты өлкәсендә киң эрудицияле белгеч буларак, романтик язучы Г. Ибраһимов фольклор образларына да мөрәҗәгать иткән. Нәтиҗәдә, туган авылы янындагы сихри Кондызлы күлен, анда яшәүче төрле серле затларга кагыл-

ган борынгы ышануларны да укучыга җиткерә алган дип әйтә алабыз.

## Әдәбият исемлеге

1. Ванслов В.В. Эстетика романтизма / В.В. Ванслов. – М.: Искусство, 1966.– 404 с.

2. Ибраһимов, Г. Әсәрләр: 9 т. / Г. Ибраһимов; төз. Г.К. Камалиев, искәрмәләр һәм аңлатмалар авт. Р.Р. Гайнанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – Т. 1: Хикәяләр (1907 – 1929). – 510 б.

3. Садекова А.Х. Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова / А.Х. Садекова. – Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 1995. – 104 с.

4. Тургенев И.С. Бежин луг / И.С. Тургенев // Тургенев И.С. Записки охотника. – Элиста: Калмыцкое кн. изд-во, 1979.

**И.Р. Муллин**
Институт языка, литературы и искусства
им. Г. Ибрагимова АН РТ, Казань

# ТАТАРСКАЯ ЭПИГРАФИКА АПАСТОВСКОГО И АКТАНЫШСКОГО РАЙОНОВ РТ (к вопросу изучения)

Татарские эпиграфические памятники (надгробные камни), на татарском языке «кабер ташлары», на протяжение почти трехсот лет являются источниками по истории и языку предков татарского народа, но объектом искусствоведческого исследования стали совсем недавно – в конце 20-х гг. XX в. [3; 4; 6]. И в этом ракурсе они аккумулировали в себя огромный потенциал и интересуют нас «как особый феномен художественной культуры, возникший на основе синтеза искусств: архитектуры, резьбы по камню и каллиграфии» [5, с. 108].

Институт языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова ежегодно устраивает комплексные экспедиции в районы Республики Татарстан с целью изучения духовной и материальной культуры татарского народа, в их состав входят исследователи различных областей, в том числе и искусствоведы. В 2009 г. подобная экспедиция была организована в Актанышский район, а в 2010-м – в Апастовский. Результаты первой экспедиции нашли свое отражение в коллективном труде, в котором эпиграфические и археографические поиски описаны Р. Кадыровым [2]. В экспедиции же в Апастовский район РТ участвовал автор настоящей статьи, будучи направленным от отдела изобразительного и декоративно-прикладного искусства ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова. Наша цель сводилась к сбору не только эпиграфического материала, но и в целом к изучению особенностей материальной культуры (ДПИ) района.

Р. Кадыров в ходе экспедиции в Актанышский район посетил кладбища 14 деревень; всего им было обследовано 53 камня. Исследователь отмечает небольшой размер надгробных памятников, а также следующую особенность: камни, поставленные до середины XIX в., несколько больше (до 150 - 160 см) относящихся к более позднему периоду. Он выделяет четкую схему организации текста (письмен): в самом начале (верхней части) приводятся аяты из Корана и хадисы пророка, а также, иногда, дата; в середине текста следуют имя непосредственно покойного, его отца, краткое описание человека («тасвирлама», т.е. характеристика); завершает текст просьба прочитать суру «Фатиха» в честь усопшего. Надписи на камнях выполнены старательно, мастерски и аккуратно, в каллиграфии использованы стили сульс, насх и талик, рельеф различный (выпуклый и выемчатый).

Р. Кадыров также обращает внимание на оформление надгробных памятников: строки отделены друг от друга полосками; текст в большинстве случаев взят в рамки, которые включают в себя различные орнаментальные мотивы. Автор также отмечает присутствие на камнях солярных знаков, присущих эпиграфике булгарского золотоордынского периода, а также наличие специфических знаков, встречающихся только на данной территории.

В ходе комплексной экспедиции в Апастовский район Республики Татарстан нами были изучены следующие населенные пункты (включая и Апастово): Аюкудерган, Багишево, Бакырчы (Бакрче), Давликеево, Деушево, Идряс-Теникеево (Идряс-Тенькиево), Кукшум, Кулганы, Куштово, Кзыл-Тау, Танай-Тураево, Тутаево, Черемшан, Чиреево, Чуру-Барышево. Однако, к сожалению, в большинстве случаев надгробные камни дореволюционной эпохи сохранились крайне мало. Причиной этому могло стать качество камня, которое со временем утрачивало нанесенные знаки. С другой стороны, высказывались предположения, что надписи на камнях не делались намеренно – дабы уберечь могилы от осквернения воинствующими миссионерами.

Тем не менее один из самых интересных комплексов надгробных памятников находится именно в Апастовском районе – в деревне Кулганы – это так называемый «Ташбилде» (или «Ташбилге») XIV в. [1, с. 55]. Существует легенда, по которой это кладбище святых воинов-булгар, павших неподалеку отсюда. Архитектоника представляет собой невысокий прямоугольник, оканчивающийся полукругом с заострением на конце. Примечательно, что это место является святым, и люди действительно молятся здесь, прося дождь или здоровье заболевшим родным.

Интересной особенностью надгробий в селе Аюкудерган является то, что их иногда делали из металлических листов, которые ставили вместо утрачиваемых камней. Также представляют интерес знаки родов (тамги), которые вырезались на дереве, в первое время заменявшие надгробие. Эта традиция продолжается и по сей день. Как правило, знаки не переносятся на каменные памятники, но встречаются и исключения.

В Деушево надгробия, относящиеся к первой четверти XX в., изготовлены из бетона, также намечается характерная для последующего времени архитектоника памятника.

В селе Куштово встречаются надгробия, сделанные из бетона с характерной формой, как и в Деушево. Дата, начертанная на памятнике, относится ко второй четверти – середине XX в. Текст: "Б(?)агетдин Җамалетдин углы вафат 1933 нчы елны 66(?) енда".

Памятники в Кзыл-Тау относятся к первой половине – середине XX в. Встречаются как каменные, так и бетонные.

Сравнивая результаты двух экспедиций, которые проводились на одной территории (хотя ранее земли Апастовского и Актанышского районов относились к разным губерниям), можно сделать некоторые предварительные выводы. Во-первых, временной разброс материала совершенно различен, если в Апастовском районе мы наткнулись на комплекс памятников, относящихся к золотоордынскому периоду, а в Актанышском такого мы не наблюдаем. Но в то же время в Актанышском районе пышное

развитие камнерезного искусства относится к первой половине XIX в., а в Апастовском районе нам не удалось найти памятники, относящиеся этому периоду. Несмотря на различия, можно обнаружить сходные моменты. Например, так называемые солярные знаки (шести- и восьмилепестковые цветы) на рамках камней Актанышского района являлись главным украшением на камнях комплекса золотоордынского периода в Кулганах.

## Литература


1. Апасым – гомер бишегем (Земля предков – колыбель моя) / автор һәм китапны төзүче Х.А. Гайнуллин. – Казан, Идель-Пресс, 2000.
2. Кадыров Р. Ташка уелган сәхифәләр: Актаныш районында эпиграфик һәм археографик эзләнүләр / Р. Кадыров // Милли-мәдәни мирасыбыз: Актаныш. – Казан, 2010. – С. 60 – 81.
3. Муллин И.Р. Татарская эпиграфика как вид пластического искусства (проблемы историографии) / И.Р. Муллин // Проблемы истории искусства глазами студентов и аспирантов: материалы научной конференции. – М.: РГГУ, 2010. – С. 114 – 119.
4. Мухаметшин Д.Г. Татарские эпиграфические памятники. Региональные особенности и этнокультурные варианты. – Сер.: Археология евразийских степей. – Казань: Институт истории АН РТ, 2008. – Вып. 6. – 132 с.
5. Червонная С.М. Искусство Татарии / С.М. Червонная. – М.: Искусство, 1987. – 352 с.
6. Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику / Г.В. Юсупов. – М. - Л.: Издательство АН СССР, 1960. – 322 с.

**Ф.Г. Ризванова**
Татарстан Республикасы Кукмара районы
Зур Сәрдек авылы гимназиясе

# ГЫЙБРӘТЛЕ ХӘЗИНӘЛӘР

(Кукмара ягы мәзәкләре)

Ниләр генә юк мәзәкләрдә! Гыйбрәт тә, көлке дә, үгет-нәсыйхәт тә, фәлсәфә дә, шелтә дә - һәммәсе дә бар! Гүяки Хозыр Ильяс шикеллерәк бер картаймый да, әҗәл дә тими торган мәңгелек аксакал сүзләре бу. Әйтерсең, шул ил агасы халык тормышын гомере буена күзәтеп тора да, күргән-белгәнен, мыек астыннан тешен агартып кына җор тел белән безгә җиткерә.

Соңгы елларда вакытлы матбугат битләрендә, бигрәк тә “Татарстан яшьләре”, “Акчарлак”, “Ирек мәйданы”, “Сабантуй” газеталарында мәзәкләр бастыру бик популярлашып китте. Без моңарчы үзебез укый торган дәреслекләрдән Хуҗа Насретдин мәзәкләре белән таныштык. Халык иҗатының бу формасына, гомумән, аз игътибар бирелә шикелле. Хәтта аның аерым исеме дә юк иде. Берәүләр аны анекдот дип, икенчеләре кыска хикәя дип яки башкача атыйлар. Мин үзем шушы гыйбрәтле хәзинәләрне җыю эшенә моннан 3 ел элек керештем.

Ни өчен мәзәкләр җыярга керештем соң? Беренчедән, без укып үскән Хуҗа Насретдин мәзәкләрендә безнең тормыш күрсәтелми, аларда ханнар, патшалар, гомумән, борынгы персонажлар турында сурәтләнә, икенчедән, үз авыз иҗаты булган татар халкының кыйммәтле хәзинәсе төрле җирдә таралып ята, җыйналмаган, өченчедән, Хуҗа Насретдинның мәзәкләрдән торган ничә китабын укып чыктым, бер үк мәзәкләр кабатланып басылган, бер дә яңартылмаган. Ләкин шунысы сөенечле: мәзәкләр һаман иҗат ителеп тора. Үз чорында мәзәкләрне Каюм Насыйри да җыеп бастырган. Хәзерге вакытта да мәзәкләрне җыю, туплап бастыру эше дәвам итә. Аңа язучылар, галимнәр һәм халык үзе дә

актив катнаша. “Мең дә бер мәзәк” (җыючы Г. Бәширов) җыентыгы, “Татар халык иҗаты. Мәзәкләр” китабы (Татарстан китап нәшрияты, 1979) басылып чыкты. Нәкый Исәнбәтнең “Балалар фольклоры” китабына (Татарстан китап нәшрияты, 1984) кергән әсәрләрне автор халыктан үзе җыеп бастырды. Анда балалар мәзәкләре дә байтак. Минемчә, боларның әһәмияте ифрат зур. Чөнки бу мәзәкләрдә асылда үз халкыбыз тормышы, үз гореф-гадәтләребез хакында сүз бара . Мәзәк ул, әкиятләр кебек үк, безгә бабалардан ук калган бай мирас. Ул үзендә борынгыдан бирле тупланып килгән тормыш тәҗрибәсен, гореф-гадәтне саклый. Алай гына да түгел, мәзәкләрдә сүз байлыгы, телнең үзенчәлекле борынгы матур бизәкләре дә сакланган.

Хәзерге вакытта мәзәк жанры тематикасының баюы, эчтәлегенең тирәнәюе һәм заман таләпләренә сизгерлеге артуы күзгә ташлана. Шул ук вакытта мәзәк жанрының абруе да күтәрелде. Хәзер аның эчтәлеге бай, дәрәҗәсе шактый ук югары. Баштарак мәзәк нигездә көлке әсәр, барыннан да бигрәк көлдерү, ягъни күңел ачу чарасы буларак кына танылган иде. Мәсәлән, мин бала чакта Хуҗа Насретдин мәзәкләрен кич утырганда шул максат белән укулары хәтердә калган. Бу мәзәкләрдә игътибар әдәп-әхлак кагыйдәләренең төп баганалары булган иманлылык, гаделлек, вәгъдәдә тору, пакълек, гомумән, камиллеккә омтылу кебек асыл сыйфатларга юнәлтелә. Мәзәк алдакчы, ришвәтче, угры, залим кебекләрне рәхимсез рәвештә фаш итә, уңмаган, ялкау, бушбугаз бәндәләргә, шаян сүзләре белән тешләп, хаталарын искәртә. Мәзәкләрдә халыкның зирәк акылы, гасырлар буенча сыналып килгән кыйммәтле педагогик тәҗрибәсе чагыла.

Хәер, татар халкының үз рухи байлыгы да җитәрлек. Акыллы фикерләргә байлыгы, тематикасының төрлелеге, стиленең камиллеге, теленең үткенлеге, һаман яңара баруы җәһәтеннән безнең мәзәкләр башка халыклар иҗаты арасында күренекле урын тоталар.

Мин җыйган мәзәкләрнең кыйммәте шунда: аларның төгәл адресы бар, димәк, кемгә дә булса кагылышлы. Әйе, җор сүзле, шаян, шук, һәр нәрсәдән кызык таба белүче өлкәннәр һәм дә яшьләр һәр төбәктә дә бар, алар тирә-юньдәгеләрнең дә тормышын байрак, кызыклырак итәләр, тормыш авырлыкларына бирешмичә гомер кичерергә булышалар, акыл бирәләр, кайбер хәлләрдә мәзәкләр гыйбрәт өчен дә сөйләнелә.

Бүгенге көндә 60 яшен тутырып Купка авылында яшәүче Мәскүрә апа Шәймәрданова да мәзәкләр бик күп саклана. Ул үзе шигырьләр, мөнәҗәтләр иҗат итә, мәзәкләр туплау белән дә шөгыльләнә.

Мәскүрә Шәймәрдановадан язып алган берничә мәзәк тәкъдим итәбез.

### Умираллар киртәсе

Аш-Буҗи авылыннан (Кукмара районы) берәү Китәк базарына барырга чыга. Аңа утын сатарга килүче бер рус агае очрый. Базарга баручыга да утын кирәк, әмма базарда да йомышлары бар. Аның русча белүе чамалы була, шулай да үзенең Аш-Буҗидагы өен урыска өйрәтеп җибәрергә уйлый. «Доңгыр-доңгырдан чыккач, умираллар киртәсе, татарский мәчет, русский чиркәү, туда-сюда, направо, шагом марш, безнең өй, выходи да, знакум, бросай утыныңны», - дип өйрәтә. Билгеле, рус агае бернәрсә дә аңламыйча китеп бара.

### Үр менәсе бар әле

Икенче бер абзыйдан урыслар, Янсыбы авылына ничек барырга, дип сорыйлар. Абзый өйрәтә: «Туп-турыдан тут пошел, әзрәк баргач, кәкрерәк пошел, әзрәк баргач, иди да иди», - ди. Тегеләр аңламыйча: «Чего? Чего?» – дип сорыйлар. Абзый чаба-чаба барабыз дип әйтәләр, ахрысы, диеп аңлап: «Чабарсыз, атагызның башы, үр менәсе әле алда», - дигән.

## Кушай, Кушай знакум

Шул ук Буҗидан икәү урыс авылына утынга барганннр. Таныш урысларына кергәннәр. Тегесе боларны өстәл янына утыртып, ашарга кыстый башлаган. «Кушай, кушай, знакум». Ә бу абзыйларның берсенең кушаматы Кушай икән. Ул: «Минем Кушай икәнне монда да беләләр икән, син әйттеңме соң аларга?» – дигән ачу белән иптәшенә.

## Көнбагыш чукындыра

Мин үзем Купка авылында яшәсәм дә, туган авылым Буҗига еш төшәм. Бер төшкәндә тукталышта Латыйп абзыйны очраттым. Исәнләштем, хәлен сорадым. Ул: «Минем хәл әйбәт, кызым. Менә бүтәннәрне генә колхозның вак көнбагышы чукындырып кырып бетерә инде. Кукмарада 7 кешенең сукыр эчәгесенә операция ясадылар», - диде. Колхоз көнбагышына күз салучылар күп иде шул.

## Мае бар дип белерсең

Сеңлемнең иптәш кызының әтисе мактанырга ярата иде. Сеңелем мәктәпкә барганда аларга кергәч, әтисе кызына: «Кызым, ипиеңә май як, күп итеп як», - дигән. Кызы аңа каршы: «Ай-яй, мае бар дип белерсең». – дип куйган.

## Тәкә бәрәнли

Күршебез Шәрәфетдин абзый Китәк базарыннан суяр өчен тәкә алып кайткан. Ләкин ул аның сарык икәнен белмәгән, тәкәне симертмәкче булып ашата башлаганнар. Беркөнне Бәдәр апа ашарга салырга чыкса, «тәкә» бәкәйләп ята икән. Ул өенә йөгереп кергән дә: «Беттек, Шәрәфи, тәкә бәрәнли», - дип кычкырып җибәргән.

## Үзгәргән Шәмәрдән

Безнең авылдан берәү бүләк-санак салган чемодан күтәреп Шәмәрдәндәге туганнарына кунакка киткән. Электричкадан төшкән дә чемоданын җиргә куеп сокланып карап тора икән: «Үзгәргән Шәмәрдән, үзгәргән». Җиргә куелган чемоданын алыйм диеп иелсә, чемоданыннан җилләр искән. Теге абзый аптыравыннан: «Үзгәрер Шәмәрдән, чукынса», - дип куйган.

### Кая киткән бу саннар

Хәмит абзый сугыштан соңгы елларда амбарда эшли. Беркөнне кайткан ашлыкны язып бара торган дәфтәре өйдә кала, шунлыктан кайткан ашлыкның центнерын уч төбенә язып бара. Үч иткән күк шул көнне Кукмарадан комиссия килеп төшә. «Бүген күпме ашлык кабул иттең ә?» – диләр. Хәмит абый уч төбенә карый, ә андагы саннар ышкылып беткән. Аптыравыннан: «Вәт нәгаләт, кая киткән бу саннар?» – дип куйган.

### Сиңа мине җибәрделәр

Безнең авылдан бер абзыйга Мәчкәрәдән кыз димләгәннәр. Танышырга баргач, ул кыз белән үзенең энесен сөйләштергән. Үзе читтә тора икән. Ризалашканнар. Берникадәр вакыттан кызны алырга төшәләр. Кыз йөзен күрсәтмичә генә арбага чыгып утыра. Кайткач йөзен ачсалар – бөтенләй башка кыз булып чыга. Егет елап җибәргән: «Әни җаным, бу кыз түгел иде, миңа дигәне матур идее», - дигән. Кыз да аптырап калмаган: «Матурны матурга җибәрделәр, мине сиңа җибәрделәр», - дигән.

### Син дә, җаным, килеп җиттеңме?

Безнең Бужида бер-берсенә бер тамчы су кебек охшаган игезәк Зәкия апа белән Факия апа яшиләр. Көннәрдән беркөнне Зәкия апа йомышы төшеп Кукмарага бара, кибеткә керә. Ә анда зур көзге. Зәкия апа көзгедәге үз шәүләсен Факия апа дип белеп: «Ходаем, Факия, син дә килеп җиттеңмени, нәрсә белән килдең?»

– ди. Ә сатучылар берни аңламый аптырап аңа карап торалар икән.

### Шушы бүрәнәләрне үтә алсам...

Сәрдектә бер абзый, шәп кенә төшереп алгач, өенә кайтырга чыккан. Кайта торгач, исереп егылган. Ул егылган җирдә әзрәк салам бар икән. Теге абзый үзе җирдән мүкәли, үзе: «Шушы бүрәнәләрне үтә алсам, ярар иде», - ди икән.

Купка авылында яшәүче Фаяз Фәтхрахмановтан язып алган берничә мәзәк:

### Дай абзыйга лицомойка

Купка авылында Хәбиблислам абый Шәймәрданов озак еллар шофер булып эшләде. Шактый мәзәкчән кеше. Бервакыт Рәхимулла абый Вәлиуллин белән бергәләп Казанга баралар. Кичкә таба кибетләрдә дә йөрергә вакыт табыла. Рәхимулла абыйга комган кирәк икән, сатуда бар. Тик сатучысы марҗа. Рәхимулла абый Хәбиблисламга карый, тегесенә көч кереп киткәндәй була: «Дай абзыйга лицомойка», - дип әйтеп сала.

### Исеме ничек?

Авыл уртасындагы чишмә янындагы бәләкәй генә йортта Мәрфуга абыстай яшәде. Аңа олысы-кечесе: «Мәрфуга абыстай, Мәрфуга абыстай», - дип кенә тора иде. Шул ук Хәбиблислам абый кичен урамда гәп сатып торганда яшьләрдән сорап куймасынмы: «Әйтегез әле, Мәрфуга абыстайның исеме ничек?» Шунда Рамазан әйтеп сала: «Чыннан да, исеме ничек соң аның?».

### Алар Ленинга да атты

Салырга бик ярата торган берәү бар иде. Салгач хатынына да «өлеш чыгаргалый». Хатыны түзеп-түзеп торган да милициягә

хәбәр иткән. Ун тәүлеккә утырталар тегене. Шунда милиционер сорый:

- Абзый, нигә дип хатыныңны кыйныйсың?

- Күрәалмыйм мин хатын-кыз затын. Хәтта юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленинга да атты алар.

- Молодец, абзый, - дип исерекнең сүзен куәтли милиционер, күрәсең, үзе дә хатыны белән әлләни чөкердәшеп яшәмәгәннәр инде. – Бар, өеңә кайт.

Заманча фикер йөртүе исереккә ярап куя.

## Өянәге килгән вакыт

Хәйдәр абый Касыймовлар бригадысын колхоз командировкага җибәргән була. Шуннан кайтып килешләре, поезд соңлаячак икән. Болар бераз күңел ачып алырга була, берсе исә исереп үк китә дә җиргә ава. Милиционер күреп ала моны. Эшнең нәрсәдә икәнлеген абайлап алгач, Хәйдәр исерекнең өстенә менеп утыра да:

- Берүк кагыла күрмәгез, өянәге килгән вакыт, биш-ун минуттан үтә ул, үтә, - ди. Шулай итеп, иптәшен айныткычтан саклап кала.

## Шауласаң – тәмугка

Авылыбыздан берәүне, аракы исе килә, дип айныткычка ябалар. Камереда бер исерек аунап ята. Шул исерек бераздан торып утыра да: «Абый, сез кем буласыз? Мин кайда?» – дип сорый. «Мин – фәрештә, син оҗмахта ятасың, - ди минем авылдаш. – Шаулама, тик кенә ят. Әнә кечкенә тәрәзәдән газраил карап тора. Шауласаң, тәмугка төшереп җибәрәләр. Исерекнең ике күзе шар була, айнып китә».

40 яшьлек Рәмзия Хөсәенованы «Мәзәкче» дисәң дә була. Ул «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре», мәдәният

йорты директоры, кичәләр вакытында мәзәкләр сөйләп кешеләрне ял иттерә.

### Борын Мортазасымы?

Бабам, колхоз эшенә киткәндә, улы Закирҗанга әйтеп калдыра:

- Улым, менә бу ат сбруйларын, Мортаза абзаң килсә, биреп җибәрерсең, - ди. - Онытма, Борын Мортазасына бирәсе, - дип тә өсти. Төшкә таба, Мортаза абзый ат сбруйларын сорап килгәч, 7 яшьлек Закирҗан:

- Син Борын Мортазасымы? Әти Борын Мортазасына бирергә кушты, - дип әйтеп сала.

- Э-э, э-э, аның «борыны» нәрсәгә инде, - дип, Мортаза абзый дирбиясен алып чыгып китә.

***

Мортаза абзый Чишмәбаш авылының озын гомерле кешеләреннән иде. Кечкенә чакта, әтинең: «Безнең авылда печәнне Мортаза абзый кебек чабучы юк, перәме ялап чаба», - дигән сүзен ишеткәч, икенче көнне зират печәнен чабып яткан бабайлар арасында печән чабучы Мортаза абзыйны карарга киттем.Нәрсә ялый микән, дип, койма ярыгыннан карап тордым, ә ул сөйләшә-сәйләшә печән чаба. Бернәрсә дә яламады. Чиста чабуы булган икән.

***

Зур Сәрдекнең ике агае, Китәк базарыннан кайтышлый, тау өстендәге салам кибәненә елышып бер чирекле шешәдәге көмешкәне «сындырып» утыралар икән. Утыра торгач туңып китеп, җылынырга учак якмакчы булганнар. Кабызалар – сүнә, кабызалар – сүнә, азаплана торгач ут тергезә болар. Җылынып кына утырганда «гөлт» итеп эскерткә ут каба. Саламның кадерле еллары, авыл кешеләре утны сүндерергә чабыша башлыйлар. Сүрхүшләрнең берсе икенчесенә: «Кара әле, малай, учак кабы-

зырга булышучы булмады, җылынырга ни чаклы чабалар», - ди икән.

## Каенанам Рәйсә сөйләгәннәрдән

Авылда, эчеп алса, адашып кайта алмыйча йөрүче агай булган. Төнге өчләр тирәсендә, кышның бер көнендә ишек шакыган тавышка әни уянып чыкса, анда бәсләнеп беткән әлеге агай басып тора икән. Әнигә карап торган, торган да: «Рәйсә, кайсы авыл бу?» – дип сорап куйган.

***

Ике Вагыйз күрше Олыяз авылына балта эшенә барганнар. Хуҗа хатынының пешәр-пешмәс ашын ашагач икесенең дә эчләре бөтереп алган.

Беренче Вагыйз йөгереп бәдрәфкә кергән, икенчесе дә тегесенең чыкканын көтеп йөри икән.

- Вагыйз, чык! – дигән бу. Теге Вагыйз чыгам гына ди икән, тагын кире кереп утыра, ди.

- Вагы-и-й-з, ч-ы-ы-к! – дип ялвара икән тышта калганы. Ләкин тегесе дә чыга алмый.

Бераздан соң тәмам эше харап булганы әйтеп куйган:

- И-и-и, Вагы-й-й-з...

***

Авылда борыны бик озын булган Газиз абый бар иде. Колхоз идарәсеннән (кәнсәләр) чыгып килә икән бу. Кешедән көлергә яратучы бер агай әйтеп куйган: «Чыга борын, чыга борын, кая моның Газизе?».

***

Киров өлкәсеннән эш белән килгән рус хатынын йөк машинасында эшләүче Зәки агага илтеп куярга кушылган. Зәки ага, путевкасына маршрутны язганнан соң «груз» дигән графага «тонна ярым марҗа» дип язып куйган, диләр.

Мәзәкләр шактый борынгы чорлардан ук басыла башласалар да, жанрны фәнни яктан өйрәнү бик соң башлана. Бүгенге көндә иң дөрес бәяне профессор Ф. Хатипов бирә: «Мәзәк дигәннән барыннан да бигрәк шаян рухлы, көтелмәгәнчә тапкыр, көлкеле җыйнак вакыйганы хикәяләп биргән жанрны аңлыйбыз».

Мәзәкләрен җыйнап тикшергәннән соң аларның төп үзенчәлекләренә дә игътибар итик: беренчедән, мәзәк тапкыр һәм көтелмәгән чишелеш белән тәмамлана, икенчедән, реаль эчтәлекле була (хыялый, фантастик вакыйгалар белән һич алышбиреше юк), өченчедән, бер генә эпизодтан тора, дүртенчедән, аларның геройлары зирәк, тапкыр, хәйләкәр кешеләр.

## Әдәбият исемлеге

1. Балалар фольклоры / җыючысы һәм төзүчесе Н. Исәнбәт. – Казан, 1984.

2. Батулла Р. Тузга язмаган сүзләр / Р. Батулла. – Казан, 1997.

3. Мең дә бер мәзәк. – Казан, 1963.

4. Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 2 томда / К. Насыйри. – Казан, 1974, 1975.

5. Татар халык иҗаты: мәзәкләр. – Казан, 1979.

6. Татар халык мәкальләре: 3 томда. – Казан, 1959, 1963, 1967.

7. Туксан тугыз мәзәк. – Казан, 1960.

8. Хатипов Ф. Эпик жанрлар / Ф. Хатипов.. – Казан, 1973.

9. Үзебезнең яктан җыелган мәзәкләр.

**Г. Садыкова, Р. Ә. Минһаҗева**
Алабуга дәүләт педагогия университеты

# БОЛГАР ЧОРЫ ФОЛЬКЛОРЫНДА ЗИНДАН ТЕМАСЫ

Бүген татар халкының үткән юлы, тарихы никадәр катлаулы булуын һәркем белә. Тарихның билгеле бер этапларында аның язмышы драматик, хәтта фаҗигале була.

Гаделсезлек, ачы язмыш, хәсрәт татар халык авыз иҗатына, фольклорга да үтеп кергән. Шул рәвешле, күпгасырлык фаҗигале үткәне булган халкыбыз фольклорында *төрмә-зиндан* мотивы бик борынгы чорлардан ук башлангыч ала. *Тоткынлык* концептына берләшүче *җәза, әсирлек, зиндан, мәхбүс, хисбес, сөрген, казамат* кебек образ-төшенчәләрнең татар халык авыз иҗатында еш таралганлыгы моның ачык дәлиле.

Тоткынлык темасының күренә-чагыла башлавы төрле йолаларга, ышануларга бәйле. Мәсәлән, шундый караш Себер халыкларында (алар нигездә төркиләр), кешеләрнең җаннарын урлап, тоткынлыкта газап чиктерүче явыз көчләр бар, дип санаудан киң таралган булган.

Җан урлау, әлеге җаннарның тоткында газап чигүләре кебек тасвирлаулар татарларда фольклор әсәрләренең хәтта үсүенә, киң таралыш алуына сәбәпче булганнар. Бу иң беренче чиратта халык экиятләрендә күзәтелә. Бай кызларының Дию пәриләре, төрле җен-шайтаннар тарафыннан урланулары, аларның төпсез коеларда, караңгы урманнарда, җиде диңгез артларында тоткынлыкта утырулары, газап чигүләре һ.б.

Әкренләп зиндан темасы, үзгәрешләр кичереп, «миф, экият, дастан, ягъни халык иҗатының барлык чорлары аша үтеп, урта гасыр фольклорына: тарихи җырларга, балладаларга һәм бәетләргә кадәр килеп җитә» [3, б. 177].

*Болгар чоры фольклоры* – бүгенге татар фольклорының бер баскычы, ныклы бер буыны булып тора. Аерым бер жанрларны

искә алмаганда, бу чор фольклоры әле бүгенгесе көндә дә тулысы белән өйрәнелмәгән. Үз эченә күпсанлы җыр, бәетләр, әкиятләр, дастан-легендаларны алган ирек сөючән халкыбызның рухи мирасында *тоткынлык* темасы чагылыш алмый калмаган.

Болгар шәһәренең Аксак Тимер тарафыннан җимерелүе, Казан шәһәре төзелә башлау турындагы легендаларга күз салыйк. Шуларның берсе «Дәфтәр-и Чыңгызнамә»дән: Болгар шәһәрендә халык бик нык аза, намаз укымый, дин кушканнарны үтәмиләр. Аллаһы Тәгалә аларны акылга утырту максатыннан шул җирлекләргә Аксак Тимерне җибәрә. Ул Болгар илен пыран-зыран китереп бетерә: Бикчура ханның һәм аның 12 вәзиренең башын кисә, 36 галимне аса, хатыннарны үзенең сугышчыларына тапшыра, коллыкка мәҗбүр итә.

Монда, әлбәттә, әлеге юлбашчының аяусыз явызлыгы күрсәтелә, ләкин ул Ходай тарафыннан җибәрелгән кеше, ул шул җирдә иман нурларын кабызучы, коткаручы кебек кабул ителә.

«Алпамша» әкияти дастанында мәсәлән, Алпамшаның әсирлектә булуы, зинданга бикләнүе хакында да әйтелгән. Баһадир йокысы белән йоклап яткан Алпамшаны Кылтап рәшәткәле чуен баз койдырып, шунда яптырта. Ул анда егерме дүрт тәүлек йоклагач кына уяна. Галимнәр Алпамшаның бу рәвешле әсирлеккә эләгүен һәм зинданга бикләнүен борынгы, «теге дөнья» турындагы карашлар белән бәйле булуын искәртәләр [1, б. 68]. Зинданда ятканда Алпамша һавада кыр казларын күрә, янына төшкән казның канатына сөеклесе Сандугачка хат яза, каз үз каурыен патша сараена – Алпамшаның яраткан кызы яшәгән йорт тирәсенә ташлап китә. Хатында тоткын Алпамша дусты аша икмәк, су җибәрүләрен үтенә.

Бу чорда *җырлар, бәетләр* дә иҗат ителгән. Аларда күпчелек тарихи вакыйгалар, кеше башыннан кичкән авыр кайгылар да, уңыш-шатлыклар урын алган. Аеруча *тарихи җырларда* нинди дә булса бер легендар шәхес яисә нинди дә бул-

са бер тарихи вакыйга тасвирлана. Легендар затның туганнан алып ахыргы көненәчә яшәве, батырлыклар кылуы мактала.

Болгар чорына караган тарихи җырлар арасында конкрет үрнәкләр күп түгел. Күп кенә әсәрләрдә Болгар кызларының әсирлеккә алынулары, аларның анда иң соң дәрәҗәгә төшерелеп кимсетелүләре ачык чагылыш таба. Мәсәлән, «Болгар иленең кызлары» җырында яшь кызларны төрле орыш-сугышлар барышында әсирлеккә алу һәм ерак җирләргә, Урта Азиягә яки Кавказ якларына, ә бәлки Якын Көнчыгыш илләренә сату ул чорлар өчен гадәти бер күренеш булган:

Шәһри Болгар богдайлары
Чәчми үскән, диләр, бугай,
Шәһри Болгар гүзәлләре
*Әсир* төшкән, диләр, бугай [3, б. 202].

«Болгар ятимәләре» әсәрендә бала чактан ук ятим, яклаучысыз калган кыз балаларның сәүдәгәрләр кулына эләгүе һәм рәхим-шәфкать көтәр урыннарына тоткынлык тормышында җан асрарга мәҗбүр булулары бәян ителә [1, б. 113].

Әлеге дәвер халык авыз иҗаты үрнәкләреннән «Мәрҗән каласы һәм унике кыз» хикәясендә Хуҗалар тавы дигән тауда, имеш, борынгы заманнарда Мәрҗән исемле болгар шәһәре булуы, анда Тырышмал Хуҗа исемле хакимнең берсеннән-берсе матур 12 кызының Болгар шәһәре өчен сугышлар барганда яу артыннан карап торганнары, шуның белән дошманның көчен киметүләре, һәм аларның 12 кызны тотып алып Хуҗалар тавы кырына китерүе, яңа бер тау өяргә йөкләүләре, аларны терелэй җиргә күмергә теләүләре хакында сөйләнелә. Кызлар исә 12 йолдыз булып күккә күтәрелгәннәр, ә Тырышмал Хуҗа, таудан сикереп, елга суына әйләнеп, агып китәргә мәҗбүр булган. Халык хәзер дә шул елга башланган чишмәне изгеләштерә, кызлар өйгән тауны «Кыз тавы» дип атаган, янәсе [2, б. 52 – 53].

Тоткынлык мотивлары әсәрдә турыдан-туры чагылыш тапмаса да, кызларның дошманнарга әсир төшүе, күзәтүчеләр кушканны эшләргә теләмәүләре, коллык газабына күктәге йолдыз тормышын сайлаулары халкыбызның хөр, буйсынмас табигатенә ишарә булып тора. Хикәядә Хуҗа тавы, Изге чишмә турында бәян итү белән белән бергә болгар кызларыбызның ирек сөючәнлеге, үлемсезлеккә омтылуы үзәккә алынган.

Болгар чорында язылган фольклор үрнәкләренең күбесе, кызганычка каршы, безнең көннәргә кадәр үк килеп җитә алмаган. Әмма сакланып калганнарының аерым үрнәкләренә күзәтү ясагач, аларда *тоткынлык мотивларының* әкиятләрдә, дастаннарда, тарихи җырларда, риваять-хикәяләрдә киң таралыш алганын күрәбез.

Коллар, күп очракта кызлар белән сату итү, Болгар дәүләтендә, аның икътисадында еш очрый торган күренеш булган. Тасвирланучы тарихи вакыйгалар төсмере, анда газап астында яшәүчеләрнең ачы күз яшьле тормыш шаукымы шушы чор фольклорында сакланып калып, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән.

### Әдәбият исемлеге


1. Закирова И.Г. Болгар чоры халык иҗаты / И.Г. Закирова. – Казан: Фикер, 2003. – 144 б.
2. Исә Болгар җилләре... Риваятьләр, легендалар, бәетләр һәм тарихи ядькарьләр / төз. С.М. Гыйлаҗетдинов. – Казан, 1992. – 64 б.
3. Урманче Ф.И. Татар халык иҗаты / Ф.И. Урманче. – Казан: Мәгариф, 2005. – 383 б.

**Ә.Г Төхфәтуллина**
Г. Тукай исемендәге
Арча педагогия көллияте укытучысы

# Ш. ГАЛИЕВ ИҖАТЫНДА ПАРЕМИЯЛӘР КУЛЛАНЫЛЫШЫ

Мәкаль-әйтемнәр төрлелеге, үтемлелеге, кулланылышы әһәмияте белән халык иҗатының афористик жанрлары арасында иң активлардан санала [2, б. 9]. Сәнгатьчә алымнарга бай булуы, кыскалыгы, үткен әйтелгән тирән мәгънәсе, ритмик, симметрик үлчәме белән ул күп кенә язучылар, шагыйрьләр өчен рухи азык чыганагы булып тора [4, б. 3]. Паремияләргә һәр язучы үченчә мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, танылган шагыйрь Ш. Галиев иҗатында алар фикерне үткен итеп әйтеп бирү коралы буларак кулланылганнар.

«Ни чәчсәң...» шигырендә бер кешегә карата гына әйтелгән мәкаль, бөтен бер халыкка төбәлеп, гомумиләштерелә һәм үзенең мәгънә төсмерен тагын да киңәйтә: *Токымың иман алмашты, Инде аптырап торырсың... Милләт әйтер туп-турысын: «Ни чәчсәң, шуны урырсың!»* «Татар акылы» шигырендә дә шундый ук күренеш: *«Татар акылы төштән соң» Әле һаман эштән соң...* Мисаллардан күренгәнчә, Ш. Галиев шигырьләрендә паремияләр шигырьнең асылын, төп өлешен тәшкил итәләр. Автор, аларның билгеле бер вакыйгага яисә хис-кичерешкә тәңгәл кигәннен сайлап алып, мәгънә төсмерен киңәйтә яисә аңа образлы итеп аңлатма бирә, хәтта кайбер мондый шигырьләрнең исеме дә мәкаль белән аталган. Нәтиҗәдә автор кулланган мәкальләр, эчтәлек белән тыгыз мөнәсәбәттә килеп, зур тәрбияви чарага әйләнәләр.

Барыбер бер тишеп чыга,
Без ул капчыкта ятмый.

Шуңа күрә, без – капчыкны,
Капчык – безне яратмый... («Без»)

Бу юлы мәкаль үзе үк шигырь тууга сәбәпче. Шагыйрь, кыска гына итеп, халык иҗатына аңлатма бирергә теләгән.

Ш. Галиев бу жанрны баету өстендә дә зур эш алып бара. Кыскасы, ул, халык авыз иҗатындагы мәзәк, хикмәтле сүз, мәкаль, әйтем кебек үткен фикерләүгә нигезләнеп, кыска жанр формаларын заманча яңартуга, аларны әдәбиятның тулы хокук белән яшәргә хаклы актив жанр формалары итеп яшәтүгә ирешә алды [2, б. 324]. Мәсәлән, бүген күпләр халыкныкы дип белгән «Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел» мәкален генә алыйк, үзе үк Ш. Галиев каләменең ни дәрәҗәдә үткен һәм оста булуын күрсәтеп тора торган дәлил бит. Һәркемне уйландырырлык тагын бер мисал:

Бәхет бит ул була күзгә чалынмаучан,
Бәхетлеләр була телгә алынмаучан. («Үкенечле мәхәббәтләр...»)

Сөю, мәхәббәт, бәхет төшенчәсен сурәтләү өчен дә менә нинди үткен сурәт тапкан шагыйрь. Ш. Галиевнең аз сүз белән тирән мәгънә җиткерә алу сәләте «аерылу» һәм «кавышу» темасына язылган «Мәхәббәт» шигырендә дә күренә:

Әле ярый аерылу бар,
Югыйсә шундый шатлыклы
Очрашу булмас иде! («Мәхәббәт»)

Үзенең иҗаты аша балаларга туган тел нечкәлекләрен өйрәтүне максат итеп куйган Ш. Галиев әлеге жанрда да мәкаль һәм әйтемнәрне яратып куллана. Бу юлы инде ул аларны балаларга яраштырып үзгәртеп тә җибәрә:

Көнгә чыккач авызыңны

Гел ерасың, Шәвәли,
Күп көлгән ул елар, ди,
Бер еларсың, Шәвәли. («Сораулы җавап»)

Биредә мәкаль, шагыйрь фантазиясе белән кушылып, әсәрне барлыкка китерүче, оештыручы чара буларак хезмәт итә. Аның автор тудырган икенче өлеше һәрбер баланы, елаган җирдән туктатып, көлдерерлек итеп язылган.

«Кое көзгесе» шигырендә исә Ш. Галиев, халыкның бай иҗат мөмкинлегеннән оста файдаланып, әхлак тәрбиясе алып бара. Бу юлы ул, әсәрнең бетем өлеше булып килгәнлектән, сурәтләнгән вакыйганы, фикерне тагын да калкурак итеп күрсәтә. «Ни югалттың» шигырендә дә шундый ук күренеш: биредә автор халык мәкален бераз гына үзгәртеп, балага вакытның кадерен белергә өйрәтә:

Тимер таптың,
Бакыр таптың,
Алтын вакытың
Югалттың!.. («Ни югалттың?»)

Түбәндәге мисалларда да Ш. Галиев халык мәкален нәкъ менә бала рухына туры килгәнчә үзгәртеп бирә: *Кем бәхетен эштә күрә, / Кем бары тик төштә күрә* («Кем кояшы кайчан чыга?»)*; Начар исем бер ябышса, / Булмый икән котылып* («Энә карагы»).

Менә шулай үз тәҗрибәсенә халык тәҗрибәсен кушу шагыйрьнең шәхси йөзен югалтуга китерми, киресенчә, аның поэзиясен тагын да баета, иҗтимагый яңгырашын тирәнәйтә.

Ш. Галиев нәни укучысын, шул рәвешле, үз тирәсендәге дөньяны танып белергә генә түгел, сөйләшә белергә дә, туган телнең байлыгын, матурлыгын, музыкальлеген, шигъри нәфислеген тоярга да өйрәтә.

Элек-электән юморда тел чарасы буларак кулланылган мәкальләр Ш. Галиевтә дә бу үзенчәлекләрен югалтмыйлар, ә киресенчә, төрле яклап баетылалар гына. Шагыйрь еш кына тормыштагы бер күренештән көлү өчен, аңа тәңгәл килгән мәкаль сайлап, мәзәк чишелеш китереп чыгара. Мәсәлән: *Чибәр артыннан кума – / Җете кызыл тиз уңа!* («Җете кызыл...»)*; Әле хәзер дә җаным син, / Шикәрем син, балым син, / Тик гаепкә алмачы: / Күпкә китсә – бал да ачы!..* («Ачы тәҗрибә»).

Гомумән, татар халкының тел хәзинәсе бик бай. Ш. Галиев әнә шул хәзинәдәге һәр сүзне эшкә җигә белә. Аның әсәрләрендә урын алган мәкальләр, шигырьдәге хис белән кушылып, әсәр теленең үткен, җанлы һәм сыгылмалы булуына сәбәп булалар. Хикмәт мәкальнең нәрсә әйтүендә генә түгел бит, ә ничек әйтелүендә дә.

**Әдәбият исемлеге**

1. Галиев Ш. Сайланма әсәрләр: 5 т. / Ш. Галиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.

2. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре / Н. Исәнбәт – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – 189 б.

3. Татар әдәбияты тарихы: 6 т. / Ш.Ш. Абилов, А.Г. Әхмәдуллин, Ф.Г. Галимуллин һ.б. – Казан: Раннур, 2001. – Т. 6. – 544 б.

4. Яхин А. Татар халык иҗаты әсәрләрен системалы итеп тикшерү тәҗрибәсе / А. Яхин, М. Мәһдиев. – Казан: КДУ, 1982. – 133 б.

**Т. Усманова**
Г. Ибрагимов исемендәге тел, әдәбият
һәм сәнгать иституты, Казан

## ФОЛЬКЛОР ОБРАЗЛАРЫ АША Ф. ЯРУЛЛИН ШИГЪРИЯТЕНДӘГЕ МИФОЛОГИК КАТЛАМНЫ ТЕРГЕЗҮ

Халыкның фольклор мирасы шул чорның сәяси, эстетик, әхлакый, дини, мифологик карашларын чагылдырып, милләт яшәешенен елъязмасын булдыра. Татар халкына хас булган сыйфат-билгеләр, аның аңында формалашкан концептлар, әдәбиятта гәүдәләнеш тапкан мифологик катламнар, образ-символлар милли фольклорда да урын ала. Аны аңлау өчен халык авыз иҗаты әсәрләре үзәгендә торган образларны, алар ярдәмендә тудырылган мифологик катламны ачыклау мөһим. Тормыш хакындагы күпкырлы мәгълүматларны чиктән тыш гомумиләштерелгән модельләргә, структураларга, ситуацияләргә «утыртырга» мифлаштыру ярдәм итә [6, б. 128]. Бик борынгы карашларның байтагы кайчандыр безнең халыкта да булуы һич тә шик уятмый. Мифлар – халыкара универсаль күренешләр. Гасырлар буена дәвам иткән иҗади процесста конкрет мифларның сюжетлары һәм мотивлары онытыла бара: халык күңелендә, бигрәк тә милли телдә шул борынгы мифларның төсмерләрен, кыйпылчыкларын, аерым карашларын саклаган сүз берәмлекләре сөйләмә телдә дә, шигърият телендә дә әле хәзер дә актив кулланылышта яшиләр [5, б. 50]. Без дә, әлеге фикергә таянып, фольклорда киң таралган образлар ярдәмендә Ф. Яруллин шигъриятендәге мифологик катламны ачыклауга омтылыш ясап карыйбыз.

Иң беренче нәүбәттә әдип иҗатында киң урын алган *туган як* мотивына тукталыйк. Күпчелек фольклор әсәрләренең үзәгендә торган әлеге мотив шагыйрьнең «Туган як төсе» шигырендә дә урын ала:

Туган якларыма кайтып барыш,
Яшел әле кырда бодай, арыш.
Урманнардан, кыр һәм болыннардан.
Күзләремә тула яшел балкыш.

Шагыйрь биредә үзе өчен кадерле булган туган ягы сурәтен тергезә. *Яшел кыр*, *болын*, *бодай*, *арыш*, *урман*, *басу* – лирик герой өчен якын булган *туган як* төсен тәшкил иткән категорияләр. Алар татар кешесе аңында туган ягы «төс»е буларак сеңеп калган. «Төс» дигәндә, әлбәттә, төсләр палитрасы гына түгел, «туган туфрак» төшенчәсен тәшкил иткән ассоциацияләр, билгесыйфатлар да күздә тотыла. Татар халкында «Анам төсе», «Туган ягым төсе» кебек гыйбарәләр яши. Кеше үзенең күңелендә туган як образын саклап йөртә. Ул һәрвакыт татар акылында, төркитатар рухи хәзинәсе калыпларында формалашып, генетик код буларак һәркемдә яши «туган як төсе» төшенчәләрендә мифлаша. Нәкъ шуны без Ф. Яруллинның алда искә алынган шигырендәге туган як образы чагылышында күрәбез. Туган ягына кайтып барганда, үзенә кадерле булган җирләрне күреп, лирик герой күңеленә моң тула. Моң – сүзләр ярдәмендә аңлатып булмый торган хис-халәт ул. Биредә ул мифлаштыру категориясе буларак та килә. «Туган җир» һәм «моң» бер-берсенә аерылгысыз береккән бөтенлек. Алар һәркайсы үзара ассоциациялашәләр.

Якынайган саен авылыма
Таныш тавыш ишетелә ныграк.
Дулкын-дулкын булып кайнар тавыш
Җанга тула тамырларым буйлап.
    Шушы тавыш мине биләп ала,
    Мин кушылам аңа эчтән генә.
    Туган якларымның тавышы да,
    Тора, ахры, кайнар хистән генә.

Лирик герой өчен газиз туган җире илаһи тавыш буларак саклана. Бу тавыш – туган якны символлаштыра торган тагын бер билге. Ул һәрчак күңелдә булып, туган якка якынайган мизгелдә тагын да ныграк ишетелә башлый. Лирик герой күңелендә тулысы белән туган якның төсе, тавышы, исе урнаша, нәтиҗәдә бөтенлек барлыкка килә.

Тиктомалдан йөрәк ярсый башлый,
Күмелеп калган хатирәләр ташый.

Һәр хатирә әверелә дә кошка,
Юлларыма ап-ак каурый таш-
лый.
Каурыйларны җыям учлары-
ма,
Каурый түгел, гүя моңнар
җыям.
Туган якларымның
моңнарына
Никадәрле кайнар уйлар сый-
ган.

Һәм, әлбәттә, хатирәләр әйләнеп кайта, элекке кичерешләр яңара, үткән көннәр искә төшә. Шушы мизгел лирик герой күңленә моң сала. Туган як моңы кеше күңелен җылытырга сәләтле көч ул. Лирик герой аңында формалашкан туган як төсе – йөрәктә мәңге саклуначак кайнар тавыш та, кайнар уйлар сыйган моң да, кош сурәтенә әверелеп ап-ак каурыйлар ташлаган хатирәләр дә. Күренә ки, шагыйрь *туган як төсе* мотивы аша туган як образын тудыра. Ләкин аның белән генә чикләнмичә, шигыре аша укучысының аң төпкелендә яткан «Изге туган җир» мифологик образ-кодын тергезергә мөмкинлек бирә, туган як турында уйлаганда туган як төсен, тавышын формалаштыруга ярдәм итә.

Шагыйрьнең «Туган як төсе» шигырендә татар мифологиясендәге үзенчәлекле мифик затларның берсе – *Аҗдаһа* образы да кулланылган. Аждаһа, мифик «елан-кош», символ буларак, күк (канатлы) һәм җир-су (аяклы, койрыклы) дөньяларын берләштерә, дөресрәге, аларның гармоник берлеген гәүдәләндерә. Ул гадәттә нинди дә булса илгә яисә шәһәргә һөҗүм итә; халыкны, илне коткарып калу өчен аңа көн саенмы, ел саенмы (төрле әкият-мифларда төрлечә) иң гүзәл кызны ашарга биреп торалар. Еш кына ул патша кызы була [2, б. 84 - 87]. Ф. Яруллин да күпчелек фольклор әсәрләрендә очраган Аждаһа мифологик образын әсәр тукымасына кертеп җибәргән.

Урманда аю, бүреләр
Беткән инде, беткән.
Тик тимер тешле аждаһа
Кимерә аны төптән.

Тимер аждаһа тавышы
Ачы, шомлы, зәһәр.
Һәрбер яфрак дер калтырап
Укый аңа каһәр.

Әлеге өзектән күренгәнчә, аждаһа, әлбәттә, мифологик укылыштагы “елан-кош” түгел. Автор аждаһа образы турындагы

мифның мәгънәсенә таянып, бүгенге көндә кулланылган техник чараларны дөньяны җимерерлек, яшәешне туктатырлык көч булуына ишарә ясый. Лирик герой гына түгел, ә табигать үзе әлеге мәхшәрнең тәмамлануын көткән сыман эчтән генә ачы каһәрли. Аждаһа мифологик образын кулланып, шагыйрь әсәрнең милли эчтәлеген баетып кына калмый, аның аша гомумкешелек проблемаларын да күтәрә. Кешелекне боза, табигать матурлыгын юкка чыгара торган техник чаралар куркыныч мифологик образга – «Аждаһа»га тиңләштерелә. Шагыйрь «мифларда нигездә явыз, хәшәрәт зат, шайтани зат буларак телгә алынган» [2, б. 86] образны кулланып әсәрнең тәэсир көчен арттыра. Шул рәвешле шагыйрь гомумкешелек проблемаларына кагыла, яшәешнең гадәти ритмын бозучы техник чараларга карата үзенең тискәре мөнәсәбәтен ассызыклый.

Ф. Яруллинның «Кереп барам урманга» дип аталган шигыре дә кызыклы.

Көннәр гел кыскарып бара,
Ә төннәр – кара урман.
Ай-йолдызларны һәммәсен
Каплаган кара буран.

Ерак юлга чыкканнарның
Юнәлеше югалган.
Җен-пәриләр кулын сузып
Тора төнге урманнан.

*Кара урман* ул – татарның җаны өчен кадерле, халык авыз иҗаты текстларын баеткан милли образ; җырдан җырга, иҗаттан иҗатка күчә килгән милли мотив. Яшәешнең милли күзаллануы, чагылышы ул [7, б. 152]. Татар халкы мифологиясендә *кара урман* – караңгылык, шомлылык символы булып килә. Урман дигән мифик дөньяда *Шүрәле, Урман шәүлегәне* (яңгыр чакыручы), *Шәке* (урман хисапчысы), *Талпан* (урман сакчысы) яшиләр. Кайчакта урман биләмәләренә *Убырлы карчык, җен-пәриләр, Албасты, Өрәк* кебек түбән рухлар да килеп керәләр [3, б. 144]. Өзектән күренгәнчә, кара урманны хәтерләткән төн патшалыгына кергән лирик герой экияти-мифологик дөньяга чума. Ул да пәриләрнең, халык ышанулары буенча, кешеләрне юлдан яздырып, аң-зиһеннәрен алып кала торган түбән рухлар булуын искәртә. Алга таба автор әсәр эчтәлегенә тагын бер экиятимифологик образны кертеп җибәрә.

Әкияти сәмруг кошка
Ашатып йөрәк итен,
Урман, диңгез өсләреннән
Инде күп очып үттем.

Иран-төрки мифологиясендә, халык авыз иҗаты әсәрләрендә Аждаһа образына каршы куелган *«Сәмруг кош» («Каракош»)* образы билгеле. *Каракош* – мәһабәт мифик кош, рух буларак та билгеле; ул, балаларын аждаһадан яисә башка берәр афәттән коткарган өчен, миф, әкият героена ярдәм итә. Без анализлаган әсәрдә дә әлеге мифологик мотив күзәтелә. Шагыйрь аны тирәнәйтә, көчәйтә. Бу образ аша шигырьдә татар кешесенең аң төпкелендә урын алган җен-пәри, сәмруг кош кебек әкиятимифологик образлар белән бәйле булган мифологик катлам оеша.

Халык әкиятләрендә еш телгә алынган борынгы төрки мифологиядәге канатлы ат образы татарларга бик якын. Алар ат туганда ук канатлы була, аны бары тик җиргә төшкәнче үк тотып алырга гына кирәк дип ышанганнар [1, б. 52]. *Акбүзат* – батырның ышанычлы ярдәмчесе. Әлеге мифологик образ Ф. Яруллин шигъриятендә дә очрый. Мисал өчен, «Акбүз ат булып килермен» шигырен алыйк.

Акбүз ат булып килермен
Беркөн синең яныңа.
Иярләрсең дә чабарсың
Үзеңнең хыялыңа.

Алып китәрмен, җилдереп,
Карурманнар аркылы.
Карурманнарны яктыртыр
Йөрәгемнең ялкыны.

Акбүзат – батырның хыялларын тормышка ашырырдай көчкә ия булган илаһи зат, сөйгәненә канатлы ат рәвешендә килергә өметләнгән лирик герой үзенең бар булганы белән яраткан кешесенә биреләчәге турында әйтә. Ул Акбүзат булып сөйгәнен бәхетле итәргә тели. Әлеге шигырьдә инде без тикшереп үткән карурман образы да урын ала. Ул киләчәктәге каракайгылы көннәр, юлда очраячак киртәләр, авырлыклар турында искәртә. Ләкин Акбүзат рәвешендә килеп баскан лирик геройның мәхәббәте алдында киртәләр дә ава, карурманнар да яктыра, ди автор.

Әкияттәге акбүз ат мин,
Киртә юк юлларыма.
Кара төннәрдә килермен
Яшьлегең кырларына.

Курыкмый шомлы төннәрдән
Көт мине таң атканчы.
Эләктер, йөгәнлә мине,
Кире борылып чапканчы.

Төрки халыкларның эпик традицияләре буенча, батырның аты – илаһи күктән иңдерелгән тылсымлы зат [5, б. 116]. Сөйгәне янына Канатлы ат рәвешендә килгән лирик герой көннәрдән бер көнне күккә ашачагын аңлый, чөнки легенда буенча, җирдәге барлык вазифаларын үтәгәч, Акбүзат күккә аша һәм йолдызга әверелә. Сөйгәненә бөтен барлыгын бирергә әзер булган лирик геройның әлеге хыялый нияте аның мәхәббәтенең никадәр көчле, саф, самими, илаһи булуы турында сөйли. Шигырьнең үзенчәлеге дә шунда: автор милли-мифологик образ аша гомумкешелек өчен уртак булган темаларны яктыртуга ирешә, шигырь фәлсәфи эчтәлекле әсәр дәрәҗәсенә күтәрелә.

Ф. Яруллин «Бүләк итә алам», «Агач ат» кебек әсәрләрендә дә «Акбүзат» мифологик образын «уйната». Халык телендә еш кулланылган образларны үзәккә куйган шигырьләр, әлбәттә, татар укучысына атап язылган. Чөнки ул образларга салынган мәгънәгә башка халык вәкиле тулысынча төшенә алмый. Бу исә, үз чиратында, Ф. Яруллин поэзиясенең халыкчанлыгын, милли үзенчәлеген билгели.

Татар халкында Ай өстендәге Зөһрә кызның язмышын чагылдырган мифологик хикәят яшәп килә. Космогоник күзаллауга корылган әлеге әсәрдә Айдагы тапларның ничек барлыкка килүе аңлатыла. Фольклор жанрларының иң актив төре саналган хикәятнең сюжетында Зөһрәнең матурлыгыннан көнләшкән үги ананың кызны нык рәнҗетеп-җәберләп яшәве, авыруга әйләндерүе һәм җәза буларак ятимәгә төпсез кисмәкне су белән тутырырга кушуы ята. Сюжет үстерелешендә бичара кыз ярдәм сорап Айга ялварган. Ай аңа авыр чиләкләрен күтәрергә ярдәм итә, аннары бер йолдыз, «нурларына чолгап», аны күккә күтәрә. «Үксез дөнья» шигырендә дә шагыйрь татар әкиятләрендә, мәкаль-әйтемнәрдә һәм, гомумән, татар халкы аңында сакланган «Зөрә» кыз образын үзәккә куя.

Тәхетендә төннәр буе тирбәлә Ай,

Зөһрә-кыз да сулар ташып арган бугай.
Чиләкләре чайкала да суы түгелә,
Тамчылары йолдыз булып күккә сибелә.

Шул рәвешле лирик герой күңелендә Зөһрә-кызның язмышына карата үкенеч хисе туа. Автор тарафыннан кулланылган Ай образы лирик геройның авыр, моңсу хисләре белән бәйләнештә бирелә. Чөнки татар халкы аңында Айның төп символик-мифологик мәгънәсе – кешенең ялгызлыгын, сагышын, саргаюын, гомумән, кайгы-хәсрәттә булуын гәүдәләндерү [5, б. 53]. Шигырен автор «Үксез дөнья» дип очраклы гына атамаган. Чөнки җирдә дә Зөһрә-кыз кебек ялгызлар, эти-әнисез, ярдәм-таянычсыз калган ятимнәр әллә никадәр. Шагыйрьнең күңел күзе аларны күрә, ул алар өчен борчыла, ләкин ниндедер үзгәрешләр кертергә үксез дөньяны түгәрәкләргә лирик геройның көче юк.

Әзме җирдә синең төсле язмышлылар,
Ялгызлыктан күзе тулы сагышлылар.
Үги бала, үги ана, үги дөнья,
Үгиләрнең һәрвакытта күзе юлда.

Шагыйрь әлеге шигырендә төрле халыклар мифологиясендә һәм дини фәлсәфәдә төрлечә аңлатынган «язмыш» төшенчәсен дә, гомумиләштереп, әсәр тукымасына кертеп җибәрә. Татар халкының борынгы ышанулары буенча, кеше туганда ук үз өлеше, үз язмышы белән туа. Бу язмыш исә югарыда, ягъни күктә билгеләнеп, кешенең маңгаена язылып куелган, дип саналган. Язмышлары Зөһрә кыз язмышы белән тәңгәл булган ятимнәрнең саны көннән көн арта баруына җаны әрни, күңеле сыкрый авторның. Әсәрдә Зөһрә-кыз турындагы мифны тергезеп, шагыйрь бүгенге вәзгыятькә бәя бирә: көнчелек, мәкер кебек сыйфатлар кеше күңелендә булганда, җирдә ялгызлар, ятимнәр саны артачак, ди ул. Нәтиҗәдә, Зөһрә кыз образы аша автор гомумкешелек мәсьәләләрен күтәрә торган гомумиләштерүләр ясый.

Хәзер шагыйрьнең «Өмет сибик алар өчен дә» шигыренә тукталыйк.

Өметләрне чәчтем аланнарга,

Кар өстенә кара буранда.
Бәлки, алар җиләк булып пешәр
Кышкы салкын кара урманда.
Ул җиләкне төннең уртасында
Барып җыяр ятим Үги кыз.
Бәхетеннән йөзе балкыр аның,
Күңелендә эрер калын боз.

Күренә ки, шигырь гади-гадати түгел: реаль булмаган хәлвакыйгалар тасвирланган, үзенчәлекле ассоциацияләр тудыруга исәпләнгән әсәр. Өметләрнең кышкы салкын кара урманда җиләк булып пешүенә лирик герой үзе дә ышанмый. Ирреаль, хыялый дөнья сурәте тудырып, автор әсәр тукымасына төрки-татар халык иҗатында кайгы-хәсрәт белән сугарылган фаҗигале язмышка дучар ителгән фольклор персонажын, экияти-мифологик *Үги кыз* образын кертә. Аны татар халкына таныш булган Зөһрә кыз символик-мифологик персонажы белән тиңләштерә. Өметләренең акланмаячагын аңлаган лирик герой, мифологик персонажларга мөрәҗәгать итеп, экияти-мифологик дөнья сурәте тудыра. Шул рәвешле илаһи сакраль мәгънә калыбындагы кеше өметенең күкләрдә чынга ашуын, ягъни илаһилашуын искәртә. Шагыйрь татар кешесенең аң төпкелендә мифологик код рәвешендә уелып калган Зөһрә кыз мифологик персонажы аша үзенең хис-халәтен сурәтли.

Халык авыз иҗатының барлык төрләре дә кешеләрнең тормыш турындагы уйлануларын, тәҗрибәсен һәм хыяломтылышларын чагылдыра. Фольклор әсәрләрендә урын алган образ-мотивлар шул халыкның мифологик карашларын формалаштыруга ярдәм итәләр. Без анализлаган шигырьләрдәге фольклор образлары Ф. Яруллин шигъгиятендәге мифологик катламны тергезергә ярдәм итәләр. Аның «Туган як төсе», «Кереп барам урманга», «Акбүзат булап килермен», «Бүләк итә алам», «Агач ат», «Үксез дөнья», «Киек каз юлларыннан», «Өмет сибик алар өчен дә», һ.б.шигырьләрендә татар мифологиясендә очраган Аждаһа, Акбүзат, Сәмруг кош, җен-пәриләр, Зөһрә кыз, Үги кыз образлары урын ала. Әлеге образларга бәйле мифологик мотивны әсәр тукымасына кертеп, автор халык авыз иҗаты әсәрләреннән татар укучысына таныш булган милли дөнья сурәтен тудыра.

Әдип поэзиясендә туган як образы «туган як төсе» төшенчәсендә мифлаша. Без анализлаган беренче шигырьдә «моң» да мифлаштыру категориясе буларак чыгыш ясый. Туган як һәм моң берберсенә береккән бөтенлек булган хәлдә һәрберсе үзара ассоциацияләшәләр. Шул рәвешле, шигырьдә туган як мифологик мотивы урын ала һәм татар укучысы таный алырлык милли дөнья сурәте тудырыла.

## Әдәбият исемлеге


1. Дәүләтшин Г. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы / Г. Дәүләтшин. - Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. - 512 б.
2. Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, имтомнар, сынамышлар, йолалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – Т. 1. - 432 б.
3. Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, имтомнар, сынамышлар, йолалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – Т. 2. - 388 б.
4. Урманче Ф.И. Иңәме соң безгә иман нуры? / Ф.И. Урманче // Татар фольклоры мәсьәләләре. – Казан: Фикер, 2004. – 168 б.
5. Урманче Ф.И. Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек: 3 т. / Ф.И. Урманче. – Казан: Мәгариф, 2008. - Т. 1: А – Г. – 303 б.
6. Федоров А.А. Введение в теорию и историю культуры: словарь / А.А. Федоров. – Москва: Флинта МПСИ, 2005. – 464 с.
7. Шәмсутова А.А. Хәзерге татар әдәбиятында яңарыш: фәнни мәкаләләр / А.А. Шәмсутова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 204 б.
8. Яруллин Ф. Сайланма әсәләр: 5 т. / Ф. Яруллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – Т. 4. - 575 б.
9. Яруллин Ф. Сайланма әсәрләр 5 т. / Ф. Яруллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – Т. 5. - 479 б.

**Г.М. Хәйдәрова**
Кукмара 4 нче гомуми урта
белем бирү мәктәбе

# ЗӘРӘ БОТКАСЫ – ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ КАДӘР ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН БӘЙРӘМНӘРНЕҢ БЕРСЕ

Халык бәйрәмнәре – шул халыкны бердәм милләт итеп берләштерә торган чараларның берсе. Һәр милләтнең үзенә генә хас бәйрәмнәре була. Алар халыкның милли горурлык хисләрен тәрбияләргә, формалаштырырга ярдәм итеп кенә калмыйлар, ә шул хисләрне кичергән кешеләрдә рухи канәгатьләнү дә тудыралар [2, б. 3]

Татар халык календаре, башка халыклардагы кебек, ел фасылларына һәм хуҗалык эшләренә бәйле рәвештә барлыкка килгән. Икенче төрле әйткәндә, халык календарендагы төрле даталар, йола-бәйрәмнәр крестьяннарның ел да бер тәртиптә кабатлана торган хезмәтенә, теге яки бу аграр эшнең кайчан, ничек каршылануына һәм башкарылуына нигезләнеп формалашкан. Шушы юнәлештә эш итеп, магик характердагы төрле йолалар һәм шулар башкарылганда әйтелә торган төрле сүзләр-гыйбарәләр уйлап чыгарылган.

Гасырлар дәвамында барлыкка килгән йола иҗатының төп өлешен җир эшкәртү, иген үстерү, уңыш алу, мал асрауга бәйле йолалар һәм текстлар алып тора. Ел фасылларына бәйле рәвештә әлеге синкретик фольклор дүрт циклга бүленеп йөртелә: кышкы, язгы, җәйге һәм көзге [1, б. 49].

Язгы чәчүгә кадәр үткәрелә торган «Нәүрүз», «Боз озату», «Зәрә боткасы» яки «Карга боткасы», «Балаларның манган йомырка җыюы», «Сөрән» бәйрәмнәре һәм йолалары булган.

«Зәрә боткасы» – язны каршылуга бәйләнешле традицион йолаларның берсе. Аны Малмыж өязенең көньягында, Минзәлә өязенең кайбер авылларында *дәрә боткасы, карга боткасы* дип

тә йөрткәннәр. Ул яз көне «ала карда», ягъни кара җир күренә башлагач, апрельдә үткәрелгән һәм язгы чәчүгә әзерләнү эшләренә бәйләнгән. Бу сакланып калган йолалар җитди характерда булганнар, муллык һәм елның җиңел килүен теләп, бөтен авыл белән үткәрелгәннәр. Зәрә боткасы – Сабан туеның кереш өлеше ул. Сабан туена әзерлек билгеле бер эзлеклелектә уен рәвешендә алып барылган.

Без үзебезнең Киров өлкәсе Вятка Аланы Иске Пенәгәр авылында үткәрелгән *Зәрә боткасы* турында язабыз. Зәрә боткасы сугыш вакытында үткәрелмәгән, ә сугыштан соң инде үткәрелүен дәвам иткән. 1951 елдан соң бу бәйрәм булмый башлаган. Совет хакимияте елларында Сабан туен җәй аена күчерү сәбәпле милләтебез тарихтан килгән, игенченең иң изге эшен олылауга багышлап, яз килүен зур бәйрәм итеп каршы алудан мәхрүм булды. Китап-журнал укыганнардан һәм олыларны тыңлаганнардан чыгып, без бу бәйрәмнәрнең билгеле бер тәртиптә үткәрелүен күрдек.

Билгеләнгән көнне атка атланган ир-атлар, яшь кызлар ярма, сөт, май җыярга чыкканнар. Аларга бала-чагалар да ияргәннәр. Кайбер йортларда егетләрне сыра белән дә сыйлаганнар. Азык-төлек җыеп йөргәндә такмаклап җырлаганнар. Менә шундый такмакларның берсе:

Зәр, зәр, зәрәки,
Иске-москы кәзәки.
Кәзәкиең булмаса,
Кәҗәнекен ал да ки.

Ә инде өйгә якынлашканда, мондый такмак башкарганнар:

Зәр, зәр, зәрәгә,
Иртә торып берсекөнгә сөрәнгә.
Ай диләр, вай диләр,
Мөхәмәян бай диләр,

Берәр кадак май диләр!

Ә кемнең кызлары бар, шундый юллар да өстәп куйганнар:

Берәр кадак май бирмәсәң,
Кызыңны сатабыз, диләр.

Соңыннан азык-төлекләр җыелып беткәннән соң, атларны авылның уртасында булган тирән булмаган Мотыйк күленә кертkәннәр. Аларның чабышуын кызык итеп карап торганнар.

Икенче көнне билгеләнгән җиргә, Ситдыйк тавына, бар халык агылган. «Безгә кашык белән тәлинкә алып килергә кушалар иде,» – дип искә алдылар олылар. Алар бу вакытта бала-чага булганнар бит. Бер зур казанда җыелган бер-ике өлкән яшьтәге хатын җитәкчелегендә бер зур казанда ботка пешергәннәр. Монда мондый такмаклар әйтелгән:

Зәр,зәр, зәрәки,
Иске-москы кәзәки.
Кәзәкигә ут капкан,
Бөтен авыл шаккаткан.

Олылар үзләре белән сыра, ачыбал алып килгәннәр һәм түгәрәк-түгәрәк булып утырып ашаганнар, алып килгән эчемлекләре белән сыйланганнар. Атларда йөргәннәр. Яшьләр «Назалы», «Чүпләмле», «Биш парлы» кебек уеннар уйнаганнар. Тау бите шау-гөр килеп торган.

Болай ботка пешерүләр ачлык галәмәте булмаса да, заманында тыю-тәнкыйтьләү нәтиҗәсендә борынгыдан килгән бу йола да онытылды. Шул сәбәпле, кешеләр бик үтемле, уңай аралашу, салкын кышлар бетүенә шатлану чарасыннан мәхрүм булдылар. Халкыбызның йоласын үтәп, табигать кочагында күмәкләшеп ботка пешереп ашаулары – тамак туйдыру чарасы булмаганлыгы ап-ачык. Милли бәйрәмнәр, йолалар кимү, бетү

сәбәпле, бер-беребез белән аралашу, очрашу, күрешүләр һаман сирәгәя бара. Хәтта авыл җирендә дә бер-берсен белмәүче-танымаучылар арта. Ә, бәлки, ата-бабаларыбыздан калган гадәтне истә тотып, бәйрәмнәрне үткәрергә кирәктер?

Гасырлар дәвамында халыкның күңеленә сеңгән йолалар, бәйрәмнәрнең рухы каныбызда яши әле. Халкыбызның бәйрәмнәре, гомумән, гореф-гадәтләре, йолалары белән кызыксынуы әнә шуны раслый. Кайбер бәйрәмнәребез яңадан торгызыла. Зәрә боткасы Кукмара районының Янил, Үрәсбаш, Биклянгур, Югары Өскебаш, Түбән Өскебаш авылларында бәйрәм ителә. Югары Өскебаш авылында бу бәйрәмнең беткәне юк икән. «Бу бәйрәмне әтиләр дә, апалар-абыйлар да бәйрәм итәләр иде,» – ди бу бәйрәм турында сөйләүче Галимуллина Фирая Наил кызы. Беренче көнне казаннарны, утыннарны әзерләп куялар. Зәрә боткасы өч урында пешерелә: югары очта, түбән очта, Атау урамында. Балалар такмаклар әйтеп төрле ярмалар җыялар. Алар мондый такмак әйтәләр:

Дәр, дәр, дәрәгә,
Иртән торып күкәйгә,
Берсекөнгә сөрәнгә.

Ай диләр, вай диләр,
Бер кашык май диләр.
Фирая апаларны бай диләр.

Җыеп бетергәннән соң, олы кешеләр ботка пешергәннәр. Ботка ашарга бала-чагалар килгән. Калган боткаларны өйләренә биреп җибәрәләр. Кайтканда очраган кешеләргә боткадан авыз иттергәннәр. «Зәңгелә, миңа килмә, миннән кач» дип кабалар ботканы. Бу боткадан авыз итү зәңгелә авыруыннан саклау чарасы булып тора, диләр. Иртәгесен сәгать 4 – 5ләрдә манган йомырка җыярга чыгалар. Шул ук көнне язгы Сабан туе үткәрелгән. Көндезен яшьләр сөлге җыялар. Анда сабын, яулык, сөлге кебек

әйберләр бирәләр. Урам буенча төрле киемнәр киеп, битләрен каплап, Сәмигуллин Наил самовар төзәтүче булып, «кемнең самовар, чәйнек төзәтәсе ба» дип кычкырып йөри. Аның чанасына иске чәйнекләр, самоварлар тутырылган була. Пычракта итекләр киеп, чана өстерәп кызык ясап йөрүче була ул. Бар кеше, балачага кызык итеп карап тора. Төштән соң Сабан туе була. Анда балалар гына катнаша. Алар шигырьләр сөйлиләр, җырлыйлар, бииләр. Җәелгән әйбер өстендә көрәшәләр. Кызык ясап киенгән олылар да киләләр. Сабан туе өлеше ике ел инде төшеп калган.

Традицияләр, халык бәйрәмнәре – аеруча тәэсирле, үтемле тәрбия факторы. Аларда чын халыкчанлык күзгә ташлана, чөнки анда олысы-кечесе катнаша, аралаша, бергәләп уйный, шаяра, көлә, ял итә. Бәйрәмнәр – яшьләрнең тормышка, хезмәткә әзерлеген ачыклау чарасы да [5, б. 27].

Безнең Кукмара 4 нче урта мәктәбендә дә тәрбия чарасы итеп халык педагогикасын кулланабыз. Сабантуй, рус халык бәйрәме масляница кебек бәйрәмнәр мәктәп ачылганнан ук даярлек үткәрелә (1992 еллардан). Бу бәйрәмнәр гореф-гадәткә, йолага әверелеп киткән инде. Сабантуй бәйрәме май урталарында матур бер көнне билгеләнелә. Балалар татар халык киемнәрен киенеп, бер сыйныфтан икенче сыйныфка, җырлап, күңелле итеп кереп йөриләр. Һәр укучы алып килгән бүләкләрен тапшыра. Зәрә боткасы да бу бәйрәмнең бер өлешенә керә. Укучылар төрле ярмалар алып киләләр. Мәйданчыкта бәйрәм шау-гөр килеп тора, төрле уеннар уйнала. Зур казан белән, астына учак ягылып, ботка пешерелә. Ботка бик тәмле була. Бу бәйрәмне тагы да бизи. Мәктәбебездә булган Сабантуйга кунаклар да, әти-әниләр дә чакырыла.

Мәктәпләрдә тәрбия чаралары, бәйрәмнәр күп үткәрелә. Ләкин гореф-гадәт, йола булып киткәне аз. Балалар татар халкының бәйрәмнәре турында аз беләләр, күбесен бөтенләй ишеткәннәре дә юк. Безгә, халкыбыз бәйрәмнәрен яңадан тергезеп, яшь буынны халыкчан итеп тәрбияләүдә аларны киң файда-

ланырга кирәк. Бәйрәмнәрнең үткәрелеп килә торганнарын югалтмыйча киләчәк буынга тапшыру бик зарур.

## Әдәбият исемлеге


1. Бакиров М.Х. Татар фольклоры / М.Х. Бакиров. – Казан, 2008.
2. Уразманова Р.К. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре / Р.К. Уразманова. – Казан, 1992.
3. Уразманова Р.К. Современные обряды татарского народа / Р.К. Уразманова. – Казань, 1984.
4. Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары. – Казан, 1980.
5. Җәләлиева Ш.Ш. Татар халык педагогикасы / Ш.Ш. Җәләлиева. – Казан, 1997.

**А.Х. Хисматова**
Татарстан Республикасы Кукмара районы
Янил авылы

# ТУЙ ЙОЛАСЫ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ТАКМАК-ТАКМАЗАЛАР

(Татарстан Республикасы Кукмара районы
Янил авылы мисалында)

Милли мәдәниятне тулысынча, бөтен барлыгы белән өйрәнү, милли тел, әдәбият, халыкның тарихы, сәнгате, музыкасы һ.б. турында төпле белем булдыру аларга карата кызыксыну уятуны максат итеп куя.

Хәзерге вакытта милли мәдәниятне үстерүгә күп көч куябыз. Ләкин бу гына җитми. Халкыбызның көй-моңнары, гореф-гадәтләре кешенең рухи азыгына әйләнсен өчен, бала кечкенәдән үк үзе дә төрле кичә, уеннарда катнашырга, иҗат итәргә, иң матур гадәтләрне канына сеңдереп үсәргә тиеш. Балаларны тәрбияләүдә ата-бабалардан калган күркәм гадәтләребез, матур сыйфатларыбыз зур әһәмиятка ия. Халык уеннары җитезлек, зирәклек, күмәклек сыйфатларын тәрбияли. Бер-беребезне хөрмәт итәргә өйрәтә, көй, хәрәкәт аша күңелләрдә иҗат уты кабыза.

Безнең мәктәптә «Яшь журналистлар» түгәрәгенә йөрүче укучылар авылыбыздагы милли йолаларыбыз, уеннарыбыз, гореф-гадәтләребезне барлады, шуи исәптән гаилә йолаларын да.

Гаилә йолалары арасында иң күренеклесе өйләнешү, никах туе белән бәйле. Туй – мул сыйны, күңел ачуны аңлата. Бездә туй йолаларын бер-берсенә тыгыз бәйләнгән өч өлешкә бүлеп йөртәләр:

1) туй алды (кыз яучылау, килешү, ярәшү, кыз сорау, кыз елату);

2) туй (никах, язылышу, кыз алу, егет йортында туй уздыру);

3) туй арты (килен токмачы, су юлы күрсәтү, кияү төшерү, сандык сату).

Урыны, ягана карап, туйлар төрлечә үтә. Әлеге хезмәтебездә без Кукмара ягына хас булган туй белән бәйле такмак-такмазалар, әйтемнәр тәкъдим итәбез.

Туй алды гадәтләренең берсе – яучылау. Билгеле булганча, яучы, димче итеп авылның хөрмәткә лаек, йола нечкәлекләрен яхшы белгән зирәк, үткен телле олы кешеләр йөргән. Алар арасында яучылау вазыйфасын шигъри юллар, такмаклар белән башкаручылар да булган.

Ефәк баулы былбыл кош
Бардыр синең илеңдә.
Каеш баулы лачын кош
Бардыр минем илемдә.
яки

Безнең якның күбәләге
Оча-оча болында,
Очраткан бер матур чәчкә.
Шуңа куну уенда

такмакларында былбыл, лачын, күбәләк, чәчкә образлары егет һәм кызны аңлата.

Безнең төбәктә мөселман татарлар керәшен татарлары белән бергә дус һәм тату яши. Элегрәк керәшен татарларында «Кыз елату» йоласы булган. Бүгенге көндә әлеге йола онытылып бара. Кияүгә китәсе кыз янына аның иптәш кызлары җыелганнар, кәләшне бизәндергәннәр, чәчләрен тәңкә үргәннәр, туй киемнәрен киендергәннәр. Кызлар үзләре махсус «Кыз елату» җырларын башкарганнар.

Колагыма таккан алкам
Әткәм-әнкәемнән бүләк.
Кадерле бала идем лә,
Чит йортта мин кемгә кирәк.

Ак кәҗәнең мамыгын ла,
Эрләвеннән авыр тетүе.
Әнкәемнең куенынnan
Әҗәлләрдән авыр китүе.

Атаң-анаң өендә
Урының булыр түрдә.
Килен төшкән җиреңдә
Урын ишек төбендә.

Өй түрендәге каеным
Авышып үсә бер якка.
Озатасыз мине бик еракка,
Кайтып йөри алмам кунакка.

Әлеге такмаклар арасында кызның туган йортыннан аерылуы турында гына сөйләнмәгән. Кайната, кайнананы усал, явыз итеп сурәтләгән такмаклар да җырланган.

Үз анама мин баламын,
Чит ятларга кем булам.
Килен кеше – ким кеше, дип
Какма мине кайнанам.

Чәй ясаган чинаякның
Сиңа бирәм сырлысын.
Иреңнең сеңлесе дә бар –
Ак каенның шырпысы.

«Кыз елату» йоласына карата керәшен татарларында мәкаль-әйтемнәр дә йөри. Мәсәлән, «Үз атаң йортында елап

бетермәсәң, биатаң йортында кан-яшь түгәрсең», «Елап барсаң – көләрсең, көлеп барсаң – сыкрарсың», «Елап бару – бәхет юрау». Шушы әйтемнәргә карап, кызлар яратып кияүгә чыксалар да, елап китә торган булганнар. Кызларның туган йортларыннан елап аерылулары бүгенге көндә дә очрый.

Туй алды йолалары үтәлгәннән соң, туй көне җитә. Кияү егете иптәшләре белән кыз алырга кәләш йортына килә.

Урамнарны иңләп-буйлап,
Тальян гармуннарда сиптереп,
Атлар җигеп, кыңгыраулар тагып,
Кыз алырга килдек җилдереп.

Атларыбыз, атларыбыз,
Канатлы чаптарыбыз.
Безнең дә булыр әле
Киленле чакларыбыз.

Ләкин егеткә җиңел генә өйгә үтәргә ирек бирмиләр, сынаулар үткәрәләр. Ишек төбендә «Ишек бавы» такмагы җырлана.

Ишек бавы бер алтын,
Безнең апа мең алтын.
Ашыкмый тор, җизни абый,
Энеләр бүләк алсын.
Сеңелләр бүләк алсын.

Синең ярың булса да,
Ул – кайненеңнең апасы.
Без белетсыз кертмибез.
Бу бит җәннәт капкасы.

Әлеге җырны кызның энесе яки сеңлесе башкара. Олырак туганнары такмагы:

Кыштырдап та торсын,
Чылтырап та торсын.
Безгә биргән бүләгеңдәй
Тормышыгыз мул булсын.

Пәлтәләрен кисә дә,
Мамык шәлен бәйләми.
Кыз куенына кергәндә
Егет акча җәлләми.

Кыз озату мәҗлесеннән соң кияү, кызның әти-әнисенә рәхмәт әйтеп, кәләшне алып, үз өенә кайта. Туй анда дәвам итә.

Егет өендә киленне каршы алу йоласы уздырыла. Кияүнең әнисе килене белән улына такмаклап теләк тели. Киленгә бал-май каптыра, ак мендәргә бастыра.

Исән килдеңме, балам,
Ак мендәр юлыңа салам.
Төкле аягың белән кил,
Бәхет-тәүфыйгың белән кил.

Юраганың юш булсын.
Курыкканың буш булсын,
Эшләгән эшең уң булсын,
Аш-суларың мул булсын.

Йөзең айдай якты,
Телең балдай татлы,
Күңелең майдай ягымлы булсын.

Туй өйдә дәвам итә. Биредә кода-кодагыйлар үзара такмак әйтешә. Мәсәлән керәшен такмаклары:

Тактадан басма ясыйк,
Тасмадан бантик ясыйк.
Кодалар җыелышканнар,

Бергәләп күңел ачыйк.

“Саклау” тавын менгән чакта,
Шаулый агач башлары.
Шикәрдәй тәмле, балдан татлы
Кодагыйның ашлары.

Капка төпләремдә җигүле ат,
Кемнәр икән аның иясе.
Бу җыруымны җырламас идем
Кодаларым алтын бәясе.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Бал эчәләр дисеннәр.
Җырлап, гөрләшеп утырыйк,
Кодалар килгән, дисеннәр.

Түшләреңә таккан биш тәңкәңнең
Ничек итеп чутын алаем?
Сездәй чибәр кодаларның
Ничек кенә күңелен табаем.

Туйда кода-кодагыйларның күчтәнәчләре чыга. Һәр күчтәнәчкә үзенең такмак-теләге бар.

Каз гомере – кыз гомере
Кыска да, күңелле дә.
Пар казлардай каңгылдашып
Үтсен гомерегез дә.

Бал-май кебек татлы булсын,
Бәхетегез чәк-чәк кебек өелеп торсын.

Туйның күрке – кәләштер,
Табын күрке – икмәктер.
Өстәлегез икмәкле,
Балаларыгыз игелекле булсын.

Кодагыйлар күчтәнәченә рәхмәт әйтү такмаклары:

Икәү икән атыгыз,
Берсен безгә сатыгыз.
Бу кадәрле күчтәнәчне
Ничек тартты атыгыз.

Бәлешегез бигрәк уңган,
Кемнәр генә тартты ярмасын.
Безне шулай зурлаганга
Ходай үзегезне зурласын.

Туйдан таралышканда җырлана торган такмаклар:

Дыңгыр-дыңгыр-дыңгыр чак,
Ат өстендә ыңгырчак.
Сезләргә җитте ятыр чак,
Безгә җитте кайтыр чак.

Дыңгыр-дыңгыр-дыңгыр чак,
Ат өстендә ыңгырчак.
Туй-сыеңны, хөрмәтеңне
Кайтарырбыз бер-бер чак!

Алай итәргә кирәк,
Болай итәргә кирәк,
Хуҗаларга рәхмәт әйтеп
Кайтып китәргә кирәк

Биек икән тавыгыз,
Каршы ява карыгыз!
Без килдек тә кунак булдык,
Инде үзегез барыгыз!

Алай итеш булмасын,
Болай итеш булмасын,

Монда булган монда калсын,
Гаеп итеш булмасын.

Туйлар узганнан соң, туй арты йолалары башлана. Кызның эти-әнисе «Кияү мәҗлесе» үткәрә, аны «Кияү төшерү» дип тә атыйлар. Яшь парлар кыз ягында кунак булалар, ике яки дүрт көн торалар. Бәйрәмнәр узганнан соң, яшьләрне «Кыз бирнәсе» белән озаталар. Бирнә сандыкка тутырыла. «Сандыкчы» сандыкка менеп уутыра да сандыкны бирми.

Сандыгының эчләрендә
Алтын-көмешләре бар.
Кызны сиңа бүләк иттек,
Ә бирнәсен сатып ал.

Сандыгы ла, сандыгы ла,
Сандыгы ла бизәкле.
Кияү сиңа гына бирәм
Бирнәле кыз кирәкме?

Сандыкчыны ризалаткач, сандыкна парлы, тату, урнәк гаиләдә яшәүчеләр күтәреп чыга. Сандыкны биргәч, кияүгә кызның әнисе яки туганнары җырлый торган такмак:

Сандыкларың сандык өстендә,
Бер сандыгың тезең өстндә.
Кеше какса да, син какма,
Ризыгы синең өстеңдә.

Без әби-бабаларыбызның хәтерендә калган, кызганычка каршы, бүгенге көндә бик азы гына кулланыла торган такмак-такмазалар тупладык. Авылларыбызда элеккеге гореф-гадәтләрне, йолаларны хәтерләүче әби-бабаларыбыз бар әле. Алар исән чакта барысын да туплыйсы, торгызасы иде матур йолаларыбызны.

**Әдәбият исемлеге**

1. Татар халык иҗаты һәм уен җырлары. – Казан: Татар китап нәшрияты, 1980.

**И.И.Хуснуллина**
Республиканский центр развития
традиционной культуры, Казань

## МНОГОКОМПОНЕНТНОСТЬ ЖАНРА ЗАГОВОРА

Заговор является самым древним и сложившимся жанром художественного слова и представляет интерес с точки зрения изучения мировосприятия народа. Единство всех компонентов приводит в действие процесс заговора. Согласно взглядам Н.И. Толстого: «Традиционный обряд представляет собой культурный текст, включающий в себя элементы, принадлежащие разным кодам» [1, с. 167-184]. И, соответственно, заговор можно рассматривать в единстве всех своих структурных элементов. Так в жанре заговора выделяются следующие: последовательность действий определяются акциональным кодом; предметы, используемые в процессе заговаривания – реальным (предметным) кодом; слова-благопожелания, молитвы – вербальным; лицо, выполняющее действия по отношению к другому (в данном случае к больному – *Х.И.*) – персональным; пространственная ориентированность действий – локативным, временной показатель – темпоральным кодами.

По определению М.Х. Бакирова [2, с. 34-40], заговор, в основе своей – попытка воздействовать на окружающий себя мир разными словесными формулами, действиями, с помощью каких-либо неведомых сил. Ученый указывает на изначальную связь заговоров с обрядом. Этим объясняется и то, что некоторыми учеными заговор рассматривался в составе обрядового фольклора. Но со временем связь заговоров и обряда утратила свою силу и он стал рассматриваться как самостоятельный жанр.

Заговор – это часть определенного магического ритуала, и его действенность многократно усиливается точным выполнением всех компонентов ритуала [3]. В жанре заговора, как мы уже упоминали, можно выделить единство всех структурных элементов. Для целостного понимания данного жанра необходимо учитывать все элементы. Так как только вербальный или предметный элемент не могут дать полного представления. В ходе сбора материала фольклористу следует акцентировать внимание на каждый из этих элементов и беседовать с информантом используя заранее подготовленный вопросник. Как показал наш опыт беседы с информантами знахарями, фиксация процесса заговора на видеокамеру большинством из них не разрешается. В данном случае исследователю самому следует присутствовать в реальном процессе заговора как сторонний наблюдатель или же непосредственно как человек, который пришел за исцелением от той или иной болезни. Это даст возможность в точности зафиксировать весь процесс.

Рассмотрим каждый из элементов заговора на примере.

В заговоре при испуге используют настой золы и 7 видов разных зерновых культур.

Акциональный код в данном заговоре следующий:

1) по вороту больного проливают настой золы примерно полстакана, произнося благопожелания, просьбы и молитвы из Корана;

2) затем сыпят 7 видов разных зерновых культур и произносят просьбы, пожелания;

3) после процесса заговора высыпанные зерновые собирают и бросают под дерево в саду.

Реальный или предметный код здесь представлен настоем золы и 7 видами зерновых культур (пшеница, рожь, овес, ячмень, просо, гречиха, горох).

Благопожелания, просьбы исцеления и молитвы в данном случае Аятель-Курси представляют вербальный код.

Персональный код реализуется через знахаря и пришедшим к нему больным. Знахарь является тем, кто совершает определенные действия по исцелению, больной – тот на кого всё это направлено.

Совершение данного заговора при испуге не требует конкретного места проведения. Как говорят знахари, это может быть любое прибранное, чистое место в доме.

Темпоральный – временной код определяется временем обращения больного к знахарю. Многие знахари называют благоприятными днями среду, четверг и пятницу.

Обряд запекания ребенка, который у мишар Ульяновской области называется «ныжы куыру» производится в случае проблем мочеиспускания у детей (при детском энурезе).

Акциональный код представлен последовательностью следующих действий:

1) знахарка берет лопату для хлеба, укладывает туда ребенка и отправляет лопату в остывшую печь;

2) следующий этап – диалог одного из родителей ребенка со знахаркой. Родитель поочередно подходит к трем разным окнам и спрашивает у знахаря: «Что делаешь?», на что следует ответ «Запекаю – Ныжы куырам».

Пространство определяется домом, в частности, местом у печи и окнами. Они реализуют локативный код. И печь, и окно несут символическое значение, являясь связующим звеном между внешним и внутренним миром, миром реальным и потусторонним.

Лопатой для хлеба представлен реальный код.

Диалог знахарки и родителя ребенка, произнесение молитв и благопожеланий определяют вербальный код.

Как видно из примеров, заговоры от разных недугов включают в себя несколько структурных элементов. Вера в силу заговора, единство всех структурных элементов, точное их выполне-

ние дают исцеление. Поэтому к изучению заговорной традиции необходимо подходить комплексно.

## Литература

1. Толстой Н.И. Вторичная функция обрядового символа // Язык и народная культура. Очерки по славянской мифологии и этнолингвистике. М., 1995. С. 167-184.

2. Бакиров М.Х. Татар фольклоры: Югары уку йортлары өчен д-лек / М.Х. Бакиров. – Казан: Мәгариф, 2008. – 359 б.

3. http://www.krimova.ru/component/content/article/19-stati/15-zagovory.html. Дата обращения: 30.11.2011

**А. Хәмитова**
Чистай шәһәре 2 нче гимназиясе

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИСТАЙ РАЙОНЫ КЕРӘШЕН ТАТАРЛАРЫНЫҢ КАРГЫШ ҮРНӘКЛӘРЕ

Татар халкы төрле этник һәм этнографик төркемнәрдән тора: Казан татарлары, мишәрләр, керәшеннәр һ.б. Алар барысы да бер тамырдан, бер туфрактан. Шулар арасында керәшеннәр зур бер урын алып тора. Бу төркемнең сөйләмендә, гореф-гадәтләрендә, йолаларында борынгы Болгар дәүләтеннән килгән үзенчәлекләр бүгенге көндә дә сакланып килә.

Мин Чистай районы муниципаль районының Нарат-Елга авылында туганмын. «Нарат-Елганың барлыкка килүе тегәл генә билгеле түгел. Авылның тирә-ягында бик күп нарат агачлары үскән. Шушы нарат агачлары янына бер сунарчы килеп урнашкан, ике нарат арасына куыш ясап, шунда яши башлаган. Аның янына башка гаиләләр дә килеп, куышлар ясап, яши башлаганнар (Әпсәләмов Хөснулла бабай сөйләве буенча).

Минем туган авылымда керәшеннәр белән мишәрләр иңгә-иң куеп, тату гына гомер кичерәләр. Алар борынгы ата-бабаларыбызның тарихына нык әһәмият бирә, аларның йолаларын, гореф-гадәтләрен саклауда зур эш алып бара, халык авыз иҗаты әсәрләрен яшь буынга тапшыруны беренче бурычы итеп саный. Мин дә керәшеннәрнең йолаларын, гореф-гадәтләрен, бәйрәмнәрен, шул бәйрәмнәрдә аралашуларын, анда кулланылган сөйләмне бик яратам. Шул уңайдан мин китапханәләрдән, авылыбызда яшәүче олы яшьтәге әби-баларыбыздан күп кенә материал тупладым. Күршемдә генә торган 82 яшьлек Максимова Мария әби миңа «Нардуган», «Пасха» бәйрәмнәре турында сөйләде, кыска җырлар, такмаклар өйрәтте. Ә Валентин бабай белән Анна әби Петровалар туй җырларын яздырып бирделәр. Бигрәк тә Миняева Валентина әбинең каргышлары бик үзенчәлекле булып тоелды.

*Каргышлар* – татар халык авыз иҗатының сирәк очрый торган жанры. Хәзер инде каргыш дигән сүз аерым бер кешене, күренешне, вакыйганы каһәрләү мәгънәсендә генә сакланып калган. Ләкин ул элегрәк заманнарда үгет-нәсихәт, васыятьнамә, мактау өчен дә кулланылган. Шулай да, кагыйдә буларак, каргышта трагизм өстенлек итә. Каргышлар эчтәлек ягыннан тотрыклы түгел. Каргыш әйтүче һәр кеше, бу жанрның формасын нык саклаган хәлдә, аңа үз фикерен, үз образын сала. Чөнки каргышлар күбесенчә гадәти булмаган конкрет хәлләр, язмышлар, күренешләргә багышлана. Шул ук вакытта каргышлар билгеле кешеләргә дә төбәп әйтелә.

«Без җәш чакта кичке уенга чыга торган иек, җырлаша, такмаклар әйтешә торган иек. Шунда ызгышып та китә торган иек, такмаклар ошамаса. Усалраклары, ачулыраклары каргышлар каргыйлар ие. Аннан суң берәресе бер-бер әйберен җугалтса, шикләнгән кешегә нинди генә каргышлар теләмиләр иделәр. Бу каргышлардан бик курка торган иек, кайберләренең теләкләре

кабул да була торган ие бит» (Валентина әби, Чистай районы, Нарат-Елга авылы).

Безнең авылның керәшен халкында каргышлар бүгенге көндә дә киң кулланыла, аларны хәтта яшьләрдән һәм балалардан да ишетергә мөмкин. Балалар уйнаган вакытта талашып китсәләр, ачуларын шул каргышлар аша белдерәләр, тик бүгенге көндә алар каргыш итеп түгел, ә ниндидер бер әйтем итеп кенә кабул ителәләр. Менә шуларның кайберләре:

1. Күп яшә, озак яшә, йөзгә җиткәнче яшә.
   Дөньяның бөтен рәхәтен,бөтен михнәтен күреп яшә.

2. Гомерең озын булсын, кайгың күп булсын,
   Балаларың чирле булсын,
   Оныкларың ятим калсын.

3. Бүре телен ишет, елан телен ишет.
   Җир йөзендә нинди зар бар,
   Барын да син ишет.

4. Мин күргәннәрне син дә күр,
   Мин ишеткәннәрне син дә ишет.
   Өеңдә эт булып яшә,
   Гүреңдә бүре булып ула.

5. Минекен урлап баемассың,
   Аннан рәхәт күрмәссең.
   Аягың йөрмәс булсын,
   Кулларың череп аксын.

**А. Хөснетдинова**
Арча педагогия көллияте

## ЧИШМӘЛӘРДӘ - ЕРАК ГАСЫРЛАР АВАЗЫ

Һәр төбәкнең үз тарихы, үз моңы, үз көе, тамырлары еракларга барып тоташа торган чишмәләре бар. Һәр чишмәнең үз тарихы бар. Аларның ничек барлыкка килгәннәре, нинди исем кушулары турында төрле риваятьләр яшәп килә. Шуларның берничәсенә тукталып китик.

Безнең бабаларыбыз чишмәләрне күз карасыдай саклаганнар, кайберсен хәтта изге чишмәләр дип тә йөрткәннәр. Изге чишмә дигәч тә, әллә нинди илаһи көчкә ия, дигән сүз түгел. Бу – чишмә суының минераль тозларга бай булуы, сәламәтлек өчен шифалы матдәләрне күп туплавы.

Арча районы Гөберчәк авылында да Сафый абзыйның йорты урам рәтеннән бөтенләй читтә, су буена таба бүлтәеп чыккан тау битендә булган. Урам тормышы аңа бөтенләй кагылмый, ул бөтен хуҗалыгы, бала-чагасы белән урам тормышыннан читтә. Сафый абзыйларның каралты артыннан түбән төшкәч, бер чишмә бар. Чишмәне Сафый абзый карап торган да инде: өстен япкан, чүп-чардан чистарткан, әйләнә тирәсендәге чүп үләннәрен йолкыган, улак ясап куйган, үзенең хикмәтле бакчасына кереп киткәнче чишмәне бер әйләнә торган булган. Шуңадыр, күрәсең, бу чишмәне «Сафый чишмәсе» дип йөртәләр. Ә икенче чишмәне, «Гали чишмәсе»н, исеменнән күренгәнчә, Гали атлы абзый шулай карап торган.

Арча районы Кишет һәм Кышкар авылларындагы чишмәләрнең тарихы үзенчәлекле. Иске Кишет авылында Раилә исемле кыз дөньяга авыр травма белән туган. Шуннан әбисе Арсланова Гөлбәгыйрәм: «Бу бала исән-сау тазарып аякка басса, чишмә юлын ачтырыр идем», – дип әйткән була. Соңрак, 1990 нче елда, Раилә аякка басып йөри башлагач, аның әтисе Арсланов Тәбрис, бабасы Арсланов Әсфәндияр һәм күршеләре Ахметгалиев Гали, Рәис абыйлар бу чишмәгә юл ачканнар. Чишмәгә төшә торган сукмакны, басып су ала торган басманы

һәм чишмә юлын ясап куйганнар. Бабасы чишмә янына яш шомырт куагы һәм усак агачы утырткан. Раиләнең истәлегенә бәйле рәвештә бу чишмәне «Раилә» чишмәсе дип атыйлар.

Кышкар авылындагы чишмәләргә дә тукталып үтик. Моннан бик күп елар монда мануфактура тоткан Муса һәм Мортаза байларның эшчеләре торган. Авылда бу байларның кытап (тыгыз ефәк тукыма) фабрикалары булган. Ә «Фабрик» чишмәсе шушы элекке байларның фабрикалары урынында саркып чыккан. Шунлыктан бу чишмәне “Фабрик чишмәсе” дип атаганнар. Хәзерге вакытта аны матур итеп бурап төзекләндергәннәр.

«Изгеләр чишмәсе» матур итеп буралган, тирә-ягында 4 өянке үсеп утыра. Чишмә янына дога укырга әбиләр, бабайлар килә. Кешеләр акчалар салып китәләр. Авырулар үзләренә шифа, күңелләренә дәва алыр өчен килә әлеге чишмә янына. Чишмәнең саулыкны кайтара алу, су тоту кебек көчләренә ышану өлкән буын вәкилләре арасында байтак. Шуңа бәйле рәвештә бу чишмә «Изгеләр чишмәсе» дигән исемне йөртә.

Ә менә «Караүгез» чишмәсе юлаучыларны, көтүчеләрне, печәнчеләрне үзенең татлы суы белән сыйлап тора. Әлеге чишмәнең шулай ук үз тарихы бар. Авылда бер байның кара үгезе баткаклыкка кереп баткан да, шул урыннан чишмә ургып чыккан, дигән риваять яши. Әлеге үгезне судан көч-хәл белән тартып чыгарганнар. Исеме дә шушы вакыйгага бәйле булып, «Караүгез» икән. 1976 елда тикшеренүләр нәтиҗәсендә әлеге чишмәнең башында бик зур таш барлыгын ачыклаганнар. Әгәр ул ташны кузгатсан, авылны су басарга мөмкин, диелә.

Иске Кишет авылына ерак түгел «Шыгале» зираты дигән урын бар. Анда элек Шаһ Гали хан авылы булган. Бабайлар, анда ике зират урыны бар, дип әйтәләр. Риваять сөйләвенчә, авылның бик зур булмаган 35 – 40 йорты булган. Юлчы шул авылның бер гаиләсенә кереп су сораган. Ләкин аңа берәү дә су бирмәгән. Әлеге юлчы авылны «6 өйдән артмасын, 7 өйгә җитмәсен», – дип каргаган диелә. Беркадәр вакыт үткәч, авылны җир упкан. Бары

тик 6 – 7 йорт кына утырып калган. Авылның капкасы тимердән булган. Әлеге басу капкасы ябылганда тавышы Казанга ишетелгән, имеш. Хәзерге вакытта анда сазлык, баткаклык. Ә калган 6 – 7 гаилә якын-тирә Мәңгәр, Кишет авылларына күчеп беткәннәр. Авылда бер Сабира исемле карчык торып калган. Ул шунда җирләнгән. Кабер астыннан чишмә саркып чыккан. Сабирәттәй бик түзем булганга, бу чишмәгә «Сабыр чишмәсе» дигән атама биргәннәр.

Наласа авылы да чишмәләргә бай. Мәсәлән, авылыбызның югары очында урнашкан Нократ чишмәсе. Борынгы риваятләргә караганда, бу авылга беренче булып килүчеләр үзләрен «нократлар» дип атаганнар һәм бу чишмә янына урнашканнар. Шуңа күрә бу чишмәне Нократ чишмәсе дип атаганнар. Әле дә Нократ бәйрәме үткәрелә. Бу чишмәдән ярты авыл су ала.

Мифтах бабай карап торган чишмә аның кушаматы белән «Балтай» дип атала. Коры мулла чишмәсе елга кырыенда үлеп калган мулла хөрмәтенә аталган: шул җирдә чишмә бәреп чыккан. Хәзер ул кипкән. Тау астында Салкын чишмә бар. Ул чынлап та бик салкын.

Авылдан читтә, төньяктарак «Рабига» чишмәсе челтерәп ага. Өлкәннәр аны Изгеләр чишмәсе дип тә атыйлар. Бу чишмәнең су бик салкын һәм тәмле. Чишмәне карап, чистартып, янына агачлар утырткан кешенең Рабига исемле кызы булган. Кыз буйга җиткән, һәр көнне шул чишмәдән су ташыган. Әммә авырып киткән һәм үлгән. Әтисе чишмәгә кызының исемен кушкан, шуннан бирле бу чишмәне «Рабига чишмәсе» дип йөртәләр икән.

Чишмә – җиребезнең кабатланмас бизәге. Ул халык тормышының истәлек-хатирәләре һәм тарихы турында сөйли.

**А.Ф. Хөснетдинова**
Татарстан Республикасы Буа районы
“Академик Р.З. Сәгъдиев исемендәге
гомуми урта белем мәктәбе”

# ХӘЗЕРГЕ БЕЛЕМ БИРҮ ПРОЦЕССЫНДА ФОЛЬКЛОР

Һәр милләтнең педагогикасы нигезендә шул милләтнең теле һәм әдәбияты ята. Бала фәкать үз туган телендә генә дөньяны бөтен нечкәлекләре белән танып-белә ала. Мәктәпләрдә татар телен һәм әдәбиятын өйрәнү – милли тәрбияне тормышка ашыруның нәтиҗәле бер юлы.

Матур әдәбият әсәрләрен өйрәнү – укучының иң яраткан дәресләреннән берсе. Дөньяны, тормышны, тарихны һәм бүгенгене, кешенең үз-үзен тотышын, психологиясен аңлауга ачкыч ролен үтәгән матур әдәбият – сүз сәнгате, кеше турындагы зур фән ул. Бүгенге әдәбият укыту программалары замана белән бергә атлый. Мәктәптә әдәбият укытуны да тамырдан үзгәртү, аның асылын, максат һәм бурычларын яңадан билгеләү – хәл ителергә тиешле төп мәсьәләләрнең берсенә әверелә.

Халкыбызның гореф-гадәләрен хөрмәтләп, туган телебез белән горурланып, акыл белән яшәрлек шәхес тәрбияләү – безнең төп максатыбыз.

Халкыбыз авыз иҗаты әсәрләре – яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә кыйммәтле чыганак. Халыкның бай рухлы, кешеләрне гүзәл киләчәккә рухландыручы экиятләре, киң колачлы җырлары, тирән фәлсәфи әйтемнәре, тапкыр һәм үткен мәкальләре, үзенчәлекле табышмаклары, яшьләргә сабак бирердәй итеп иҗат ителгән риваять, дастан, легенда, эпослары һәм башка күп төрле иҗат җимешләре киләчәк буынны милләт тормышын дәвам итәрлек, аны үстерүгә өлеш кертерлек итеп

тәрбияләүдә зур рухи чыганак булып тора. Бу кыйммәтле мирасның тарихи һәи тәрбияви әһәмияте елдан-ел үсә бара.

Туган тел чыганагы булган фольклор әсәрләрен урта белем бирү мәктәбендә өйрәнү баларның тел байлыгын, фикерләү сәләтен үстерүгә булышлык итә. Шул нигездә рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучы татар балалары өчен дә әдәбият укыту программасының эчтәлеге үзгәртелде, кече һәм урта яшьтәге укучылар өчен шактый текстлар фольклордан алынды.

Кече яшьтәге мәктәп балаларының уку программасына такмаклар, тел шомарткычлар, экиятләр, мәзәкләр, табышмаклар, санамышлар, мәкальләр һәм әйтемнәр кебек фольклор әсәрләре кертелгән.Укучылар аларның һәрберсен дә бик зур кызыксыну белән өйрәнәләр.

Такмаклар – халкыбыз уеннарында кара-каршы әйтелүче яки биеп башкарыла торган кыска җырлар. Эчтәлеге белән алар балаларның төрле хәрәкәтләр ясавын – кул чабу, баш селкетү, аяк басу, яулык болгау, баштан сыйпау һ.б. – күздә тоталар, кечкенә балаларның хәрәкәт итү ихтыяҗына туры килгән такмаклар рифмалашкан авазларны сиземләү, телнең байлыгын һәм матурлыгын тануны да тәрбияли.

Тел шомарткычларны икенче төрле тел төзәткечләр, тизәйткечләр дип тә йөртәләр. Алар әйтү өчен авыр булган, берберләренә охшаш сүзләрдән төзеләләр. Шуңа карамастан, укучылардан тизәйткечне бик тиз һәм ялгышмыйча әйтеп бирү таләп ителә. Тизәйткечләр, беренчедән, уен-көлке, күңел ачу өчен кулланылсалар, икенчедән, алар сүз һәм иҗекләрне ачык әйтергә, чиста, дөрес итеп сөйләргә өйрәтәләр. Башлангыч сыйныф укучылары өчен бу бик мөһим.

Баланы халыкның рухи мәдәниятенә алып керүче беренче чыганак – экият. Бала өчен экият тыңлау – халыкның рухи мәдәнияте белән таныша башлавына беренче адым.

Әкиятләр – балалар арасында иң популяр әсәрләр. Моның сәбәбе – әкиятләрнең гаҗәеп оста иҗат ителгән, формасы эчтәлегенә тәңгәл килгән булуында һәм әкият табигатьнең балалар табигатенә бик якын торуында. Шунысы үзенчәлекле: халык педагогикасының әкиятләргә салынган мөһим нәтиҗәсе төгәл һәм мавыктыргыч образлар, сюжетлар искиткеч зур осталык белән тыңлаучыга, укучыга җиткерелә. Нәкъ менә шул ягы белән әкиятләр балага, укучыларга турыдан-туры педагогик тәэсир ясый. Кече яшьтәге мәктәп балаларын әкият жанрының өч төре дә кызыксындыра: хайваннар һәм җәнлекләр турында әкиятләр, көнкүреш әкиятләре, тылсымлы әкиятләр.

Мәзәк – борынгы заманнарда ук туып, безнең көннәрдә дә актив яши һәм үсә торган жанр.Аның төп идея-эстетик кыйммәте тормыштагы төрле тискәре күренешләрне сатира-юмор ярдәмендә фаш кылуы, әдәп-әхлак нормаларын ныгытуга, кешеләрдә, бигрәк тә яшь буында югары рухи сыйфатлар тәрбияләүгә ярдәм итүе белән билгеләнә. Кече яшьтәге мәктәп балаларына тәкъдим ителгән мәзәкләр укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алынып төзелгән һәм аларның күпчелеге уку, белем алу темаларына багышланган.

Халык авыз иҗаты әсәрләренең бер төре – табышмаклар. Табышмак – табигать дөньясындагы, халыкның тормыш-көнкүрешендәге барлык җанлы һәм җансыз әйберләрне һәм күренешләрне, исемен атамыйча, читләтеп сурәтләүгә корылган, я булмаса шаян сорау, хәйләкәр мәсьәлә рәвешендә төзелгән, күп вакытта шигъри формага салынган кечкенә күләмле халык авыз иҗаты әсәре. Табышмак – туры уйлап, уратып әйтелгән образлы сөйләм ул. Шул образлы сөйләмнән тыңлаучылар уйланылган предметны эзләп табарга тиешләр. «Табышмак» – «табу» сүзеннән ясалган. Табышмаклар – халыкның афористик иҗат төре. Халык табышмакларын өйрәнү педагогик яктан әһәмияткә ия. Ул укучыларга өстәмә мәгълүмат биреп, тормышны танып-белергә өйрәтеп кенә калмый, укучыларда игътибарлылык,

күзәтүчәнлек сыйфатлары тәрбияли. Аларның эзлекле һәм образлы фикерләү сәләтен үстерүгә булыша, тел байлыгын арттыра, туган телгә мәхәббәт тәрбияли.

Табышмаклар күп төрле булалар. Бер төр табышмаклар бер әйберне икенчесенә турыдан-туры охшату юлы белән иҗат ителгәннәр. Мәсәлән: «Бәләкәй генә эт, өрми дә җибәрми дә» (йозак). Икенче төр табышмаклар сорау рәвешендә булалар: «Берсе чәчә, берсе эчә, берсе үсә – ул нәрсә?» (яңгыр, җир, үсемлек). Хисаплау-санау белән бәйләнешле табышмаклар да була: «Ике сигез – уналты, тагы сигез, тагы алты» (утыз).

Татар фольклорында әкият-табышмаклар да очрый. Аларга мисал итеп «Өч юлаучы», «Кем җиңүче?», «Акыллы бала» әкиятләрен күрсәтергә мөмкин.

Табышмаклар тормышны танып-белергә, зиһенне үстерергә, хәтерне ныгытырга ярдәм итәләр. Алар кыска, җыйнак, рифмалы булалар. Табышмаклар кешенең уйлау, фикерләү сәләтен сыныйлар. Аны әйтүче дә, җавабын табучы да үзен зирәк итеп күрсәтәсе килә.

Халыкның тормыш тәҗрибәсе, дөньяга карашы, тирән акылы, әхлак нормалары бигрәк тә афористик иҗатында, шул исәптән мәкальләрдә, тулы чагыла. Мәкаль дип, телдән-телгә күчеп йөрүче, халыкның зур тормыш тәҗрибәсен туплаган дидактик эчтәлекле, кыска һәм образлы сөйләмнәргә әйтәләр.

Татар халык мәкальләрендә яшь буынны тәрбияләү буенча үзенчәлекле милли яклар белән бергә бөтен кешелек өчен хас булган гомуми фикерләр дә чагыла. Халык мәкальләрендә туган ил, туган җир, хезмәт, акыл һәм һөнәрчелек темалары киң урын алып тора. Халыкның хезмәткә, гыйлем алуга, һөнәр, кәсепкә өйрәнүгә омтылышын чагылдырган, уңганлыкны, тырышлыкны данлаган һәм ялкаулыкны, наданлыкны фаш иткән мәкальләр бик күп. Мәкальләрдә ялкау, булдыксыз, бушка шапырынучы кешеләр тәнкыйтькә дучар була.

Мәкальләрнең тормыштагы ролен балаларга аңлатып бирү тәрбияви яктан бик файдалы. Аларны өйрәнү, хәтердә калдыру, урынлы файдалана белү безнең сөйләмебезне баета, эзлекле фикерләвебезне үстерә, камилләштерә, халыкка, туган телебезгә мәхәббәт, гүзәл сыйфатлар тәрбияли.

Халык һәрвакыт үз туган телен саклап килгән, үз теленә уй һәм хисләрен салган. Кыска, җыйнак, үткен мәгънәне белдергән әйтемнәр халыкның осталык-тапкырлыгын күрсәтә. Алар нәрсәгәдер чагыштырып бәя бирә. Мәсәлән, «күз ачып йомганчы». Күз ачып йомуның бик тиз башкарылуын һәркем белә. Тиз үтәлгән яисә үтәлергә тиеш эш-гамәл дә шуның белән чагыштырыла.Әйтем теге яки бу әйбернең сыйфатын, сыйфат дәрәҗәсен ачыклый. Мәсәлән, «җиде төн уртасы». Әйтемнәр төрле вакыйгаларда төрле мәгънә дә алырга мөмкин. Мәсәлән, «ут борчасы». Ул шаярып та, үз итеп тә, тәнкыйтьләп тә әйтелә ала.

Башлангыч сыйныфлардагы эзлеклелекне дәвам иттереп, укучыларның белемнәрен тулыландыру максатыннан, 5 – 9 сыйныфларда халык авыз иҗатының барлык төрләреннән дә үрнәкләр алынган. Беренчедән, алар укучыларга фольклордан тулырак мәгълүмат бирә, икенчедән, телгә караган белемнәрне гамәли яктан ныгыту өчен материал буларак кулланыла.

Халык авыз иҗаты әсәрләреннән әкият, мәкаль, әйтем, табышмак, тизәйткечләр, шарадаларны өйрәнүне 5 сыйныф укучылары белән дәвам итәбез. Дәреслектә бирелгән «Зирәк карт», «Җил арба» дигән әкиятләрне укыгач, укучылар кешеләрдәге уңай һәм тискәре сыйфатларны капма-каршы куеп, нәтиҗә ясыйлар, үзләренең фикерләрен җиткерәләр. Кайбер укучыларда әкиятләр иҗат итү теләге дә туа. Бу вакытта бала җәмгыятьнең моралең үзләштерә, шәхеснең әхлакый сыйфатларын танып белә башлый, эстетик тәрбия ала.

Мәкаль һәм әйтемнәрне өйрәнгәндә, укучылар белән аларның үзенчәлекле якларын билгеләргә, мәгънәләрен аңларга тырышабыз. Һәр төр әсәргә дә яңадан билгеләмә биреп, башлан-

гыч сыйныфларда өйрәнгәннәрне кабатлыйбыз. Бу әсәрләрне өйрәнгәндә аларны бер-берсеннән аера белүләренә, сөйләмдә дөрес итеп куллануларына, аларны җыеп туплый алуларына ирешүне максат итеп куям.

Табышмаклар – укучыларның иң яратып өйрәнә торган әсәрләреннән берсе. Шуңа күрә, бу теманы өйрәнергә керешкәнче үк, укучыларга табышмаклар табып куярга яки әби-бабаларыннан язып алырга тәкъдим итәбез. Алар дәрескә әзер килеш килеп, бер-берсенә дә табышмак әйтешә алалар. Соңыннан табышмакларның нинди әсәр булуларына нәтиҗә ясыйбыз, үзенчәлекле якларын күрсәтәбез.

Шарада – табышмакның бер төре. Биредә табышмак итеп алынган сүзнең һәр кисәге мөстәкыйль була ала. Шарадалар, бер яктан, ял итү, күңел ачу өчен кулланылсалар, икенче яктан, сүзләрнең төзелешен, дөрес язылышын аңларга да ярдәм итәләр. Ә бу исә укучыларның грамматик белемнәрен үстерүгә зур этәргеч була. (Түтәлдә нинди ике нота үсә? – Фасоль.)

Табышмак-шарадаларның бер төре логогриф дип атала. Башваткычның бу төре тиешле сүзне уйлап табып, андагы аерым иҗекләрне яки хәрефләрне алыштырып кую, өстәү һәм төшереп калдыру юлы белән чишелә. (Тугай кайчан сайрый? – “Р” хәрефе өстәгәч.) Бу теманы өйрәнү укучыларда туган телнең үзенчәлекләрен өйрәнергә ярдәм итә.

Халык авыз иҗатының башка төрләреннән аермалы буларак, җыр һәркемнең үзе белән яши. Җыр – сәнгатьнең киң таралган һәм яратып башкарыла торган төре. Ул кешене гомере буена озата бара: кайгы-хәсрәттә дә, шатлык-куанычта да.

Җыр шигърият һәм музыка кушылудан туа. Бар халык җырлары, аларның иҗат итүчеләре күптән онытылган, ә җырлары телдән телгә күчеп, үзгәреп, шомарып, матурланып әле дә булса яши. Бар шагыйрь һәм композиторлар иҗат иткән профессиональ җырлар. Шагыйрьләрнең кайбер шигырьләрен исә халык үзе

көйгә салып, җырга әверелдерә. Аларны уртак җырлар атамасы белән билгеләргә мөмкин.

Эчтәлек һәм форма ягыннан да җырлар бик үзенчәлекле һәм күптөрле. Татар халык җырлары гадәттә дүрт төркемгә бүлеп күрсәтелә: йола һәм уен-бию җырлары, тарихи җырлар, лирик озын җырлар, кыска җырлар. Мәктәптә бу төр әсәрләр 6 сыйныф укучылары белән өйрәнелә. Дәресләрдә җырлар турында төшенчә бирелә, кеше тормышында җырның әһәмиятле роль уйнавы, жанрлары, аларның үзенчәлекләре, барлыкка килү сәбәпләре аңлатыла. Халык җырлары белән композитор җырларының уртак һәм аермалы яклары күрсәтелә. Татар халык җырларын башкарган күренекле җырчыларыбыз турында мәгълүмат бирелә.

Бәетләр – татар халык иҗатына гына хас милли жанр. Борынгы төрки халыклар иҗатында да, башка милләтләрдә дә бәетләр белән бер рәткә куярдай, аларга тәңгәл килердәй жанр юк. Ике юллы тезмә әсәр гарәпчә «бәет» дип атала. Бәетләр йөзләрчә ел буена халыкның тарихын, аның тормышында булган вакыйгаларны, хезмәт кешесенең кайгы-хәсрәтен, авыр тормыш шартларына нәфрәтен һәм киләчәккә булган якты теләкләрен чынбарлык җирлегендә чагылдырып килә.

Халык тормышына нигезләнеп иҗат ителгән бәетләр – хезмәт ияләре иҗаты, халыкның рухи байлыгын чагылдырган сәнгать әсәрләре ул. Яшь буынга гыйлем һәм тәрбия бирүдә бәетләрнең мөмкинлекләре зур.

Бүгенге көндә халык арасында иң киң таралган «Сак-Сок» бәетен 8 нче сыйныф укучылары белән өйрәнәбез. Ул – халыкның яраткан әсәре. Аның нигезендә «Ана каргышы төзәтеп булмас бәхетсезлекләргә китерә» дигән фикер ята. Монда укучылар белән гаиләдә бала тәрбиясе, кеше язмышы, кеше бәхетсезлеге дигән темаларга әңгәмәләр уздырабыз.

Ә безгә билгеле булган «Сөембикә бәете»ндә Казанның руслар тарафыннан алыну вакыйгасы сурәтләнгән. Бу әсәрдә Сөембикә күп кайгы һәм хәсрәт кичергән гүзәл хатын-кыз була-

рак тасвирлана. Аның образы аша укучыларда кыюлык, батырлык, үз Ватаныңны ярату, үз халкың белән горурлану хисләре тәрбияләргә тырышабыз.

Халык авыз иҗатының күп өйрәнүне таләп итә торган әсәрләрен – риваять һәм легендаларны – без 9 сыйныф укучылары белән өйрәнәбез. Риваять сүзе төрки телләрдә төрле мәгънәләр белдерә. Аларда элеккедән килгән яисә буыннан буынга сөйләнгән вакыйга-хәлләр хикәяләнә. Кайбер риваятьләр тулысы белән уйдырма эчтәлеккә корылган була.

Риваятьләрдә күп очракта тарих түгел, ә тарихи вакыйгаларга, тарихи шәхесләр эшчәнлегенә халыкның мөнәсәбәте чагыла (Сөембикә, Батырша, Колшәриф, Утыз Имәни, Акмулла һ.б. турындагы риваятләр).

Борынгы һәм урта гасырларга караган риваятьләрнең күпчелеге дини-мифологик характерда. Пәйгамбәрләр, изгеләр тормышы турындагы риваятьләр шулар рәтеннән. Татар тарихын өйрәнүдә риваятьләрнең әһәмиятен аңлап, мәгърифәтче Каюм Насыйри күп кенә риваятьләрне халык теленнән язып алган. Дәреслектә бирелгән «Утсыз кайный торган казан», «Хыянәтчегә бүләк» дигән риваятьләрне укучылар бик кызыксынып укыйлар.

Легенда сүзе исә – латин теленнән кергән сүз, укылырга тиеш дигән мәгънәне аңлата. Ул – халык иҗатындагы проза жанрларының берсе. Легенда, риваятьләрдән аермалы буларак, могҗизалыкка, фантастикага нигезләнә. Легендаларның тематикасы бай һәм эчтәлеге төрле. Аларның күбесе күк җисемнәре, үсемлекләр, хайваннар турында. Моннан тыш, кешеләрне, көнкүреш вакыйгаларын тасвирлый, хәзинәләр, тарихи шәхесләр хакында сөйли торган легендалар да байтак. «Кәккүк ничек барлыкка килгән?», «Җир ничек җаралган?», «Зөһрә кыз» дигән легендаларны өйрәнү укучыларга үткән тарихыбыз белән бүгенгебезне чагыштырырга, нәтиҗә ясарга мөмкинлек тудыра.

Әдәбиятының төп өйрәнү объекты – кеше, аның рухи дөньясы. Шуңа күрә дәрес уздырганда мөмкин кадәр иҗади

эшләргә тырышабыз. Укучыларга дәреслек буенча түгел, үзләренә исбат итәргә, бирелгән вакыйгалар буенча нәтиҗә чыгарырга юл куябыз.

Татар халык авыз иҗатын, бәйрәмнәрен, йолаларын, гореф-гадәтләрен өйрәнүдә, милли сыйфатлар тәрбияләүдә, милли үзаң формалаштыруда сыйныф һәм сыйныфтан тыш тәрбия процессының үзенә генә хас булган мөмкинлекләре бар.

Халык авыз иҗаты әсәрләрен дәрестә барысын да өйрәнеп бетерү мөмкин түгел. Алар белән таныштыруны дәрестән тыш тәрбия чараларында да дәвам итәбез. Бу юнәлештә уңышка ирешү өчен, татар теле һәм әдәбияты атналыклары, китап укучылар конференциясе, түгәрәкләр, җыр фестивальләре, халкыбызның күренекле шәхесләренә багышланган очрашулар, әдәби-музыкаль кичәләр, әдәби викториналар, бәйгеләр, бәйрәмнәр үткәрәбез. 5 сыйныфлар өчен «Әкиятләр илендә», 6 сыйныфлар өчен «Татар халык җырлары», 7 – 8 сыйныфлар өчен «Бәетләрдә халкыбыз язмышы», 9 сыйныфлар өчен «Риваятьләр һәм легендалар», «Сөмбелә», «Каз өмәсе», «Нәүрүз», «Милли сабантуй» кичәләрен үткәрү укучыларга белем һәм тәрбия биреп кенә калмый, ә милләтебез, халкыбыз белән горурланып яшәргә чакыра.

Укучыларда әдәплелек, эш сөючәнлек, милли горурлык хисләре тәрбияләү максатыннан, музейларга экскурсияләр оештырабыз, халык авыз иҗаты әсәрләренә багышланган төрле темаларга иншалар язабыз.

Соңгы елларда мәктәпләрдә Татар халык җыры фестивальләрен үткәрү матур гадәткә әйләнде. Аларны оештырганда укучыларның хор белән һәм ялгыз җырлауларына да зур игътибар бирелә. Ә фестивальне алып баручылар җырларның барлыкка килү тарихы белән таныштырып бара.

Халык җырлары – милли профессиональ музыканың мәңгелек нигезе, гасырлар аша буыннан-буынга сакланып һәм камилләшеп килгән олы мирас. Бүгенге көндә аларга игътибар

кимеде. Шуңа күрә укучыларны халык җырлары белән таныштыру, милли моңнарыбыз дөньясына алып керү, шул рәвешле музыкаль белем-тәрбия бирү – һәр мәктәпнең изге бурычы.

Бәйрәм һәм кичәләрдә катнашу телдән чыгыш ясау күнекмәләре бирә, аларны үз фикерләрен расларга өйрәтә, тапкырлыкны үстерә, әдәбият, сәнгать, тарих фәннәре белән кызыксынуларын арттырырга булыша, югары әхлак сыйфатлары һәм туган җиргә мәхәббәт хисләре тәрбияли.

Халык авыз иҗаты – ул халык педагогикасының гыйлем капчыгы, яшьләр яттан белергә тиеш булган тормыш дәреслеге, гасырлар дәвамында ничәмә-ничә яшь буынны тәрбияләүдә тупланган уңай тәҗрибәләр, язылмаган кагыйдәләр кодексы. Халык авыз иҗаты әсәрләренең бөтенесе дә диярлек яшьләргә тәрбия һәм гыйлем бирү идеяләре белән сугарылган.

Халкыбызның күп гасырлык тарихы шуны раслый: татар милләте һәрчак белемгә, яңалыкка омтылган, киләчәк буынны шул рухта тәрбияләгән.

Бүгенге яңарыш шартларында укучыларга милли тәрбия бирү мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Һәр шәхес үз халкының милли гореф-гадәтләрен, мәдәниятен белергә, туган телдә белем алу мөмкинлегенә ия булырга тиеш. Яшь буынга белем һәм тәрбия бирү эше бездән күп көч, үз белемебезне яңартып һәм баетып торуны сорый. Мөгаллимлек эше никадәр генә авыр булмасын, укучыларны рухи һәм физик яктан сәламәт, аларны җәмгыятебез өчен файдалы кешеләр итеп тәрбияли алуыбызга ышанычыбызны югалтмасак иде.

**Әдәбият исемлеге**

1. Татар милли педагогикасы: югары һәм урта педагогика уку йортлары өчен уку ярдәмлеге / Р.Х. Шәймәрданов, Ә.Н. Хуҗиәхмәтов. – Казан: Мәгариф, 2007. – 399 б.

2. Мәктәп педагогикасы: педагогия институтлары һәм училищелары өчен уку ярдәмлеге / Г.Г. Габдуллин, Җ.Г. Нигъмәтов, Ә.Н. Хуҗиәхмәтов һ.б. – Казан: Мәгариф, 1993. – 479 б.

3.Татар фольклоры: югары уку йортлары өчен дәреслек / М.Х. Бакиров. – Казан: Мәгариф,2008. – 359 б.

4. “Раушан көзге”: татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия: педагогия училищеларының мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү бүлеге өчен кулланма / Р.Ш. Халикова. – Казан: Мәгариф, 1993. – 255 б.

5. Кемдә моң бар, кемдә хис бар: татар халык җырлары. – Казан: Мәгариф, 2001. – 183 б.

6. Татар әдәбияты: рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 5 сыйныфы өчен дәреслек (татар балалары өчен) / Ф.Ф. Исламов, Ә.М. Закирҗанов. – Тулыл. 4 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2009. – 223 б.

7. Татар әдәбияты: рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 6 сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия (татар балалары өчен) / Ф.Г. Галимуллин, Ф.К. Мифтиева, И.Г. Гыйләҗев. – Тулыл. 4 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2010. – 206 б.

8. Татар әдәбияты: рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 8 сыйныфы өчен дәреслек (татар балалары өчен) / З.Н. Хәбибуллина, Х.Г. Фәрдиева, Ә.Н. Хуҗиәхмәтов. – Яңартылган 3 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2005. – 207 б.

**Э.И. Шарипова**
Кукмара районы Манзарас авылы мәктәбе

# ШӘРИФ КАМАЛ ИҖАТЫНДА МИФОЛОГИК МОТИВЛАР

Халык авыз иҗаты күп сәнгать төрләренең, шул исәптән язма әдәбиятның да иң борынгы чыганагы һәм җирлеге булган. Һәм ул хәзер дә әдәбият белән тыгыз бәйләнештә тора. Язучылар халык тудырган образларны һәм сюжет-мотивлардан киң файдалану белән беррәттән халыкчанлыкка һәм иҗади осталыкка ирешүдә халык иҗатыннан да күп нәрсә алалар [12, б. 238, 201]. Фольклорның күп кенә сюжет элементлары, мотивлары, образлары хәзерге татар әдәбияты өчен дә продуктив булып тора. Моңа мисал итеп Г. Тукайның «Шүрәле», «Су анасы», «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш», Һ. Такташның «Җир уллары трагедиясе», М. Фәйзинең «Галиябану», Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин», М. Җәлилнең «Ана бәйрәме», «Сандугач һәм чишмә», Г. Бәшировның «Туган ягым - яшел бишек», Т. Миңнуллиның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрләрен телгә алу да җитә [13, б. 359; 9].

Без бу катлаулы синтезның чагылышын XX йөз башының күренекле әдибе Шәриф Камал иҗаты мисалында күрсәтергә булдык, аның «Әүвәл-әүвәл заманда» хикәясенә максатчан анализ ясадык, әлеге хикәянең тылсымлы әкиятләр һәм мифлар белән мөнәсәбәтен күзәттек.

Шәриф Камалның «Әүвәл-әүвәл заманда» хикәясенең сюжеты болайрак. Эш эзләп йөрүче ике егеткә көймәче карт очрый. Ул әлеге егетләргә бәхет турында әкият сөйли. Әлеге хикәянең эчке катламы ике өлештән тора. Интертекстуальлек алымы ярдәмендә автор хикәясенә әкият кертеп җибәрә.

«Әүвәл-әүвәл заманда» хикәясенең төп мотивы – бәхет эзләү. Ул хикәянең ике катламында да урын ала. Әлеге мотив

фольклор әсәрләре аша (бигрәк тә тылсымлы әкиятләр аша) әдәби әсәрләргә үтеп керә. Балигълык яшенә җиткән егет бәхет эзләп чит җиргә чыгып китәргә мәҗбүр була, үзенә күрә инициация үтә. Танылган галим В.Я. Пропп фикеренчә, бик күп тылсымлы әкиятләрнең нигезендә инициация йолалары (рухи яки физик яктан сыналу) һәм аларның төрле вариантларына хас булган үзенчәлекләр ята. Тирәнрәк уйлап карасак, тылсымлы әкиятләрнең күбесе инициация йолаларының күп кенә конкрет детальләрен чагылдыра: кара урман, шундагы могҗизалы күренешләр, әкият героеның вакытлыча үлеп яңадан терелүе, аның аякларын яки кулларын кисү, берәр явыз затның әкият героен «йотып», яңадан терелтүе, һәм иң әһәмиятлесе – тылсымлы әкиятләрнең иң зур күпчелеге геройның кәләш, үзенә хатын эзләве, аны һичшиксез табуы һәм өйләнүе, «утыз көн уен, кырык көн туен» уздыруы һ.б.[14, б. 19, 9].

Әлеге фикерне фольклорист-галим М.Х. Бакиров үзенең “Татар фольклоры” хезмәтендә раслый: “Тылсымлы әкиятләрдә ...инициация институты, ягъни яшүсмерләрне яугирлеккә ...багышлау йолалары да шактый урын алган” [13, б. 359, 120].

Ш. Камал хикәясенең реалистик катламында файдалырак эш эзләп чит җирдә йөрүче бер егет белән урта яшьләрдәге егет сурәтләнә. Безнең игътибарны күбрәк егерме яшьләрдәге егет җәлеп итә, чөнки ул инициация юлына басарга тиешле герой. Көймәче карт та күбрәк аңа карап сөйли. Егет бәхет эзләп, үз дөньясын калдырып, чит дөньяга чыга. Әлеге герой олы юлда сынау үтеп кире үз дөньясына кайтырга тиеш.

Олы юлда егеткә очраган беренче каршылык – ул юл сайлау. М. Бахтин концепциясе буенча, юл сайлау тормыш юлы сайлау белән тиңләштерелә. Тылсымлы әкиятләрдәге өч юл чатында калган геройлар кебек безнең егетебез дә уйланып кала. Геройга юл сайларга көймәче карт ярдәм итә. Юлга чыккан егетләр карттан тирә-як юллар турында сорашалар, киңәш сорыйлар. Көймәче карт авызыннан бик катгый рәвештә: «Хәзер инде, энем,

ул бәхет дигән нәрсәне эзләп маташырга да ярамый: ул инде юк», – дигән сүзләр ишетелә. Һәм шул хакыйкатьне исбатлау өчен, көймәче карт кашсыз йөзек турындагы экиятне сөйли.

Әлеге экият тылсымлы экият категориясенә туры килә. Әкиятне галим В.Я. Пропп тәкъдим иткән морфологик юл белән анализласак, түбәндәге функция-мотивларны аерып чыгара алабыз:

1. Кайгы яки нәрсә дә булса җитмәү хәбәр ителә, геройга үтенеч яки боерык белән мөрәҗәгать итәләр, аны кая да булса җибәрәрләр. Әлеге функция геройны экияткә кертә.
2. Герой ризалаша яки каршы килә.
3. Герой өеннән чыгып китә.
4. Герой сынала, шул рәвешле ул тылсымлы чара яки ярдәмче табуга әзерләнә.
5. Герой кирәкле урынга күчерелә.
6. Герой карамагына тылсымлы чара эләгә.
7. Герой һәм зыян салучы көрәшә.
8. Зыян салучы җиңә.
9. Герой кире кайта [5, б. 400, 25].

Әкият галим В.Я. Пропп аерып чыгарган 31 функция эченә генә сыеп бетми. Мәсәлән, экияттә герой түгел, ә зыян салучы җиңеп чыга. Ләкин герой да үзенә гомерлек дәрес ала: бәхеткә ирешү өчен үз-үзеңә генә ышанырга кирәк.

Әлеге экият инициаль ритуал нигезендә төзелгән: герой өеннән чыгып китә – геройның юлы (хикәяләү объекты) – герой кире кайта.

Тылсымлы экиятләргә хас булганча, хикәяләүнең башы – ул өйне калдырып китү. Өй биредә үз дөнья, сакраль үзәк. Әкиятнең башында гадәттәгечә өйдә космос хөкем сөрә: «Әүвәл- әүвәл заманда ди, Бохараи Шәрифтә булган бер егет. Бер эби карчык булган да япа-ялгызы берүзе» [1, б. 446). Әкият сюжеты һичшиксез геройның өен ташлап китүен таләп итә. Ә әлеге сәяхәтнең сәбәпләре төрле. Биредә анасының үлеме егетнең гадәти тормыш

рәвешенең кискен үзгәрүенә китерә, космос хаоска әйләнә. Герой бәхет эзләп юлга чыга, дәрвиш кыяфәтендә ярдәмче таба аларның юлларының озынлыгын, авырлыгын экияткә хас традицион сүз-формулалар хәбәр итә: «Шулай итеп барганнар-барганнар, көн барганнар, төн барганнар, ай барганнар, ел бараганнар... Тауларны, урманнарны үрләшеп, тырмашып, дәрьяларны, диңгезләрне сал бәйләп йөзеп кичәләр икән» [1, б. 446].

Егет әкренләп үзенең максатына якынлаша. Бәхеткә ирешү өчен төн уртасында җен таифәсе белән генә көч алышасы кала. Биредә төн үзенең традицион символик мәгънәсендә килә һәм көнгә каршы куела. Төн куркыныч, шомлы, теге дөнья вәкилләре хакимлек иткән вакыт. Егет белән дәрвиш җеннәрдән Сөләйман пәйгамбәр йөзеген тартып алалар.

Сөләйман пәйгамбәр йөзеге – татар әдәбияты әсәрләрендә еш кулланыла торган һәм хәзерге вакытта да үзенең продуктивлыгын югалтмаган мотив. Сөләйман пәйгамбәр мөселман мифологиясендә Даутның улы, Инҗилдәге Соломонга туры килә. Коръәндә аның акыллы булуы турында хәбәр ителә [21, б. 78 - 79]. Коръән һәм башка мөселман язмалары буенча Сөләйманга көч һәм хакимлекне аның йөзеге бирә. Йөзекнең бөтен тылсымы алты кырлы йолдыз рәвешендәге кашында тупланылган, дип карала, мөселманнар аның иң көчле талисманнарның берсе булуына ышаналар [4, б. 672, 515]. Менә шундый серле-сихри нәрсәләр экият героена төрле гайре табигый эшләр башкарырга ярдәм итә [13, б. 359, 119]. Ләкин егет теләгенә ирешә алмый, чөнки йөзекнең кашын җеннәр урлап кача. Ә йөзекнең бөтен көче кашында. Дәрвиш егеткә үзенең киңәшен бирә: «Үз-үзеңә генә ышанырга калды», – ди. Егет туган шәһәренә кайтып китә. Әсәргә бу моментта тылсымлы экиятләрдә актив кулланыла торган, мәңгелек әйләнеп кайту мотивының рудименты булган туган якка әйләнеп кайту мотивы килеп керә. Егет чит җирдән бәхетен таба алмыйча, туган ягына кайтып китәргә мәҗбүр була. Әлеге геройның да юлы экияткә хас булганча түгәрәк хасил итә. Ә

хикәя эчендә автор безгә тулы юл тәкъдим итми. Без аның чит дөньяга юнәлгән юлын гына күрәбез, сакраль үзәккә таба булачак юл турында фараз гына кылабыз. Безгә бу турыда хикәягә кертелгән әкият тә хәбәр итә.

Әсәрнең реалистик катламындагы көймәче карт мифологик күзаллауда урын алган карт архетибына (Хозыр Ильяс турында дини мифлардагы образга) туры килә. Аның портретында әлеге архетипка хас булганча ак төс өстенлек итә. Ул егетләргә юллар чатында очрый һәм ярдәм итү йөзеннән ачы хакыйкатьне ачып сала: тылсымлы кашы булган йөзекне җеннәр кулыннан алу авыр, ә кайбер очракта бөтенләй мөмкин булмаган кебек, бәхетне дә чынбарлыктан табу кыен. Адәм баласының гомере бәхет эзләп үтеп китә. Хикәягә «Әүвәл-әүвәл заманда» дип исем бирелү очраклы түгел. Ул әсәрнең реалистик катламы белән романтик катламын, ягъни әкият белән хикәяне, бер ноктага җыя. Һәм мондый вакыйганың төрле вакытта була алуына ишарә итә. Ягъни социаль вакыт биредә мөһим түгел.

Шулай итеп, «Әүвәл-әүвәл заманда» хикәясендә без әкият, мифларның һәм хикәянең үзенчәлекле синтезын күзәтәбез. Бер яктан, хикәянең сюжетын фольклордан, мифологемалардан башлангыч алган бәхет эзләү, инициация, олы юл, мәңгелек әйләнеп кайту мотивлары тотып торса, икенче яктан хикәя эченә тылсымлы әкият үзе кертелгән. Шулай булгач, әсәрләрдә фольклорның аерым элементлары реальләшкән кебек, фольклор әсәрләре үзләре дә тулаем урын алырга мөмкин. Кызыклы нәтиҗәләргә китергән татар әдәбиятын фольклорга мөнәсәбәтле өйрәнү киләчәктә дә дәвам итәр, дип ышанасы килә. Без исә Шәриф Камалның хикәясе белән фольклор мөнәсәбәтен барлау, әдип иҗатына шул яссылыкта бәя бирү омтылышы ясадык.

## Әдәбият исемлеге

1. Камал Ш. Сайланма әсәрләр / Ш. Камал. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. - 446 б.

2. Веселовский А.Н. Историческая поэтика / А.Н. Веселовский; ред., вступ. ст. и примеч. В.Н. Жирмунского. - Л.: Гослитиздат, 1940. – 648 с.

3. Литературный энциклопедический словарь / под общ. ред. В.М. Кожевникова и П.А. Николаева. - Москва: Советская энциклопедия, 1987. – 694 с.

4. Мелетинский Е.М. Поэтика мифа / Е.М. Мелетинский. - М.: Наука, 1976. – 407 с.

5. Мифологический словарь / гл. ред. Е.М. Мелетинский. - М.: Сов. Энциклопедия, 1990. – 672 с.

6. Пропп В.Я. Морфология сказки / В.Я. Пропп. - Изд. 2-е. - М.: Наука, 1969. – 400 с.

7. Путилов Б.Н. Фольклор и народная культура / Б.Н. Путилов. - СПб.: Петербургское востоковедение, 2003. – 457 с.

8. Теория литературы: учеб. пособие: в 2 т. / под ред. Н.Д. Тамарченко. - М.: Академия, 2004. - Т. 1: Теория художественного дискурса. Теоретическая поэтика. – 512 с.

9. Элиаде М. Миф о вечном возвращении. Архетипы и повторяемость / М. Элиаде. - СПб.: Алетейя, 1998. – 256 с.

10. Элиаде М. Аспекты мифа / М. Элиаде. - М.: Академический Проект, 2001. – 240 с.

11. Юнг К.Г. Душа и миф: шесть архетипов / К.Г. Юнг. - М.: Совершенство, 1997. – 384 с.

12. Әдәбият белеме сүзлеге. - Казан: Татар кит. нәшр., 1990. - 238 б.

13. Бакиров М.Х. Татар фольклоры / М.Х.Бакиров. - Казан: Мәгариф, 2008. - 359 б.

14. Урманче Ф. Борын-борын заманда... / Ф. Урманче // Татар халык иҗаты. Әкиятләр. - Казан: Хәтер, 2007. – Б. 3 - 16.

**М.Х. Шәфигуллина**

Кукмара районы
Зур Сәрдек авылы гимназиясе

# УКЫТУ-ТӘРБИЯ ЭШЕНДӘ ТАТАР ХАЛЫК УЕННАРЫННАН ФАЙДАЛАНУ

Без зур үзгәрешләр заманында яшибез. Күңел шул үзгәрешләрнең уңай идеаллар тудыруын, сакланганнарын ныгытырлык җирлек булдыруын көтә. Телисеңме-теләмисеңме, син заман агымына иярергә мәҗбүр. Ә ул заманда татар халкының җырлары, биюләре, уеннары онытылып, искереп бара. Аларны күптән инде берсеннән-берсен мавыктыргыч компьютер уеннары, төрле төсләр белән балкучы уен салоннары, дискотекалар алыштыра. Бик күңелсез хәл, әлбәттә.Чөнки бу уеннарның берсе дә яшьләрне тормышка әзерләүдә, сәләтен үстерүдә йогынты ясамый. Ә яшьләр үзләре дә сизмәстән, хәтта өлкән буын вәкилләре дә шушы уеннарны кулайрак күрә.

Балаларның рухи яктан бай, физик яктан сау-сәламәт булып үсүендә уеннарның әһәмияте бик зур. Олыларга эштән бушаган вакытларында күңел ачу, ял итү, вакыт уздыру өчен бер чара булса, бала өчен уен – чын шөгыльгә, тормыш көрәшенә һәм хезмәткә әзерләнү ул. Нәниләрнең уеннары асылда зурларның тормышы, көнкүреше һәм хезмәтенең бер чагылышы булып тора.

Хәзерге вакытта уеннарны төркемләүдә В. Всеволодский-Гернгросс квалификациясе гамәлдә йөри. Ул барлык уеннарны өч типологик төркемгә: драматик, спорт һәм орнаменталь (җырлы-биюле) уеннарга бүлә.

Җырлы-биюле уеннар нәниләр репертуарында, сан ягыннан күп булмаса да, балалар (бигрәк тә кыз балалар) аларны яратып уйныйлар. Бу төр уеннарда музыка, җыр, такмак хәлиткеч роль уйный. Көй уен хәрәкәтләре белән тәңгәлләшә, җыр һәм такмакларның эчтәлеге хәрәкәтләрдә чагылыш таба.

Җырлы-биюле уеннарда татар халкының милли үзенчәлеге, гореф-гадәтләрнең халыкчанлыгы чагыла. Гасырлар дәвамында буыннан-буынга күчеп, бүгенге көнгәчә сакланып калган элеге уеннар татар халкының йөзек кашы булып тора. Әбием сөйләве буенча, элек җырлы-биюле уеннар аулак өйләрдә, кыз җыеннарында, төрле бәйрәмнәрдә, мәҗлесләрдә яратып уйнала торган булган. Шушы уеннар ярдәмендә кызлар-егетләр бер-берсенә үзләренең сәләтен, җитезлеген, тапкырлыгын күрсәтә алган. Ә бүгенге көндә исә җырлы-биюле уеннарның күбесе онытылган, кайберләре генә бүгенге көндә дә яратып уйнала.

Гимназиябездә «Энҗе бөртекләре» түгәрәге эшләп килә. Бу түгәрәктә татар халкының гореф-гадәтләрен, фольклорын яңадан сафка бастыру өчен зур көч куела. Әби-бабайлардан сорашып, без элек уйналган җырлы-биюле уеннарны кайтару өстендә эшлибез. Уеннарны сорашып кына калмыйбыз, бу уеннарны ата-аналар җыелышларында күрсәтәбез, тәнәфесләрдә уйныйбыз. «Назалы», «Әйлүк лә, сәйлүк лә», «Гөлбану», «Ал кирәк, гөл кирәк», «Ак калач» кебек уеннарны укучылар үз иттеләр.Әлеге уеннарны балаларның үзләре теләп өйрәнүләре шатландыра. Димәк, халык иҗатының бу төренә ихтыяҗ бар.

Әби-бабаларыбыз бик күңелле итеп ял итә белгәннәр. Сорашып йөргән уеннар кызык та, тәрбияви дә. Безнең уйлавыбызча, әгәр дә әби-бабаларыбыздан сорашып җырлы-биюле, хәрәкәтле уеннарны өйрәтсәк, балалар рухи яктан байрак, сәламәтлекләре дә яхшырак булыр иде. Бу уеннарны уйнап үссәләр, бер-берсе белән аралашырга, дус булырга өйрәнерләр иде.

Балаларны тән һәм акыл ягыннан сәламәт үстерү, коллектив дисциплинага күнектерү, нәфислек тойгылары тәрбияләү, ихтыяр көчен арттыру өчен дә кирәк бу уеннар. «Сәламәт тәндә сәламәт акыл» дигән әйтем бар. «Кеше ул йөзе белән дә, сүзе белән дә, җаны белән дә матур булырга тиеш» дибез. Ә бит ул тән һәм җан матурлыклары кешегә үзлегеннән генә бирелми. Сәламәтлекне

дә, тышкы-эчке матурлыкны да яулап алырга, аның өчен көрәшергә тиешбез. Безнеңчә, моның өчен төп өч чара кирәк: эш, уку, уен. Халык уеннары бездә ирекле ярыш рухы, иҗади тапкырлык, үткенлек, өлгерлек тәрбияли. Бу уеннарны уйнап, без үз көчебезгә ышанабыз. Җырлы-биюле уеннар безнең күңелебездә нәфислек тойгысы уята, музыкаль авазларны тоярга, хәрәкәтләрне көйгә салырга өйрәтә. Бу уеннарны уйнаганнан соң безнең күңелебез, тәнебез ял итә, уеннардан җан рәхәте алабыз.

Моның өчен безгә зирәк акыллы әби-бабаларыбыз белән күбрәк аралашып, сорашып уеннарны өйрәнергә, язып алырга һәм аны үзебез дә уйнарга кирәк.

**Әдәбият исемлеге**

1. Исәнбәт Н.. Балалар фольклоры һәм җырлы-биюле йөз төрле уен / Н. Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 430 б.

2. Ягъфәров Р. Татар балалар фольклоры / Р. Ягъфәров. – Казан: Раннур, 1999.

3. Ягъфәров Р. Кабыргалы-камчылы: татар халык уеннары / Р. Ягъфәров. – Казан: Мәгариф, 2002. – 66 б.

**М.Х. Шәфигуллина**
Кукмара районы
Зур Сәрдек авылы гимназиясе

## ТАТАР ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫНДА ЛИРИК ЭНДӘШЛӘР

Татар халык җырларында уңышлы файдаланылган поэтик алымнарның берсе – *лирик эндәшләр.* Бу алым сөйләмнең аһәңен, эмоциональ яңгырашын баету, лирик геройның хис-тойгыларын көчәйтү, җылырак итеп сурәтләү өчен кулланыла. Лирик эндәшләрне без бик борынгы мәҗүсилек чорларыннан калган

шигъри сүз үрнәкләрендә, шулай ук ырым текстларында ук очратабыз. Мәсәлән, «Бака, бака, җилгә оч, җилгә очмасаң, җиргә сең!» («Теш бакасы» әсәреннән), «Ут, уйнама, уйнама»; «Уйнамыек, көлмиек, / Бергә гомер итиек» («Ут теле»), «Син тимәсәң, мин тимәм. / Кара елан, кит, елан» («Елан теле»).

Лирик эндәшләрне ел фасылы белән бәйле поэтик иҗат үрнәкләрендә күрәбез. Менә алар: «И Иш бабай, Иш бабай, Пич башыннан төш, бабай» («Нәүрүз мөбарәкбад!»), «Кызыкайлар, дустыкайлар, җитте ич Нәүрүз айлар» («Нәүрүз җитте, уйнагыз!»), «Эт кояшы, тегеләй кит, Безнең кояш болай кил! Кояш, чык, чык, чык! Болыт, кач, кач, кач, Без уйнарбыз җылыткач!» («Кояш, чык, чык»). Әлеге шигъри алымны без татар халык җырларының барлык төрләрендә дә очратабыз.

Бишек җырларында очрый торган эндәшләрне аерым күздән кичерү кирәк. Чөнки бу төркем җырлар махсус бер контингентка гына багышланганнар. Аларда урын алган эндәшләр балаларга гына юнәлтелгән.

Бишек җырларында эндәшләр арасында сан ягыннан беренче урынны бала сүзе һәм аның иркәләү-кечерәйтү (балакаем) яки тартым кушымчалы (балам) формалары алып тора. Баланы ир бала яки кыз бала буларак аерып атаганнары да бар: кызым, улым.

Үс, *улым*, үс, *улым* әйдә,
Дөнья бик киң, сыярсың һ.б.

Җырларда шулай ук бәбекәй һәм бәбекәем, аның саңгырау варианты пәпә сүзләре теркәлгән. Пәпә һәм пәбэ, бәбә сүзләренең бер үк сүз булуын дәлилли торган фактлар диалектларда күп табыла. Шулай ук алтыным, бәхетем, бердәнберем дигән сүзләр дә еш кулланыла.

*Алтыным* ла син, диеп,

*Ялкыным* ла син, диеп
Үстерәм бәбкәемне
Иркәләп сөеп.

*Бәхетем* минем.
Бәлли-бәү, бәлли-бәү.
Син минем ышанычым,
*Бердәнберем* дигәнем.

Җаның кебек газиз һәм кадерле нарасый бала бишек җырларында гаиләнең гөле (бу сүз гөлием формасында да очрый), бөредән әле генә ачылган чәчәге (сачәгем), ул әни кешенең күз нуры, багалмасы, йолдызы, чибәре, йомрысы, кыйгач кашым, асыл ташы һ.б.

*Кыйгач кашым,*
*Асыл ташым!*
Йоклаек икәү!

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, бу төркем эндәшләрдә дә традицион алымнар (эпитетлар, чагыштырулар, сынландырулар) актив кулланыла.

Син минем *карлыгачым,*
Син минем *сандугачым*,
Бәлли-бәү.бәлли-бәү.

Җаным, балакаем-җаныкаем, бәгърем дип мөрәҗәгать итү шулай ук актив.

Бишек җырларында үзенчәлекле эндәшләр бар. Мәсәлән, и йомрым, йомрым, нәнием. Син минем *нәнием,* / Табигать *җимешем,* дип яратып эндәшү, аны Бәхтияр (гарәпчә бәхетле дигән сүз) дип атау шундыйлардан. Шулай ук алмакаем, аппакаем дип әйтүләрне дә еш очратырга була.

*Аппакаем, алмакаем,*
Йоклаек икәү!

Эндәшләрдә балалар дөньясы белән бәйле хайван исемнәре күзәтелә: песи-матур, нечкәбил; песием, бөркетем, лачыным һ.б.

Син – *бөркетем, лачыным,*
Илгә бүләгем.

Туй йоласына караган һәм лирик җырларда эндәшләрне еш кына җыр исемнәрендә үк күрергә була. «Әтекәем, мине бирәсең», «Ах, кәбәм анакай», «Ах, тыңдашлар, тыңдашлар», «Сайрамачы, былбыл», «Гөлҗиһан, җаныем», «Хәерниса, канат кынам».

Татар халык җырларында актив кулланылышта булган, киң таралган эндәшләр – туган-тумачаларга, дус-ишләргә караган, яраткан, якын күргән кешеләргә мөрәҗәгать итү сүзләре, кош һәм үсемлек атамалары. Лирик җырларда алар шулай ук күп кенә хатын-кыз исемнәрен үз эченә ала. «Бибкәй, Бибинур», «Хәлимә», «Гаделбану», «Галиябану», «Җәмилә, җаныем ла», «Әсмабибкәй, Маһисәрвәр», «Бибкәй, гөлкәй» һ.б.

Кулыңдагы йөзегеңне
Кемнәр әйтер сәйлән дип,
*Бибкәй, гөлкәй,*
Кемнәр әйтер сәйлән дип, аппагым?

Җырларда, бигрәк тә дүртьюллыкларда, лирик герой *башым, газиз башым, йөрәккәем, күз ямем, йөзем* кебек сүзләр ярдәмендә үз-үзенә, үзенең гәүдә өлешләренә эндәшә. Моннан тыш, *Ходай, Алла* сүзләре белән эндәшүләр, туган илгә, аерым шәһәргә исемнәрен атап мөрәҗәгать итүләр еш очрый.

Лирик геройның кошларга һәм үсемлекләр дөньясына, үзенең туган-тумачасына, якын кешеләренә мөрәҗәгать итү

формаларының иң бай үрнәкләре кыз елату кебек йола җырларында һәм лирик җырларда күзәтелә. Дөресрәге, туй йолаларына караган җырлардагы эндәшләр тулысы белән диярлек туганлык, дуслык атамаларына карый. Кыз елату җырларында кыз, үзенең моң-зары, кайгысы турында сөйләгәндә, ата-анасына, туганнарына мөрәҗәгать итә, алардан киңәш сорый, үтенечләрен әйтә. Бу алым җырларны җанлы сөйләм интонацияләре һәм эмоциональ тибрәнешләр белән баета, лиризмны көчәйтә:

Җиң очым тулы җиз төймә,
Кая гына, *анакай,* сибием?
Эчкенәем тулы кайгы-хәсрәт,
Кемгә, *анакай кәбәм,* сөйлием?

Кардәшлек терминнары арасында баш килештәге сүзләр күп кулланыла *(әни, әти, агай, туганай* һ.б.):

*Әти-әни* күзләремә,
Соңгы тапкыр карагыз!
Нигә көчләп сез бирәсез,
Мин бит сезнең балагыз?!

Тартым кушымчалы *(балам, әнием, әтием, дустым, анам, туташым, сеңлем, кодачам һ. б.)* формалар бар. Иркәләү кушымчасы алган эндәшләр дә киң кулланыла: *анакай, балакай, энекәй, әткәй, җизнәкәй* һ.б.

Бодай сиптем җирләргә, *энекәй*,
Күгәрченгә чүпләргә.
Бар хәсрәтем сөйләр идем, *энекәй*,
Юк үз ишем җүпләргә.

Бер төркем туганлык атамалары берничә кушымча алалар: *анакаем, инәкәем, бәбекәем, туганайларым, әнкәем, бәбкәем, дускайларым* һ.б.

Энә белән генә җеп кенәм
Калды сары сандык төбендә
Уйнаганым гына көлгәнем, *анакай,*
Калды газиз әтием өендә.

Кияүгә китә торган кыз ата-анасына аеруча яратып мөрәҗәгать итә, алардан мәрхәмәт-шәфкать өмет итеп эндәшә, үтенечләрен әйтә, саубуллаша, рәхмәт укый, кыз елату җырларында кинә-үпкәсен дә әйтә. Кызның саубуллашу җырларында иркәләү-кечерәйтү кушымчалы сүзләр янында шундый ук мөнәсәбәтне белдерә торган башка сүзләр дә әйтелә, шулай итеп ике, кайвакытта хәтта өч компоненттан торган эндәшләр барлыкка килә: *кияү канатым, әтием йөрәгем, газиз әнкәй, сөекле газиз әнкәем* һ.б. Мондый берничә компонентлы эндәшләр җырларның эмоциональлеген арттыралар, кыз баланың җырга салынган рухи халәтен, кайгысын тирәнрәк аңларга ярдәм итәләр, җырларның эстетик тәэсирен көчәйтәләр.

Икенче зур төркем эндәшләр телебездәге традицион эпитетлар, чагыштырулар нигезендә һәм шул ук тартым *(-ым/ -ем),* иркәләү-кечерәйтү *(-кай / -кәй, -ш, -кәш / -каш)* кушымчалары ярдәмендә ясалганнар. Алар арасында иң киң таралганы *җан* сүзе һәм аның төрле формалары: *җаным, җаникәем, җаныкаем минем, җанкаем, җаныем, җаный, җаный гынам сылуым, җан сөйгән(ем), җаным егет, җаным бәгърем, җанкисәгем, җанкиҗаным, и җан дустым* һ.б.

Күзләрем төшсә, күңелем төшми
Син *җанкаемнан* гайре бүтәнгә,
Җәмилә, *җаныем ла!*

Санап кителгән формалар, бер яктан, татар теленең образлы сүзләр һәм формалар ясау өчен бай арсеналы булу турында сөйләсә, икенче яктан, мондый вариантлылык кеше күңелендәге иң тирән кичерешләрнең, иң нечкә хисләрнең бик күп төсмерләрен чагылдыруга хезмәт итә. Шул ук вакытта аларга шигъри нәфислек хас, аларда төрледән-төрле тормышчан буяулар табарга була:

Биек тауларның урамы, *абзыем,*
Очадыр ла тузаны, *җаныем.*
Ни рәхәтне күргән башлар, *абзыем,*
Әле күрә нужаны, *җаныем.*
Яки

Агыла гына болыт, әй агыладыр,
Таулардан тауларга кагыладыр.
Гөлҗиһан, *җаныем,* бу ни хәл?

Беренче мисалда *җаныем* эндәше гомумән мөрәҗәгать итүне белдерә, ә икенчесендә исә конкрет бер кешегә, сөйгән ярга карата кулланыла, шигырь текстының төзелешенә үзенчәлек тә кертә.

Мәхәббәт җырларында *җанашым* эндәше, башка поэтик чаралар белән берлектә, тирән сөю хисен җиткерә:

Кашларың кыйгач, йөзләрең кояш,
Күңелем яктыра, күрсәм, *җанашым.*
Яки

Йөзегең алмаз, кими ярамас,
Йөзек тик ярат мине, *җанашым.*

Мишәрләрдә бу сүзнең *җәйнушым* варианты да кулланыла:

Узып китәсең былбыл кош кебек,
Кашыңны сикертеп чакыр, *җәйнушым.*

Яки

Карый урман уртасында
Туз яндырдым, *җәйнушым.*

Эндәшләрнең бер төркеме игътибарны кешенең матурлыгына, холкының күркәм якларына юнәлтә: *матурым, чибәрем, матуркаем, аппагым, акыллым:*

Җилбер дә генә җилбер йөргән чакта,
*Аппагым* ла, киче бәрхет калфагың,
Җилләр ачты ла минем лә,
Әй *аппагым,* куенымны.

Аппак кына, вак-вак кына, Мәфтуха,
Мәфтуха *чибәрем,* урманда куак кына;
Күп күрмәгез, күп тормабыз, Мәфтуха,
Мәфтуха, *акыллым,* без монда кунак кына.

Бер төркем эндәшләрне кеше әгъзаларын белдерә торган сүзләр тәшкил итә, алар халык иҗатында традицион сурәтләү чаралары булып урнашкан эпитетлар белән ачыкланып киләләр һәм җырларга җанлылык, шигъриятлелек бирә торган сүз-сурәтләр барлыкка китерәләр: *озын керфек, яшь йөрәгем, энҗе тешем, гәүһәр каш, ак беләк, бөдрә чәч, зәңгәр күз, алтын чәч* һ.б. Әгъзаларны белдерә торган сүзләрнең кайберләре, кушымчалар алып яки аерым сүзләр белән даими янәшә кулланылып, яратып, якын итеп мөрәҗәгать итүне белдерә торган традицион символларга әйләнеп киткәннәр: *йөрәк маем, йөрәк парәм* (фарс. парә – кисәк, *җанкисәгем), бәгърем* (бәгырь – багыр – бавыр + -ем) һ.б. Кайбер мисаллар:

Җиңги, *йөрәк парәм,* синнән сорыйм,

Бая узган егет каягы?

Китәм инде, озат, *бәгърем,*
Басу капкаларын чыкканчы.

Кай җирләрдә син йөрисең, сөйгәнем,
Йөрәгемнең *парәсе,*
*Сандугач баласы!*

Егълама, әнкәй, безнең өчен,
Тулган аем, *йөрәк маем,*
Җибәрермен яхшы хәбәр.

Алдарак билгеләп үтелгәнчә, җырлардагы эндәшләрнең зур төркемен кеше (нигездә хатын-кыз) исемнәре тәшкил итә. Җырларны өйрәнүгә зур өлеш керткән И. Надиров, лирик эндәшләр еш кына хатын-кызларга юнәлгән булалар, ди. Бу – татар җырларының бер поэтик сыйфаты. Җырларда очраган хатын-кыз исемнәрен бергә тезеп чыксаң, бик озын шигъри исемлек барлыкка килер иде.

Хатын-кыз исемнәреннән торган эндәшләргә аеруча лирик җырлар бай: аларда 50ләп хатын-кыз исеме эндәш сүз функциясен үти. Билгеле булганча, чыгышлары белән аларның зур күпчелеге гарәп сүзләре, эчтәлекләре белән исә алар нигездә кызларның *матур, гүзәл* (Җәмилә, Нәфисә, Җамалым, Латыйфә), *тыйнак* (Мазлума), *сабыр* (Хәлимә), *гөл* (Рәйхан), *җәннәт, бакча* (Фирдәвескәй), *истәлек* (Хатирә), *кадерле* (Газизә, Азизәкәй) булуларын, башка шундый күркәм сыйфатларын билгелиләр.

Төзелешләре буенча мондый исемнәр гади һәм кушма сүзләр булып торалар. Кушма исемнәрдә компонентларның берсе еш кына даими була. *Шәмсе* – кояш (Шәмсенур), *Нур* – нур (Бибинур), *Ниса* – хатын-кыз (Хәмдениса), *Гөл* – гөл (Гөлҗиһан, Гөлмәрфуга, Гөлфируз), *Биби* – бикә (Бибизарига, Бибисара), *Маһи* – ай (Маһисәрвәр), *Хәер* – яхшылык, изгелек (Хәерниса),

*Хәмде* – шөкер итүче (Хәмдениса) һ.б. Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, хатын-кыз исемнәрендә югары стильгә хас шигърилек чагыла, аларга салынган иң матур, иң күркәм сыйфатлар җырларның сурәтлелеген, образлылыгын көчәйтәләр, алар, бер яктан, җыр текстларының төзелешен баеталар, икенче яктан, аларның эчтәлеген тирәнәйтәләр. Традицион сурәтләү чараларының берсе буларак матур хатын-кыз исемнәреннән ясалган лирик эндәшләр шигъри әсәрдәге хис-тойгыларның тагын да баерак, үзенчәлеклерәк булуына китерә. Кайбер мисаллар:

Сиңа булган яшьлек мәхәббәтем,
*Мәдинәкәй,* гөлкәй, бөдрә чәч,
Гөрләп чәчәк ата йөрәктә.

Күпме йөрешеп тә аерылабыз,
Жәл каласың бигрәк, *Фатыйма,*

*Фатыйма,* каласың,
Сагынганда кемгә карарсың?

Кыскасы, җырның аһәңен, эмоциональ яңгырашын баету, хиссилеген көчәйтү максатына хезмәт итүче бу поэтик алым җырларда бик киң файдаланыла. Шул ук вакытта лирик эндәшләрнең халык җырларындагы һәм профессиональ иҗаттагы кулланылышын чагыштырганда, автор җырларында аларның шактый сирәгәюгә, бертөрлелеккә, төссезләнүгә таба баруын күрергә мөмкин.

**М.Р. Яппарова**
Татарстан Республикасы Кукмара районы

# ТАТАР ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫНДА АТА-АНА ОБРАЗЫ

Кеше күңеле җырлап ачыла, диләр. Җыр сәнгатенең барлыкка килүе дә табигый. Шатлыкта, кайгыда һәрберебез татарга гына хас моңга тартыла. Татар халкының җыр мирасы күп төсле бизәкләрдә тукылган моңлы, шигъри бер дөнья булып күз алдына килә. Җырның хискә, мәгънәгә бай нәфис сүзләре һәм бай тылсымлы музыкасы халыкның тиңдәшсез талант иясе булуын раслый. Җыр хәзинәсендә чал тарих авазлары да тирән булып уелган.

Шигъри хәзинә буларак тикшергәндә, татар халкының җыр мирасы йола җырлары, тарихи җырлар, уен җырлары, лирик җырлар төркемнәренә бүлеп каралган.

Гомумән, халык җыры катлаулы, поэтик жанр булып санала. Татар халкының гасырлар буена килүче һәм безнең көннәрдә дә телдән төшми яшәүче җырлары шактый бай, мәгънәле эчтәлекле тематикасы 2 төрле:

1) тарихи җырлар (болгар чорын, Казан ханлыгы чорын, крестьян сугышы, ватан сугышы, шәкерт садалары һәм җырлары, патша рекрутлары турында җырлар). Фольклор фәнендә тарихи җырлар төркеменә халыкның үткән тарихындагы аерым социаль-тарихи вакыйгаларга, күренекле шәхесләргә Һәм билгесез геройларга багышланган әсәрләрне кертәләр;

2) лирик җырлар (туган як, хәсрәтле тормыш, чит илләрдә бәхет эзләүчеләр, гомер агышы, мәхәббәт җырлары). Бу төркемдә һәрберебезгә дә якын булган уйланулар, кичерешләр, хистойгылар ята.

Әлеге җырлар белән танышканда халкыбызның талантына, кичерешләренә хәйран каласың. Бу кичерешләр эти-әниләргә бәйле җырларда ачык чыагыла. Әлеге тема аерым булып түгел, ә

тарихи һәм лирик җыр төрләрендә балаларга бәйле рәвештә чагыла. Мәсәлән, “Качкыннар һәм тоткыннар турында” җырлар бүлегендә “Староста кызы” текстында әлеге юллар бар:

Әтиемнең сивай аты
Таймас микән көченнән?
Беглыйлар урладылар
Әтиемнең үченнән.

Сүз кыз баланың качкыннар тарафыннан урлануы турында бара. Ата кешенең староста булып, качкыннарның сүзләрен тыңламавы өчен кызы урлана. Газаплар эчендә кыз бала бары тик әти-әнисен генә искә ала. Һәм бу табигый да, чөнки һәрберебез үз әти-әнисенең баласы, авырлык килсә, иң элек шуларны искә алабыз бит.

“Никрутлар йөкләнде муйныма” җырында лирик герой:

Быел җәйне урак урдым,
Ике беләгем сызганып,
Бәне әткәй солдат итте,
Бер эскертен кызганып.

Сүз патша армиясенә хезмәткә чакырылган егет турында. Җыр эчтәлегеннән атаның баласын әлеге хезмәттән алып калырга мөмкинлеге булып та, берни дә эшләмәве аңлашыла. Ата “бер эскертен кызганып” малаен хезмәт итәргә җибәрә. Җырда улларының әти-әнигә үпкәсе сизелә. Урынлымы бу, урынсыз үпкәме, әти-әни, патшага хезмәт итүне тиеш, дип санап, газиз балаларын алып калуны кирәк дип тапмыйлар. Әлеге тема “Наемщик” җырында да ачык чагыла: “Бай булса да әти мине, әй, җибәрә”, чөнки “ ике меңгә бер йөз тулмый”, шуңа күрә әти-әни:

...әй, бәбекәем бәхетең юк,
ахры кит син солдат булып, әй, үзең үк, -

дип, улларын озаталар. Бүгенге көн күзлегеннән караганда, күп аналар өчен кыргыйрак күренгән бу күренеш, ул чорда еш кына булгалаган, күрәсең.

“Син китәсең инде”(никрут анасының җыры). Әлеге җырда ананың никрут улын сагынып елавы сурәтләнгән:

Син китәрсең инде, мин калырмын,
Камышлардан күпер салырмын;
Син кайтасы юлга карый-карый,
Камышлардан сары калырмын.

Ана хәсрәте тирән, көче җитсә улын “ятлар кырына” җибәрмәс иде. Ул аның бердәнбер баласы:

Син дә бәбекәемнән дә аерылгач,
Кемнәр бирер миңа бер киңәш?

Патша хөкүмәте ялгыз ананың хәленә керми. Баласының 25 ел хезмәт итеп кайтуы да икеле. Бу хәсрәт заманында малае бул-ган һәр йортка да агылган.

“Хатын-кыз язмышы” турындагы җырлар үтә бер моң, күз яше белән сугарылган. Җырлар эчтәлеге нигездә кыз баланы теләмәгән кешегә кияүгә бирү, сатып җибәрүдән гыйбарәт. Бу моңның чыганагын иске тормыш шартларыннан, җәмгыятьтә һәм гаиләдә хатын-кызларга тискәре мөнәсәбәттән эзләргә кирәк.

Бу темага караган җырларны анализлаганда, шул күренә: та-тарда ул чорда хатын-кызның теләге, хисләре белән исәпләшүне кирәк дип тапмаганнар. Ата-ана кызларын кияүгә биргәндә, бил-геле сәбәпләр аркасында башкалары белән беррәттән материаль якны да исәпкә алу ягын караган. Мәсәлән, “Фәрүзә кыз” җырында ата кеше кызын карт, ләкин мул яшәүче берәүгә киягә бирә. Кыз :

Бирмәдең, әтием, үз тиңемә,
Бирдең картка, адәм кименә, –

дип елый, ләкин язмышына буйсынмыйча нишләсен? Җыр текстында кызның нинди гаиләдән икәне сиземләнми. Бәлки, гаилә башлыгы баласының тук тормышта яшәвен теләгәндер? Атаның яхшы ниятләр белән эш кылганын баласы соңыннан аңлагандыр? Шул ук тема "Әткәй мине картка бирде", "Кыз картка китте","Сабый кияү", "Ник үстердең буемны?", "Сөйгәнемә баралмадым", "Нигә тудым?"исемле һ.б. бик күп җырлар халык тарафыннан иҗат ителгән.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, югарыда билгеләп үтелгән барлык җырларда ата-ана темасы баласы белән булган вакыйгаларга бәйле рәвештә ачыла. Һәм бу табигый да: авырлык, кайгышатлык килгәндә, баласы өчен сөенгән, көенгән, аны кайгырткан кешеләр кемнәр? Әлбәттә, әти-әниләр! Шулай ук баласының зарына игътибар бирмәгән әти-әниләр дә сурәтләнгән. Заманасына күрә бу күренеш булгандыр һәм әле дә бар. Нишлисең, ата-ананы сайлап алмыйлар!

Җырлар нигездә моң, сагыш белән тугарылган. Тарихи җырлар тулысы белән үк, лирик җырларның туган якка, социаль тормышка, чит җирләрдә бәхет эзләүчеләргә, яшәү кадеренә, хатын-кыз язмышына багышланган текстларында бу тема тулысынча ачыла. Мәхәббәт, дуслык, шаян җырларда исә әлеге тема яктыртылмый диярлек.

Татар халкының җыр чишмәсе чал гасырлар түреннән агып килә. Һәр җыр – ул тарихның бер кисәкчеге, чорның үзе. Аны өйрәнү, татар халкына гына хас моңны югалтмау киләчәктә җыр чишмәсене саекмавына өмет бирә.

### Әдәбият исемлеге

1. Надиров И.Н. Татар халык иҗаты: тарихи һәм лирик

җырлар / И.Н. Надиров. - Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.

2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. - Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.

**Содержание**

**От составителей**.................................................................3

**Ахатова И.И., Ахатова С.И.**

ТАТАР ГАИЛӘСЕНДӘГЕ АРАЛАШУ ӘДӘБЕНЕҢ ФОЛЬКЛОР ҮРНӘКЛӘРЕ (Татарстан Республикасы Кайбыч районындабулган экспедиция материаллары буенча)....................4

**Галимуллина З.М.**

СУ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЫШАНУЛАР, ЙОЛАЛАР(Кукмара районы Зур Кукмара авылы мисалында).......................................15

**Гатауллин Р.Р.**

УРАЛ АРТЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНЕҢ ТАТАРЛАР ТАРАФЫННАН ҮЗЛӘШТЕРЕЛҮЕ.............................................20

**Гаянова Л.З.**

ЯШЬЛӘРГӘ ТӘРБИЯ БИРҮ ЫСУЛЫ БУЛАРАК КУКМАРА ТӨБӘГЕНДӘ УЙНАЛА ТОРГАН КИЧКЕ УЕННАР.......................................................................................24

**Гыйльманова С.М.**

РУХИ ЯДКӘРЛӘР……………………………..………32

**Демухаметова Г.М.**

ТУГАН ЯГЫМ АТАМАЛАРЫ ҺӘМ АЛАР БЕЛӘН БӘЙЛЕ ХИКӘЯТЛӘР......................................................................................35

**Завгарова Ф.Х.**

ВОПРОСЫ ТЕКСТА И КОНТЕКСТА В СОВРЕМЕННОЙ ФОЛЬКЛОРИСТИКЕ……………………………………39

**Завгарова Ф.Х.**

МИФОЛОГИЧЕСКИЙ ПЕРСОНАЖ БИЧУРА В ТРАДИЦИОННОЙ КУЛЬТУРЕ ТАТАР ЗАКАЗАНЬЯ…………44

**Зиганшина Л.**

О НЕКОТОРЫХ ОСОБЕННОСТЯХ КАЛЕНДАРНО-ОБРЯДОВОГО ЦИКЛА ТАТАР-МИШАРЕЙ

ДРОЖЖАНОВСКОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН……………………………………………………49

**Исмәгыйлева С.С.**

СТУДЕНТЛАРНЫҢ ФОЛЬКЛОР ТҮГӘРӘКЛӘРЕ БЕЛӘН ЗАМАНЧА ЭШЛӘҮ АЛЫМНАРЫ...............................................56

**Минһаҗева Р.Ә., Иванова О.Н.**

Г. ИРАҺИМОВНЫҢ «ЯЗ БАШЫ» ХИКӘЯСЕНДӘ ФОЛЬКЛОР МОТИВЛАРЫ..........................................................62

**Муллин И.Р.**

ТАТАРСКАЯ ЭПИГРАФИКА АПАСТОВСКОГО И АКТАНЫШСКОГО РАЙОНОВ РТ (к вопросу изучения)……...66

**Ризванова Ф.Г.**

ГЫЙБРӘТЛЕ ХӘЗИНӘЛӘР (Кукмара ягы мәзәкләре)…...70

**Садыкова Г., Минһаҗева Р.Ә.**

БОЛГАР ЧОРЫ ФОЛЬКЛОРЫНДА ЗИНДАН ТЕМАСЫ..80

**Төхфәтуллина Ә.Г**

Ш. ГАЛИЕВ ИҖАТЫНДА ПАРЕМИЯЛӘР КУЛЛАНЫЛЫШЫ.......................................................................84

**Усманова Т.**

ФОЛЬКЛОР ОБРАЗЛАРЫ АША Ф. ЯРУЛЛИН ШИГЪРИЯТЕНДӘГЕ МИФОЛОГИК КАТЛАМНЫ ТЕРГЕЗҮ……………………………………………………88

**Хәйдәрова Г.М.**

ЗӘРӘ БОТКАСЫ – ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ КАДӘР ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН БӘЙРӘМНӘРНЕҢ БЕРСЕ............................................97

**Хисматова А.Х.**

ТУЙ ЙОЛАСЫ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ТАКМАК-ТАКМАЗАЛАР (Татарстан Республикасы Кукмара районы Янил авылы мисалында)………………………………………………………..103

**Хуснуллина И.И.**

МНОГОКОМПОНЕНТНОСТЬ ЖАНРА ЗАГОВОРА.......111

**Хәмитова А.**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИСТАЙ РАЙОНЫ КЕРӘШЕН ТАТАРЛАРЫНЫҢ КАРГЫШ ҮРНӘКЛӘРЕ.........114
**Хөснетдинова А.**
ЧИШМӘЛӘРДӘ – ЕРАК ГАСЫРЛАР АВАЗЫ.................117
**Хөснетдинова А.Ф.**
ХӘЗЕРГЕ БЕЛЕМ БИРҮ ПРОЦЕССЫНДА ФОЛЬКЛОР..........................................................................120
**Шарипова Э.И.**
ШӘРИФ КАМАЛ ИҖАТЫНДА МИФОЛОГИК МОТИВЛАР............................................................................131
**Шәфигуллина М.Х.**
УКЫТУ-ТӘРБИЯ ЭШЕНДӘ ТАТАР ХАЛЫК УЕННАРЫННАН ФАЙДАЛАНУ................................................137
**Шәфигуллина М.Х.**
ТАТАР ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫНДА ЛИРИК ЭНДӘШЛӘР...........................................................................139
**Яппарова М.Р.**
ТАТАР ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫНДА АТА-АНА ОБРАЗЫ..............................................................................149

**Татарская фольклористика: исследования молодых.**
Сборник материалов чтений
школы молодых фольклористов.

Составители: Ф.Х. Завгарова, Л.Ш. Давлетшина